ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№02 (385)
ФЕВРАЛЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

БЛОГЕРНЫҢ ЯШЕ ЮК

№02 (385)
ФЕВРАЛЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Наилә Хәйретдинова,
Муса Юлдашев, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Рамил Гали,
Алсу Шакирова, Айдар Мөшәрәпов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Анастасия Хатыйпова
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Буадан галим, бакчачы, блогер
Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов.
Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 - 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-0140
Басарга кул куелды: 14.02.2024
Чыгу көне: 20.02.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ДӨНЬЯНЫ ЯМЬЛӘНДЕРҮЧЕ БУЫН

Авыр заманнарга, кырыс тормыш шартларына да карамастан, юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы кешеләр гел булган. Дөньяны алга этәрүче, кешеләрне яңалыкка, җиңүләргә рухландыручы, шул эшләрне оештыручы, үз артыннан ияртүче булган алар. Шөкер, ихлас күңелдән бирелеп эшләүче фидакарь затлар бүген дә арабызда бар. Күптән түгел генә шундыйларның берсен Буа районында очраттык. Гаҗәп кеше – кайчандыр СССР Югары Советы депутаты, алдынгы колхоз рәисе, беренче хосусый завод директоры булган ул... 78 яшьлек галим, бакчачы Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов бүген үзе өчен тагын бер шөгыль тапкан - блогерлыкны өйрәнгән. «Замана белән бергә атлыйсым, тәҗрибәмне халык белән уртаклашасым килә», – ди ул. Героебызга бу эш үзен күрсәтү өчен түгел, ә нәкъ менә халыкка файда китерү өчен кирәк. Шуның өчен әлеге хезмәтенә зур җаваплылык белән карый.

Дөньяны менә шундый фидакарь затлар ямьле итә инде. Арабызда бүгенге героебыз кебек кешеләр күбрәк булсын иде.

Сезнең сокланучан редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китерелеп бирелсә,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китерелеп бирелсә,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барысы тик татарстанда

ГАЛӘМ КӨЧЕН СЕҢДЕРГӘН БҮЛӘК

Казанда 21 февральдә башланып китәчәк Киләчәк Уен-
нарының төп бүләге фиджитал-тантананың үзе кебек
үк уникаль. Трофей ике төрле материалдан ясалган:
шомартылган металл һәм инновацияле полимер.
Эчендәге биш пластина биш ярыш юнәлешен аңлата:
«Спорт», «Тактика», «Стратегия», «Тизлек», «Техноло-
гияләр». Бүләк эчтән нур сибә, бу Киләчәк Уеннары та-
лисманы – асылда нурдан торган МИRA* - Бәхет кошын
символлаштыра. Декабрьдә трофей Җир орбитасына
күтәрелде. «МКСта ул галәм көчен, энергиясен үзенә
сеңдерәчәк. Ә аның галәмгә күтәрелүе безнең проект-
ның киләчәккә омтылуын символлаштыра. Киләчәк
Уеннары – дөнья спорт индустриясен үзгәртәчәк
12 көн ул», – дип хәбәр итте Уеннар проекты җитәкче-
се Игорь Столяров.

© «Татарстан» журналы

* MИRA – иң борынгы космик яктырткычларның берсе.

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Төнге тормыш...
Казан юлларын кардан ничек чистарталар

12. Карлы кыш
Гыйнвар ае кайсы елларда явым-төшем буенча рекорд куйган

14. Кар-бураннар белән сынау
Һава торышыннан алган сабаклар

24. Кышкы тылсым могҗизалары
Матурлык кайсы шәһәрдә туа

игелекле эшләр

38. Заманча дөньякүләм ярышлар
Нәрсә ул Киләчәк Уеннары

44. Махсус проект
Өзелеп көтү

54. Дөньяны ямьләндерүче буын
Галим, бакчачы, блогер...

58. Безнең кунакханәдә
Әдәби бәйгеләр ни өчен кирәк

мәңгелек кыйммәтләр

64. Казан обсерваториясе
Дуслык ничек бөтендөнья мирасына әйләнә

68. Тарихи сәхифә
«Өченче дөнья» инкыйлабы юлбашчылары кем хезмәтләренә таянган

72. Онытылмас исемнәр
Гальгаф кем ул

76. Безнең киштәдә
Кышкы китаплар арасында ниндиләре бар

80. Татар авыллары
Көләч Келәш

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: tatar-inform.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

22.01

Ирек Фәйзуллин, РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, – Казанда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы коллегиясенең киңәйтелгән утырышында:

– Илебезнең яңа төбәкләрендә эшләгән өчен Татарстанга рәхмәт сүзләре җиткерәм. Лисичанск һәм Рубежныйдагы эшләр өчен. Бүген Татарстанның төзелеш комплексы Мариуполь объектларында да катнаша. Анда барысы да вакытында эшләнә, өзеклекләр юк. Фронт сызыгына бик якын урнашкан территориядә шефлык эшләре дә бик актив алып барыла.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

19.01

Айрат Хәйруллин, ТР цифрлы үсеш министры, – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының йомгаклау коллегиясендә:

– Цифрлаштыру куркынычсызлыкны тәэмин итәргә тиеш, бу бурычны 99 мең камера урнаштырылган «Имин шәһәр» проекты хәл итә. Узган ел 1127 видеокүзәтү камерасы урнаштырылды. 2024 елга тагын мең видеокамера урнаштыру планлаштырыла.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

25.01

Гөлшат Нигъмәтуллина, ТР Министрлар кабинетының ЗАГС Идарәсе башлыгы, – ведомствоның йомгаклау коллегиясендә:

– Абсолют сан буенча да, 1000 кешегә исәпләгәндә дә республика туу турындагы актлар саны буенча Идел буе федераль округында беренче урында тора. Хисап чорында 36766 туу таныклыгы тапшырылды, бу узган ел белән чагыштырганда 0,4 %ка кимрәк. Шул ук вакытта кимү темплары узган ел белән чагыштырганда сизелерлек акрынайды. Татарстанда күп балалы гаиләләр саны 2008 елдан бирле өзлексез арта бара. Бу халык санын тотрыклыландыруның мөһим факторы булып тора, алга таба үсеш өчен перспективалар формалаштыра.

Фото: digital.tatarstan.ru, tatarstan.ru, tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Карны **ничек** җиңәргә

Кар көртләре **нинди** биеклектә була ала

Һава торышыннан **нинди** сабак алдык

Борынгы кала **нинди** хисләр уята

ГЫЙНВАР БУРАННАРЫ

Карга күмелеп утырган шәһәр һәм авыллар. Анда-санда машина батып калган урамнар. Атларга да кыен булган «кәҗә сукмаклары» салынган ишегаллары. Ябык федераль трассалар...
Татарстанда бер атнадан артык дулаган буран, явым-төшем буенча күпьеллык рекорд куеп, транспортчыларга, коммуналь хезмәтләргә, гомумән барыбызга да берсеннән-берсе катлаулырак бурычларны куя торды. Без табигать стихиясенә каршы ничек көрәштек соң? Мондый уңайсыз һава шартлары биргән сабакларны ни дәрәҗәдә яхшы үзләштердек? Алда – февраль, үзенең шундый ук бураннары белән. Безнең сорауларга төгәл җавапны нәкъ менә февраль ае бирәчәк тә.



Фото: tatar-inform.ru



Александр Ефремов фотолары

«БУРАН» ОПЕРАЦИЯСЕ. ШӘҺӘР ЙОКЫГА ТАЛГАН ЧАКТА...

Дмитрий Сивков

Гыйнвар аенда Казанны күмеп китә язган кардан урамнарны ничек чистартып бетерергә? «Татарстан» тәүлек буе әлеге эш белән шөгыльләнүчеләрне тыңлады, алай гына да түгел, үзе дә катнашып карарга булды. Әлбәттә инде, төнлә: шәһәр йокыга талган мәлдә юлларда эшнең иң кызган чагы бит.

25 гыйнвар. Авиатөзелеш районы, Лечебная урамы. 12 нче шәһәр хастаханәсе янындагы юл кино төшерү мәйданчыгын хәтерләтә. Әмма софитлар урынына – кар төягеч һәм КАМАЗларның фаралары. Катнашучылар – коммуналь хезмәтләр эшчеләре һәм машина йөртүчеләр: барысы да кызгылт-сары жилеттан, көрәк күтәргән. Конвейер туктамый эшли: йөк машинасының берсен шыгрым тутыруга ук, икенчесе килеп баса. Бер генә минутка да туктап тору юк.



ЙӨЗЛӘРЧӘ ЧАКРЫМ – ҺӘМ БАРЫСЫ ДА МӨҺИМ

– Башкаланың юл хезмәтләре 17 гыйнвардан бирле көчәйтелгән режимда эшли, – дип аңлата шәһәрне тышкы төзекләндерү комитеты рәисе урынбасары Марсель Әхмәтҗанов. – Соңгы тәүлектә юл чистартуда 1096 техника берәмлеге һәм 777 юл эшчесе катнашты. Бүген көндез исә 754 хезмәткәр һәм 548 махсус техника берәмлеге чыкты.

Куелган бурыч бик мөһим: мәсәлән, җәмәгать транспорты йөри торган юлларның барысын да 28 гыйнварга кадәр чистартып бетерергә кирәк. Ә аларның тулаем озынлыгы 554 километр тәшкил итә – бу Казаннан Яр Чаллыга барып кайтуга тиң. Шәһәр социаль учреждениеләре территорияләре исә 25 гыйнварга тулысынча диярлек чистартылып беткән инде.

Безнең бүгенге объект – 2 нче категорияле юл. Ул шәһәрдәге өч меңнән артык социаль объектка (балалар бакчалары, мәктәпләр, мәдәният һәм медицина учреждениеләре, спорт корылмалары) алып бара торган юллардан берсе. Төп юлларны кардан чистартканнан соң, бу урамнарны җыештыру башлана.

ЕЛ БАШЫННАН КАЗАН ЮЛЛАРЫНА **1 МИЛЛИОН ТОННАДАН АРТЫК КАР** ЯУГАН (ШӘҺӘР БИСТӘЛӘРЕ ҺӘМ ИШЕГАЛЛАРЫНДАГЫ ЮЛЛАРНЫ ИСӘПЛӘМИЧӘ). АЛДАГЫ ЕЛЛАРДА ИСӘ БӨТЕН КЫШ БУЕНА БАРЛЫГЫ 650 МЕҢНӘН 950 МЕҢ ТОННАГА КАДӘР КАР ЯВУЫ ТЕРКӘЛГӘН.

ТӨН, УРАМ, ЭШ

Әлеге көрәштә катнашучылар белән дә танышыр вакыт. Кар төягеч машина операторы Навил – шулардан берсе. Сменасы 12 сәгать дәвам итә икән. Күп дигәндә, нибары ярты сәгатькә туктап ял итеп алган.

– Арыйсыңдыр инде, ярты тәүлек буе бертуктаусыз эшләгәч?

– Миңа 25 яшь кенә бит әле, түзәрлек, зарланмыйм.

– Юл кырыенда калган машиналар комачаулыймы?

– Түзәрлек. Бераз озаграк кына эшләргә туры килә, – ди Навил. Аның сөйләшеп вакыт үткәрәсе килми, тизрәк кабинасына ашыга.

Юл эшчесе Румия аңардан сүзчәнрәк булып чыкты. Көрәге белән селтәнүдән туктамыйча гына коммуналь хезмәтләрдә инде унберенче ел эшләвен әйтте.

– Минем төнге смена – кичке тугыздан иртәнге бишкә кадәр, – ди ул. – Авырмы? Күнегелгән инде.

– Болай нормадан тыш эшләгән өчен күбрәк түлиләрме соң?

– Күбрәк. Күпмегә икәнен әйтмим...

Йөк төягеч белән узышып диярлек эшләүче Румия бик теләп фотограф белән дә аралаша. Фотоларны кайда бастырасыларын сорый. Җавапны ишеткәч, елмая.

КАР САКЛАГЫЧ

23.00. Мәскәү районы. ТЭЦ урамы. Карны вакытлыча туплау урыны. Мәйданның зурлыгы – футбол кыры чамасы. Кар ташу машиналары йөкне бирегә китереп аудара. Инде хәзер үк биеклеге ике метрдан арткан кар ястыгын бульдозер бертуктаусыз тыгызлап һәм тигезләп тора.

– Бу мәйданчыкны, башкалары тулгач, буран алдыннан гына ачтык. Киров һәм Мәскәү районнарында шундый барлыгы дүрт саклагыч бар. Путейская һәм Васильченко урамнарында, Осиново бистәсендә, – дип аңлата «Казан шәһәре Киров районы Юл ремонт-эксплуатация идарәсе» МУП директоры урынбасары Артур Кулешов.

– Ә нишләп карны башка җиргә, мәсәлән, кая да булса кырга илтеп аударырга ярамый?

– Экологиягә зыян киләчәк, шунлыктан болай эшләргә ярамый. Биредә исә мәйданчык асфальтланган, кар суы агып китәр өчен канализация җайланган. Бераз соңрак биредәге карны эретү пунктына төяп илтәчәкләр. Табигатькә зыян китерелмәячәк.

Мәйданчыкка тагын бер КАМАЗ якынлаша. Без сорау биргәнче, Артур Кулешов:

– Бер төндә якынча йөз КАМАЗ кабул итәбез, – дип әйтеп куярга да өлгерә.

Төн – кар ташу өчен иң яхшы вакыт. Трафик азрак, җәмәгать транспорты йөрми, урамнар буш. Эшлә генә!

Шәһәрне тышкы төзекләндерү комитеты мәгълүматлары буенча, 17 гыйнвардан 25 енә кадәр Казан урамнарыннан барлыгы 237 мең тонна кар чыгарылган. Соңгы тәүлектә генә дә стационар кар эретү пунктларына 11 мең тонна җибәрелгән. 26 мең тоннасы карны вакытлыча саклау мәйданчыкларына ташылган.

Шәһәр хакимияте Казанны кар әсирлегеннән – бер атна, күп дигәндә, ике атна эчендә тулысынча коткарырга вәгъдә бирә.

КАЗАН. АП-АКТАН

2024 елның гыйнвары

46 мм
БУ АЙДА ТР БАШКАЛАСЫНДА ЯВЫМ-ТӨШЕМ НОРМАСЫ

80,7 мм*
ЯВЫМ-ТӨШЕМ КҮЛӘМЕ.
БУ НОРМАДАН
1,7 ТАПКЫРГА КҮБРӘК

КАР КАТЛАМЫНЫҢ КАЛЫНЛЫГЫ
80 мм
ДАН АРТЫП КИТТЕ

ФАКТ

Гыйнварның 11 көне эчендә, 17 сеннән 28 сенә кадәр, Казанда явым-төшем күләме **57 ММ БУЛДЫ, БУ - АЙЛЫК НОРМАДАН 122 %**.
Татарстанда гыйнварның өч көнендә айлык норманың 60 – 130 % кадәр кар яуды.

* Агымдагы елның 28 гыйнварына
** Шул чорга

ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДА ШӘҺӘРДӘ КҮПМЕ КАР ЯУГАН. РЕКОРДЛАР ҺӘМ АНТИРЕКОРДЛАР

2023 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫ

19 мм

КАЛЫНЛЫКТАГЫ КАР.

РЕСПУБЛИКАДА УЛ ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫНДА ЯВЫМ-ТӨШЕМ КҮЛӘМЕ УРТАЧА **18 МИЛЛИМЕТР** БУЛА – НОРМАДАН **2,5 ТАПКЫРГА КИМРӘК**.

2022 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫ

ШӘҺӘРДӘ БЕР АЙ ЭЧЕНДӘ ЯУГАН ЯВЫМ-ТӨШЕМ КҮЛӘМЕ –

63 мм

ГЫЙНВАР НОРМАСЫННАН 144% – ИНДЕ 21 ГЫЙНВАРДА УК ТР БАШКАЛАСЫНДА ЯУГАН КАРНЫҢ КАЛЫНЛЫГЫ **48 ММ** БУЛА. КАР КАТЛАМЫ **60 САНТИМЕТРНЫ** тәшкил итә.

2011 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫ

ЯВЫМ-ТӨШЕМ КҮЛӘМЕ –

74 мм

КАЗАНДА **СОҢГЫ 80 ЕЛ** ЭЧЕНДӘ** ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЕНДА ЯУГАН ЯВЫМ-ТӨШЕМНЕҢ ИҢ ЗУР КҮРСӘТКЕЧЕ

1935 ЕЛНЫҢ ГЫЙНВАРЫ

ЯВЫМ-ТӨШЕМ КҮЛӘМЕ –

3 мм

йөз ел эчендә **ИҢ АЗ** КАР ЯУГАН ЧОР

ФАКТ

Иң карлы гыйнвар айларында, елъязма мәгълүматларына һәм йөз ел ярымлык күзәтүләргә караганда, Казанда кар катламы **100 САНТИМЕТРДАН АРТЫП КИТКӘН**.

ЧАГЫШТЫРЫЙК

Кышкы чорда айлык явым-төшем буенча рекорд **2010 ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕНДӘ** куела. Ул вакытта республика буенча уртача **3 АЙЛЫК** кар бер айда ява. Казанда - **151 ММ**, яки **4 АЙЛЫК НОРМА**.

Фото: tatar-inform.ru, Анастасия Хатыйпова

КАР КОЧАГЫНДА

Муса Юлдашев

Гыйнвар бураннары күпмедер вакытка шәһәр һәм бистә кешеләрен яшәү рәвешен үзгәртергә мәҗбүр итте. Хәзер коммуналь хезмәткәрләрнең тырышлыгы белән юл һәм тротуарлар әкренләп кардан арынып, тормышыбыз үз юлына кайткач, уйланыр, кайбер нәтиҗәләр ясар вакыт җитте: без табигать стихиягә никадәр дәрәҗәдә каршы тора алдык соң?
Хәбәрчебезнең язмасы әнә шул уңайсыз һава шартлары китергән сабаклар турында.

— Бүген ниһаять әнине казып чыгардык, – дип шаккатырды хезмәттәшебез.

Шулай дигәч, күз алдына әллә нинди куркыныч хәлләр килде. Шөкер, бар да әйбәт, корбаннар юк. Хезмәттәшемнең энисе Әнвәрия апага – сиксән яшь. Өч көн элек аның авыл өенә салынган сукмакны кар күмеп киткән, шуңа күрә әби үзе генә, мөстәкыйль рәвештә беркая да чыга алмаган – кибеткә дә, күрше-күләнгә дә. Ул өч көн тулы изоляциядә – ипи-сөтсез яшәргә мәҗбүр булган...

БЕР МЕҢГӘ КАЗЫП ЧЫГАРАЧАКЛАР

Бу хәлләр ерак тайгада түгел, Казаннан илле чакрымнар тирәсе ераклыктагы Питрәч районында бара. Барысы да аңлашыла кебек: форс-мажор, табигать китергән бәла-каза. Ләкин олы кешеләргә җиңел түгел. Авылда 90 кеше яши, күпчелеге – пенсионерлар. Әнвәрия апа да ярдәмнән башка карны җиңә алмаган бердәнбер кеше түгел. Балалар һәм оныклар шәһәрдә, әмма, ишеп яуган кардан соң юллар начар булу сәбәпле, алар да тиз генә кайтып җитә алмыйлар...

Ә җирле хакимият, авыл җирлеге администрациясе кайда соң? Алар да кул кушырып утырмый кебек. Тракторчы яллап, авыл урамнарын чистарттырып торалар. Ләкин һәр йортка салынган сукмакны, гафу итегез, тракторчы чистарта алмый, тиеш тә түгел. Хәтта ул йортта карт-корылар һәм мохтаҗлар беркая чыга алмый ятсалар да.

Әнвәрия апа әле бәхетле. Әгәр дүртенче көнгә кар тоткынлыгыннан котылуны бәхет дип санасак, әлбәттә. Хезмәттәшебез авыл советы секретарена шалтыратып ялварганнан соң ярдәм килә.

– Ләкин бушка түгел, – дип кисәтә секретарь. – Тракторчыга мең сум бирерсез.

Бу очракта мең сум нәрсә инде ул? Исән-сау дөньяга чыга алу кадерлерәк. Аллаһка шөкер, әбинең сәламәтлеге бу көннәрдә зарланырлык булмый, ә бит күңелсез хәлләр дә килеп чыгарга мөмкин.

Язмабызда без, әлбәттә, бу хәлнең кайсы авылда булганын язарга ниятләгән идек. Ләкин Әнвәрия апа:

– Кирәкми, язмагыз, минем әле монда яшисем бар, – дип үтенде.

Мөгаен, ул хаклыдыр. Хәер, без күтәргән проблема бер ул авылга гына хас түгел бит, хәтта бер районны гына да аерып әйтеп булмый. Көчле кар яву сәбәпле, өлкән яшьтәге кешеләр тышкы дөньядан аерылып калган авыллар берәү-икәү генә булмады. Социаль хезмәтләр дә, шәһәрдәге кебек, даруын, азык-төлеген сатып алып китереп бирми, ярдәмгә килерлек яшьләр дә хәзер авылларда юк диярлек.

Нишләргә? Мөгаен, быелгы кебек табигать стихиясе аркасында килеп чыккан очраклар өчен җирле хакимиятнең кулында ярдәм беренче чиратта таләп ителгән кешеләрнең исемлеге һәм адреслары булырга тиештер. Һәм оператив рәвештә ярдәмгә килергә сәләтле волонтерлардан торган мобиль команда. Тагын, әлбәттә, булган көчләрне көйләп, бөтен эшне контрольдә тотучы җаваплы кешеләр. Югыйсә күңелсез хәлләр булырга бик мөмкин.

ШӘҺӘРАРА ЮНӘЛЕШТӘГЕ ФОРС-МАЖОР

Займище станциясе. Поезд бик күпкә соңга кала - шәһәр яны электричкасын көтеп торучы ир-атның сакал-мыегына кунган бәс моңа иң яхшы дәлил. Платформада Дамир Гаязов белән бергә туңып торган кешеләрнең йөзләрендә - өметсезлек, гаҗизлек.

– Расписание буенча Казанга баручы электричка сәгать 11:33тә килергә тиеш иде, – дип аңлата Дамир. – Инде бер сәгатькә якын көтәбез - поезд юк. Беркем дә сиңа аның кайчан киләсен төгәл әйтә алмый. Иң начары шул. Бер сәгатьтәнме, өч минуттанмы, биш минуттанмы...

Салкында сәгать ярым басып торуның нәрсә икәнен аңлатырга кирәкми. Ачык платформада җил уртасында сәгать ярым туңып тору белән чагыштырганда, аэропортта алты сәгать самолет көтү - җиңел бер тәнәфес кебек кенә. Монда салкын, бернинди мәгълүмат та юк, сервис та күрсәтелми, анда - җылы аэровокзал, кафе, белешмә һәм таблода тоткарлану вакыты даими күрсәтелеп бара...

Тимер юлны кар басу, кар катламы астында калган уклар, ерак юлга баручы поездлар һәм шәһәр яны электричкаларының озакка тоткарлануы... Буранлы көннәрдә тимер юлдагы хәлләргә тимер юлчыларның аңлатмасы гади һәм аңлаешлы: стихия, форс-мажор. Электричкага электрон билетлар сатып алып, аны көтеп җиткермәгән кешеләр, күрәсең, шул ук сәбәптәндер инде хәтта теоретик яктан да акчаларын кире кайтаруга өмет итә алмый.

Чыннан да бернәрсә дә эшләп булмыймы соң?

Платформада сәгатьләр буе туңып торган пассажирлар бер нәрсәгә игътибар итте. Алар, мәсәлән, Албабадан һәрвакыт соңга калып килә торган электропоездны көткәндә, Түбән Новгородтан Казан ягына буш электричка очып үтте. Ул чыннан да расписание буенча шәһәр яны станцияләренең күбесендә тукталмый. Аның артыннан Ульяновскига таба ярымбуш рейс автобусы выжылдап узып китте. Һәм шулвакыт, мөгаен, платформада басып торучыларның күбесенең башына сәер (ә, бәлки, бик дөрестер!) уй да килгәндер. Бүгенге гадәттән тыш хәлләр вакытында әлеге поездлар ике-өч тукталыш ясаса нәрсә була? Моның өчен расписаниегә вакытлыча төзәтмә кертеп булмыймы?

Әйе, кайчандыр һәр шәһәр яны станциясендә эшләгән кассалы җылы бүлмәләрне хәзер кире кайтарып булмый, электричкалар расписание буенча йөри икән, бу кирәкми дә. Ләкин поездның соңга калуын хәбәр итәргә ярамыймы? Бу техник яктан катлаулымы? Юк, әлбәттә! Шул ук платформа янында, мәсәлән, депо, зур юл хуҗалыгы үзенең хезмәткәрләренә хәбәрне әллә кайларга ишетелерлек итеп микрофон аша җиткерә.

Гомумән, буранлы көннәрдә һәм аннан соңгы бер атна эчендә тимер юлда барган хәлләргә караганда, тимер юлчыларда «пассажирлар турында кайгырту» төшенчәсе ерак юлга баручы поездлар белән чикләнде. 22 гыйнвардан соң, Казанда һәм аның тирәсендә кар явудан туктагач та, электричкалар соңга калуын дәвам итә. Кичке сәгать 17:15 ләрдә Восстание станциясеннән Яшел Үзән ягына йөрүче электричка хәтта Коркачыктан Казанга кадәрге кечкенә участокта гына да «артык сәгать» җыярга өлгерде. Күрәсең, эштән шәһәргә якын авылларга кайтучы кешеләрнең шәхси вакыты белән санлашмаска да буладыр...

Сүз уңаеннан, электричка пассажирларының беркайчан да соңга калып йөрүче состав машинистларыннан гафу сүзләре ишеткәннәре юк.

ТАБИБ БЕЛӘН ОНЛАЙН? ХЫЯЛЛАНМАГЫЗ ДА!

Урамнарда – биек-биек кар өемнәре, юлларда - көрт, транспорт йөрми диярлек.

Ләкин кешеләр авырмый тормый, табибка язылучылар шактый. Әмма дәваханәгә барып җитә алсалар, бик әйбәт, ул чакта табибка күренәчәкләр.

...Чистай урамындагы медицина үзәгенең теркәү бүлегендә телефон кызганнан-кыза бара. Кыядай нык Екатерина исемле хезмәткәр ниндидер бер пациентка шалтырату белән берни дә үзгәртә алмаячагын аңлатырга азаплана. Кабул итү сәгатенә килеп өлгермисез икән, димәк, больничный кәгазеннән колак кагачаксыз, ди.

- Мин берничек тә килеп җитә алмаячагымны белгәнгә шалтыратам, - дип аклана пациент С. – Өйдән алдан ук, өч сәгатькә иртәрәк чыгып киттем, транспорт йөрми. Мин моны документ белән раслый алам...

- Димәк, сезгә больничныйны бозып ябачаклар һәм минималь күләмдә генә түләячәкләр...

- Форс-мажор бит, табиб белән онлайн аралашырга ярамыймы, миңа бит больничныйны озайтырга кирәкми, бары тик ябарга гына...

Сөйләшү бернәрсәгә дә китерми, пациент та табибка вакытында барып җитә алмый.

Карлы гыйнвар өчен таныш хәл, шулай бит? Аерма гадәттә детальләрдә генә. Кемдер буран аркасында табибка барып җитә алмый, кемдер больничный ачарга өлгерми, өченчеләре эшкә чыгар өчен больничныен яптыра алмый азаплана...

Шунда ук ковид вакыты искә төшә. Ул вакытта хәл күпкә катлаулырак иде, бәлки шуңа күрә дә дөрес карарлар күпкә тизрәк кабул ителде, шул исәптән сәламәтлек саклау өлкәсендә дә. Больничный кәгазьләрен дистанцион рәвештә ачу-ябу, табиб белән онлайн аралашу - болар барысы да мөмкин иде һәм актив кулланылды. Алай булгач, нигә бу уңышлы тәҗрибәне табибка барып җитү җитди проблема тудырган кайбер гадәттән тыш очракларда кулланмаска?

Язмамны тәмамлаганда тагын бер очрак турында әйтәсем килә... Яшел Үзән районының Октябрьск бистәсендәге «Пятерочка» кибете, Казаннан биш чакрым ераклыкта. Өлкән яшьтәге берәү, күзләрен кыса-кыса, ярымбуш киштәләрдә нәрсәдер эзләп азаплана. Тапмагач, сатып алучыларның берсенә мөрәҗәгать итә:

- Гафу итегез, мин генә күрмимме, сөт кайдарак икән?

- Күрсәк тә, таба алмабыз. Сөт юк...

Ун көнлек буран вакытында сөт һәм икмәк китерүдә кайвакыт өзеклекләр күзәтелде. Әмма монда, мөгаен, республика хакимиятләренең шушы катлаулы хәлләрдә дә, юллар ачылуга, беренче чиратта кибет һәм супермаркетларга азык-төлек китерүне тәэмин итә алуларын билгеләп үтәргә кирәктер. Бу да сабак. Уңай тамга белән.

Фото: Александр Ефремов

ЧЫН КЫШ

Декабрь – салкын. Гыйнвар – ишеп кар ява. Февраль – буран котыра. Ә нигә гаҗәпләнергә? Кыш бит. Чын кыш.
Карлы-буранлы кыш. Башкалабыз урамнарын бизәгән утлар яктысында ап-ак кар бөртекләре бигрәк матур җемелди: Казан Кремленә, Камал театрына, Болак елгасы аша салынган күперләргә, Черек күл, Кремль яры буйларына күз салыгыз.

Казанлылар һәм шәһәребез кунаклары, телефоннарын кулдан төшермичә, бу илаһи матурлыкны истәлеккә калдырырга ашыга...

– Бу иң матур кыш...

– Бу иң әйбәт кыш...

– Бу мин яраткан кыш...

– Бу чын кыш, - диләр алар.

Ә сез кышкы күренешләрне төшерергә өлгердегезме? Аларның иң матур дип тапканнарын безнең Телеграм-каналга юллый аласыз!

Алабуга

Оксана Кузнецова рәсеме. Александр Ефремов фотосы

ЧАЛ КАЛА АЛАБУГА

Гыйнвар бураннарын без Алабуга шәһәрендә каршы алдык. Республикабызның иң борынгы калаларының берсенә кышкы сәфәргә чыккан идек.

Ап-ак карга күмелеп утырган шәһәрдә үзебезне әкият дөньясына эләккәндәй хис иттек. Шаулап торган шәһәр тынып калган. Көндез кояш нурларында, кичке шәһәр утлары яктысында кар бөртекләре, искиткеч матур җемелдәп, тирә-якны сихри тылсымга күмә. Ирексездән күңелгә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның «Шулкадәр» дип аталган шигыре килә:

Шулкадәр яктылык, күзләрең бәйләнә,
Шулкадәр саф һава – башларың әйләнә,-
Бу чынлап һавадан, юрама хәйләгә...

...Шулкадәр иркенлек, иге юк – чиге юк:
Шулкадәр пакь җиһан, әйтерсең, чигүлек,-
Безнең һәр эзебез барадыр чигелеп....

Әлеге гүзәллек чагылыш тапкан фотоларны сезнең хозурыгызга да тәкъдим итәбез.

Фото: Артур Кудрявцев



КҮЗ САЛ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

Фото: Артур Кудрявцев



Хәләл сүзе җәмгыятебезгә ныклап кереп урнашты. Гарәп теленнән «Аллаһ рөхсәт иткән» дип тәрҗемә ителә торган әлеге сүз белән азык-төлек продуктларының да, кием-салымның да, косметиканың да тамгалануы гадәти күренешкә әйләнде. Финанслар да хәләл булырга мөмкин икән. Республикада хәләл финанс системасы үсеше турында без ислам фәннәре докторы, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Галәмәләр шурасы гыйльми сәркатибе, Казан ислам институты проректоры Рөстәм хәзрәт Нургалиев белән сөйләштек.

ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ – ИҢ ӘҮВӘЛ ПАРТНЁРЛЫК УЛ

Дмитрий Сивков

РИБАСЫЗ БАНКИНГ

– Сүзебезне иң гадидән башлыйк. Ислам финанслары күпчелегебез көн саен диярлек очраша торган финанс системасыннан нәрсәсе белән аерыла?

– Аермалар күп тә түгел. Игелек, мантыйк һәм башка төшенчәләрне кабул итүдә гомумкешелек принципларыннан тыш, мөселманның тагын бер чыганагы бар – бу илаһи вәхи. Кеше нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәненә төшенергә тырыша, әмма Аллаһ моны яхшырак белә, дип саный. Шуңа күрә ислам финанс моделенең асылында илаһи вәхидән гыйбарәт изге Коръән аятьләрендә билгеләнгән шәригать принципларын үтәү ята. Иң әүвәл бу – мөселманнарның көндәлек тормышларына бәйле рәвештә кертелгән тыюларны үтәргә омтылу.

– Аерып әйткәндә, сүз нинди тыюлар турында бара?

– Беренчедән, риба проценты турында. Икенчедән, тыелган тармаклардан керем алу турында. Боларга хәмер, тәмәке, дуңгыз ите җитештерү һәм сату, «шәһвәт һәм комар индустриясе» – казино, тотализаторлар, төрле акчалы парилар, порно җитештерү. Өченчедән, табыш алу ысулына бәйле теләсә кайсы билгесезлек төре, ягъни бу процесста очраклылык булмаска тиеш. Дүртенчедән, сүз зур зыян, чыгымнарга китерерлек куркынычы булган ысуллар турында бара.

– Әйе, гадәти банклар моны уйлап мәшәкатьләнми. Кредит алдыңмы – түлә, калганы мөһим түгел.

– Хикмәт шунда шул. Банкингта нигез итеп алынган, акчадан файдаланган өчен алдан ук билгеле процент алуны ислам риба дип аңлата. Ислам банкларга табышны һәм куркынычларны ике як арасында бүлешүнең гадел контракты аша акча эшләү теләген тормышка ашырырга тәкъдим итә. Банкирлар бу очракта акчага акча биреп кенә калмый, ә теге яки бу проектта партнёрларга әверелә, партнёрларның керемнәренә янаган акчалата куркынычларны уртак күтәрә һәм аларның табышы да шуннан тора.

Яки хәләл ипотеканы алыйк. Банк сезнең өчен фатир сатып ала һәм сез шунда ук аның хуҗасына, милек иясенә әйләнәсез. Әгәр нindидер сәбәпләр аркасында банк алдында финанс йөкләмәләрен үти алмасагыз, фатирны ачык рәвештә сату мөмкинлеге бар, ә гадәти ипотека очрагындагы кебек махсус әчке базарда арзан һәм отышсыз бәядән түгел.

Процентка акча бирү һәм бизнеска бергәләп катнашу – икесе ике нәрсә. Россия кануннарын-

Автор фотосы

да ислам финансларының «партнёрлык финансы» дип аталуы юкка гына түгел. Минемчә, бу гадел мөнәсәбәт, чөнки мөселманнарның тормыш принципларын хуплаган һәр кеше мондый партнёрлыктан файдалана ала.

АЛАР ТУРЫНДА КҮП СӨЙЛӘМИЛӘР, ЛӘКИН ЭШ БАРА

– Кызыктыргыч булуына карамастан, ислам финанс системасы популярлык казанмый кебек... Һәрхәлдә, хәтере-хәбәре юк, рекламалары һәр почмактан диярлек яңгырап торган башкаларныкы кебек түгел.

– Хәтере-хәбәре булмау – бер нәрсә. Чынлыкта Татарстанның төрле финанс структуралары тарафыннан биш төрле продукт тормышка ашырылды инде: күчемсез милек сатып алуга хәләл рәвештә өлешләп түләү; хәләл инвестиция мөмкинлеге, хәләл кыйммәтле кәгазьләр идентификаторы мобиль кушымтасы; авто-транспорт, төзелеш материаллары һәм вак көнкүреш техникасы сатып алуга хәләл рәвештә өлешләп түләү; хәләл дебет карталары.

Ә менә әлегә физик затлар өчен продуктларның гадәти банкларныкына караганда бераз кыйммәтрәк булуы – монысы башка мәсьәлә. Бу исә базарда мондый юнәлештә эш алып баручыларның әлегә аз булуы белән бәйле. Хәер, соңгы вакытта алар актив теркәлә, шулай булгач, вазгыять тә үзгәрәчәк.

– Моңа, мөгаен, Россия кануннарында үзгәрешләр дә йогынты ясагандыр?

– Шул исәптән ул да роль уйнады. Чыннан да, узган елның көзендә партнёрлык нигезендә финанслау эшчәнлеген җайга сала торган федераль закон үз көченә керде. Аның максаты – мөселманнар күпләп яшәгән һәм ислам финанс структуралары инде эшли торган төбәкләрдә ислам финанс моделен сынап карау. Мондый төбәкләргә Башкортстан, Дагыстан, Чечня Республикасы һәм Татарстан керә. Ике елдан эксперимент нәтиҗәләренә анализ ясалачак, һәм әлеге хокукый нормаларны Россиянең башка төбәкләренә дә тарату турында карар кабул ителәчәк.

– Димәк, Татарстан янә беренче сафларда бара. Ә кадрлар белән эш ничек тора? Һәр икътисадый өлкәнең үсеш мәсьәләсе нәкъ менә аларга килеп терәлә бит.

– Республикабызда андый проблема булырга тиеш түгел. Безнең югары уку йортында инде 10 елдан артык Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эшли. Җиде ел элек беренче ислам финанс продуктлары әлеге Үзәктә эшләп китте дә.

Ислам финанс учреждениеләренең бухгалтерлык учеты һәм аудиты белән шөгыльләнә торган халыкара оешма – AAOIFI бар. Хәзер Россиядә AAOIFI тарафыннан сертификацияләнгән 10 белгеч санала, шуларның 8 е – Татарстанда, 6 сы – Диния нәзарәтендә.

МЕНДӘР АСТЫНДА УННАРЧА ТРИЛЛИОН СУМ

– Белгечләр, күрәсең, финанс продуктларын эшләү һәм гамәлгә кертү өчен генә түгел, ә аларны контрольдә тоту өчен дә кирәк?

– Һичшиксез шулай. Финанс схемаларының эшен контрольдә тотарга кирәк – яклар арасында килешү әзерли башлаганнан алып тышкы ислам аудитына кадәр. Мәсәлән, хәләл казылык өчен рецептура эшләү һәм тиешле чимал белән тәэмин итүчеләрне сайлап алу гына җитми, аны җитештерүне тикшереп торырга да кирәк, ул җәмгыять исеменнән вакыт-вакыт: «Әйе, казылык дөрес эшләнгән, һәм шулай ясала да», – дип хәбәр итеп торырга тиеш. Хәләл финанслар белән дә эшне шул тәртиптә оештыру зарур.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә моның өчен тиешле компетенциягә ия белгечләр бар. Гомумән, республикада хәләл продуктларның 90 %ына кадәр алар тарафыннан сертификацияләнә һәм бу продуктларга аудит үткәрелә.

РЕСПУБЛИКАДА ХӘЛӘЛ ПРОДУКТЛАРНЫҢ 90 %ЫНА КАДӘР ТР МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ ТАРАФЫННАН СЕРТИФИКАЦИЯЛӘНӘ ҺӘМ БУ ПРОДУКТЛАРГА АУДИТ ҮТКӘРЕЛӘ

– Финанс продуктлары санын үстерү һәм аларның һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүдән тыш, Татарстанда ислам банкингы үсешенең нинди юнәлешләрен күзаллыйсыз?

– Бүген Татарстанда урта һәм кече бизнес бик актив, даими үсештә. Республика халкының якынча яртысы – тумышы белән татарлар, алар диндар мөселман булмаса да, исламга тартыла. Әгәр аларга хуҗалык эшчәнлегендә (лизинг контрактлары, кредитлар һ.б.) шул ук хакка шундый ук, ләкин күңелләренә якын рухтагы финанс продуктлары тәкъдим ителсә, андыйлар бик рәхәтләнеп ислам кагыйдәләренә ярашлы кредитларга күчәчәк, дип күзаллана.

Халык теле белән әйткәндә, мендәр астында яткан акчаларны җәлеп итү мөмкинлеге дә бар. Элек бит Россиядә мөселманнарның үз акчаларын инвестицияләү һәм саклау чаралары юк иде. Асылда, акчаларны, инфляциядән булса да саклап калу өчен дип, гадәти банкка кертем итеп процентка салырга ярамый. Хәзер мондый мөмкинлек барлыкка килә. Ә РФ Хөкүмәте белгечләренең якынча исәпләвенчә, мөселманнарның «мендәр астында» дистәләрчә триллион сум ята ала.

Әйткәнемчә, гади гражданнар өчен хәләл финанс продуктлары гадәти банкингка караганда әлегә бераз кыйбатрак, тик бер-ике елдан соң бу өлкәдә гадел көндәшлекне үстереп, без гади кулланучы өчен кулай бәяләргә һәм шартларга ирешәчәкбез.

Мин киләчәккә оптимизм белән карыйм.

ЭЛЕКТРОКАР ЗАРЯДКАЛАРЫ, АКЫЛЛЫ ХИСАПЛАГЫЧЛАР ҺӘМ КОШЛАРНЫ САКЛАУ

«ЧЕЛТӘР КОМПАНИЯСЕ»НЕҢ ИМПОРТКА АЛМАШ ЭШЛӘНМӘЛӘРЕ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯНЫ НИЧЕК ҮЗГӘРТӘ

Илебездә яңа шартлар урнашканчы ук, илнең энергетика системасы зур үзгәрешләр кичерә башлаган иде, бүген исә импортны алмаштыру гаять әһәмиятле процесска әйләнде. Татарстанда бу сынаулар каршында җавап тотарга әзерләр: «Челтәр компаниясе» АҖ ярдәме белән республикада электр энергетикасы тармагы өчен инновацион эшләнмәләр җитештерү һәм аларны гамәлгә кертүне күздә тоткан тулы бер кластер корыла.

Әйтик, сүзне электр белән йөри торган машиналардан башлыйк. «Челтәр компаниясе» генераль директоры Илшат Фәрдиев киләчәкнең алар кулында булачагына ышана. Әлегә электрокарлар безнең урамнарда гадәти күренеш булудан бигрәк, нииндидер экзотика дип кабул ителсә дә, Татарстанда аларның саны даими арта бара: 2021 елда 80 электромобиль булса, 2023 ел ахырына 700 дән артык машина теркәлгән.

Шул ук вакытта бу машиналарга корылма бирү инфраструктурасы кирәк. Һәм «Челтәр компаниясе» юлларны тиз электр корылмасы станцияләре (ЭКС) белән тәэмин итү юнәлешендәге зур инвестиция проектын гамәлгә ашыра. Шул ук вакытта электр корылмасы станцияләре җитештерү тармагында Россия базарының якынча 40 %ы бүген Татарстан кулында. «Челтәр компаниясе» белән хезмәттәшлектә Яшел Үзән районында E-PROM һәм «Энергоразвитие» заводлары заманча ЭКС җитештерү белән шөгыльләнә. Бу компанияләр ясап чыгарган станцияләр бер үк вакытта ике электромобильгә кадәр электр корылмасы алырга мөмкинлек бирә (өч төрле розеткага көйләнгәннәр). Яшел Үзән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясендә урнашкан бер E-PROM цехы гына да электр корылмасын тиз бирә торган 500 станция һәм акрын эшли торган 2000 нән артык станция җитештерә.

ЭКСлар шул исәптән яңа М-12 трассасында да урнаштырылган, аларны якын арада файдалануга тапшыру планлаштырыла. Төбәкара трассаларда электр корылмасы бирү инфраструктурасы барлыкка килү, энергетиклар фикеренчә, машина йөртүчеләрдә электрокарлар

Фотолар «Челтәр компаниясе» АҖ матбугат хезмәте тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

сатып алырга кызыксыну уятачак, чөнки ЭКСлар аларга артык борчылмыйча юл йөрү иреген тәэмин итәчәк.

Энергетиканың бүген импортка алмаш җиһазлар актив кертелә торган тагын бер тармагы предприятиеләргә һәм шәхси йортларга «акыллы хисаплагычлар» урнаштыру белән бәйле. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: 2020 елдан федераль законнар энергетика субъектларына электр энергиясен исәпкә алу эшен нәкъ менә интеллектуаль приборлар ярдәмендә алып барырга куша. «Челтәр компаниясе» бүгенгә Татарстанда 400 меңгә якын «акыллы хисаплагыч» урнаштырган, шуларның 333 меңе (бу республикадагы исәп-хисап приборларының гомуми саныннан 39 % тәшкил итә) – предприятиеләрдә һәм шәхси йортларда. Кулланучыларны мондый приборлар белән 100 %ка тәэмин итүне 2035 елга төгәлләү планлаштырыла.

«Челтәр компаниясе» Татарстанда җитештерелә торган хисаплагычлар белән эшли. Шул ук «Промэнерго» предприятиесендә, мәсәлән, бүген интеллектуаль исәп-хисап приборлары җыюның тулы циклы оештырылган, компания, республика ихтыяҗларын канәгатьләндереп, продукциясен күрше төбәкләргә дә җибәрә.

Электр хуҗалыкларын акыллы приборлар белән җиһазландырудан һәркем – энергетиклар да, кулланучылар да ота. Яңа хисаплагычлар белән җиһазландырылган коттедж поселокларында яшәүчеләр бу җәһәтләрдән канәгать. Хәзер интернет челтәрендә аларның шәхси кабинетлары бар, анда электр чыгымнарын күзәтеп барырга мөмкин, айлык күрсәткечләрне дә биреп торырга кирәкми. Өстәвенә, яңа приборларны алыштыру һәм эшләтүне «Челтәр компаниясе» тулысынча үзе башкара.

Үз чиратында энергетиклар да инновацияләрдән үзләренә өстенлек ала: электр бүлү челтәрен технологик яктан күзәтү мөмкинлеге арта, өзекләкләр килеп чыкканда төзәтү сроклары кыскара, ә ашыгыч очракларда электрны тиз генә аеру мөмкинлеге туа.

«Челтәр компаниясе» белгечләре импортны алыштыру юнәлешендә хәзер эшли торган тагын бер проект үзебездәге предприятие («Татарстанның электр тапшыру кабельләре арматурасы» – 6–35 һәм 110-500 кВ лы югары көчәнешле кабель арматурасы җитештерү заводы) җитештергән «СКАТ» кабель муфтасын монтажлаудан гыйбарәт.

Көнбатыш компанияләре Россия базарыннан киткәч, илебездә һавадан уздырыла торган чыбыклар һәм изоляцияле кабельләр челтәре өчен арматура ясау ихтыяҗы барлыкка килде. Ә аларны җитештерә торган җиһазлар шактый катлаулы. Әмма Татарстанның «Энергоинновация» ҖЧҖ продукциясе – «СКАТ» муфталары базарга шактый тиз керде һәм белгечләр тарафыннан хупланды. Идеядән алып әзер продукцияне эшләү һәм чыгара башлау өчен бер елга якын вакыт таләп ителде. Республикада җитештерелгән «салкын» тышлыклы кабель муфталары чит илдә эшләнгәннәреннән шактый арзанрак, шул ук вакытта монтажлау да җиңелрәк, чөнки бу процесска махсус инструментлар таләп ителми.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Россия базарында моңа кадәр андый җиһазлар җитештерә торган ике җитештерүче эшләп килде. Әмма Татарстанның үз җитештерүчесе пәйда булу республикада кабель-һава линияләрен ясау вакытын кыскартырга мөмкинлек бирә. Хәзер «Челтәр компаниясе» Казанда 110 кВ көчәнешле линияләрне монтажлаганда яңа муфталарны актив куллана.

Җирле инноватор җитештерүчеләрнең ярдәме компаниягә челтәрләрдә электр энергиясен өзмичә генә эшләргә туры килгәндә дә кирәк. Мондый тиңсез эш ысулын безнең энергетиклар илебездә беренчеләрдән булып гамәлгә кертте. Әмма 35000 В ка кадәр көчәнеш булганда, электр тапшыру линиясендә эшләү өчен, саклану чаралары бик ышанычлы булырга тиеш. Бүген белгечләрдә мондый кирәк-яраклар бар: «Челтәр компаниясе» ярдәмендә «Эрвольт» ҖЧҖ һәм «Сектор-Энерго» ҖЧҖ натураль латекстан перчатка һәм җиңсәләр, күмәк саклану чаралары, изоляцияләнгән траверсалар һ. б. чыгара. Ә «Автодор-Моторс» ҖЧҖ (КАМАЗның рәсми дилеры), Россиядә бердәнбер җитештерүче буларак, электр көчәнешле урыннарда эшләр өчен автогидрокүтәргечләр ясый.

Игътибарга лаек бер факт: импортны алыштыра торган эшләнмәләрнең берсе («Челтәр компаниясе»нең «Чистай электр челтәрләре» филиалы белән «Эрвольт» ҖЧҖнең уртак җимеше) күптән түгел Россия кошларны саклау союзында кызыксыну уятты. Сүз 10 кВ лы һава линиясенең арадаш терәкләрендә электр чыбыкларын эләктерү өчен кулланыла торган изоляцияле ТИ-1 траверсасы турында бара.

Яңа траверсада җитешсезлек күзәтелү мөмкинлеге югары булган проблемалы элементлар – мәсәлән, температура уйнау аркасында еш деформацияләнә торган полиэтилен капкачлар тиз тишелә һәм яшерен дефектлары була торган изоляторлар кулланылмый. Татарстанда эшләнгән траверса ультрашәмәхә нурлар йогынтысында һәм коррозиягә чыдам диэлектрик материалдан ясала, ә аның чагыштырма авырлыгының азлыгы, техник характеристикаларга зыян китермичә, монтажлау процессын җиңеләйтә. Нәкъ менә бик яхшы изоляция үзлекләре аның кошлар өчен куркынычсызлыгын тәэмин итә дә инде.

Гомумән, яңа траверса һава линиясендә эшне шактый җиңеләйтә. 2021 елда инновацияле җиһазлар беренче тапкыр «Челтәр компаниясе»нең «Чистай электр челтәрләре» филиалындагы Әлки район электр челтәрләрендә урнаштырылды, һәм, белгечләр сүзләренчә, бу җиһазларга карата шикаятьләр булмый. Хәзер «Челтәр компаниясе» Кама аръягы филиалының һава линияләрендә ТИ-1 траверсасын монтажлау эшен дәвам итә.

«Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев республика җитештерүчеләренең Яңа Турадагы сәнәгать мәйданчыгындагы эшләнмәләре белән таныша.

«АЛЕКСЕЕВСК» СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ: ОЛЫ ЮЛЛАР ЧАТЫНДА

Наиля Хайретдинова

Индустриаль сәнәгать парклары – илебезнең икътисади үсеше локомотивлары. Татарстанда мондый парклар йөзгә якын. Шундыйларның берсе – «Алексеевск» сәнәгать паркы. 2021 елның августында ачылган парк инвестиция күләмнәренең үсеш темплары белән сөендерә һәм сәнәгать экосистемасының тизләтелгән үсешенә ачык мисал булып тора.

«Алексеевск» сәнәгать паркының төп өстенлеге – логистика ягыннан уңышлы урнашуы. Ул республиканың үзәгендә, берничә олы юл – М-7, М-5, М-12 һәм яңа трасса – «Европа – Кытай Көнбатыш» халыкара транспорт коридоры чатында урнашкан.

Күзгә күренеп торган тагын бер уңай ягы - Кама елгасында йөк ташу портын төзү проектын тормышка ашыру һәм, әлбәттә, Татарстанның Казан, Яр Чаллы, Әлмәт кебек зур шәһәрләренә якын булуы.

Парк берничә юнәлеш буенча үсә: электр техникасы, азык-төлек, төзелеш материаллары, кабель-үткәргеч продукция, агач күмере, йорт комплектлары җитештерү һәм металл эшкәртү. Парк территориясендә беренче булып үз эшчәнлеген Алексеевск кабель заводы башлый, асылда ул «Алексеевск» сәнәгать паркын оештырып җибәрүче була. Ягъни башта кабель заводы төзелә, ә аннан соң гына парк үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аккредитация ала. Беренче резидент 80 миллионнан артык инвестиция кертә һәм 20 эш урыны ача.

Бүген парк 70 %ка диярлек тулган. Тагын ун яңа резидент белән килешү төзелгән, алар инде үз җитештерү мәйданнарын төзи башлаган. Парк инфраструктурасы яңа резидентларны кабул итәргә тулысынча әзер. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән инфраструктураны үстерүгә 40 млн сум акча бүлеп бирелгән, бу бер километр ярымнан артык юл төзергә, газ кертергә һәм трансформатор подстанциясен урнаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Якын араларда офис бинналары, кафе, арзан бәяле хостелы булган административ комплекс төзү көтелә, анда хезмәткәрләр яки эшчеләр производствода тоткарланган очракта төн кунарга мөмкин булачак.

Паркны үстерүнең генераль планына ярашлы рәвештә, 2028 елга кадәр 225 эш урыны ачылачак, ә инвестицияләрнең гомуми күләме 350 млн сумнан артып китәчәк. Идарәче компания мәгълүматлары караганда, инде бүген үк әлеге акчаларның 250 миллион сумы үзләштерелгән.

Эшче кулларга килгәндә, Лаеш, Чистай, Шуран кебек якында гына урнашкан шәһәр һәм бистәләрдән «Алексеевск» паркына эшләргә килергә әзер кешеләр бар.

Республиканың барлык индустриаль паркларындагы кебек үк, «Алексеевск» паркы резидентлары да, үз предприятиеләре өчен Greenfield* территориясен сайлап, күп өстенлекләргә ия була.

Бу – җирдән түләүсез файдалану да, әзер бинаны арендалау да, инвесторның үз проекты буенча типлаштырылган бина төзи алу мөмкинлеге дә, әзер бина өчен бизнес-ипотека да.

Моңа милек өчен салымны, транспорт салымын түләүдән азат ителүдән, дәүләттән ташламалы займ һәм лизинг, субсидия алудан, электр энергиясенә чыгымнарның бер өлешен каплаудан кергән файданы, шулай ук ташламалы шартларда җир кишәрлеген сатып алу мөмкинлеген өстәгез.

Парк резиденты булыр өчен, Алексеевск районы башкарма комитеты каршында махсус оештырылган комиссиягә мөрәҗәгать итәргә кирәк (бу – җитештерү, бизнес һәм дәүләтнең нәтиҗәле симбиозы үрнәге). Потенциаль резидентларның үсеш концепциясе язылган, кертеләчәк инвестицияләре нигезләнгән, эш урыннары саны, төзелеш мәйданы күрсәтелгән көчле бизнес-планы һәм акчасы булырга тиеш.

Әгәр барысы да тәртиптә икән, җир кишәрлеге торгилардан башка гына биреләчәк: төзе һәм эшли башла!

«Алексеевск» сәнәгать паркының идарәче компаниясе директоры Антон Соловьёв сүзләренә караганда, паркка резидентлар килү динамикасы инде хәзер үк 22 гектарда тыгыз булуны раслый. Шуңа күрә «Алексеевск 2.0» паркының икенче чиратын шундый ук мәйданда һәм якында гына ачу планлаштырыла. Киләчәктә паркның актив үсештә булган маркетплейсларны да үз резидентлары итеп күрүен исәпкә алсак, «Ефәк юлы»нда диярлек урнашкан «Алексеевск» өчен бу бик тә дөрес карардыр.

Фото: alexpark.ru. РЕКЛАМА

* Гринфилд

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

«ТАТАГРОЭКСПО 2024»:

ТӘҖРИБӘ, КАЗАНЫШЛАР, ПЕРСПЕКТИВАЛАР

Биш илдән һәм Россиянең 35 төбәгеннән килгән 250дән артык компания «ТатАгроЭкспо 2024» агросәнәгать комплексы казанышларының VI махсуслаштырылган авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашты.

Күргәзмәнең төп идеясе – тәҗрибә һәм казанышлар белән уртаклашу максатында Россия агросәнәгать комплексының барлык вәкилләрен берләштерү, дип аңлатып үтте Татарстан вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әлеге чараны ачканда. Экспозициянең масштабына, эшлекле очрашуларның күплегенә карaганда, чара бик уңышлы килеп чыкты.

Быел күргәзмә беренче тапкыр традицион кысаларын киңәйтте. Экспозиция, «Казан Экспо» күргәзмә үзәге павильоннары белән генә чикләнмичә, галереяда һәм ачык урам мәйданчыгында дәвам итте, анда югары җитештерүчән техника үрнәкләре куелган иде. Анда, сүз уңаеннан, үзебезнең һәм Белоруссиянең танылган предприятиеләреннән тыш, Кытай фирмаларында эшләнгән үрнәкләр дә урнаштырылды. Кайберен белгечләр карап кына түгел, сынап та карый алдылар, мәсәлән, бер җитештерүче тәкъдим иткән телескопик йөк төягечне.

Авыл хуҗалыгы машиналары һәм запас частьләр җитештерүчеләр Татарстанда 100 берәмлектән артык техника күрсәттеләр. Моннан тыш, экспозициядә селекция өлкәсендәге казанышлар, яңа төр ашлама һәм үсемлекләрне корткычлардан саклау матдәләре, терлекчелек фермалары өчен җиһазлар, токым материаллары, терлек азыгы, ветеринария препаратлары, агросәнәгать комплексының төрле өлкәләре өчен цифрлы чишелешләр тәкъдим ителде.

Күргәзмә кунаклары өчен «ТатАгроЭкспо» – Татарстанның аграр тармагы потенциалы һәм казанышлары, хезмәттәшлек перспективалары турында күбрәк белү мөмкинлеге ул. Түгәрәк өстәлләр, эшлекле очрашулар - форумның мәҗбүри өлеше, ул яктан да күргәзмә бик файдалы булып чыкты. ТР авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре үстергән һәм җитештергән иң яхшы продукция фермерлар ишегалдында күрсәтелде, анда республиканың төрле районнарында эшләгән 129 хуҗалык тәкъдим ителгән иде.

«ТатАгроЭкспо»да беренче тапкыр агрохакатон узды. Аграр югары уку йортлары студентларының биш командасы биредә үз эшләнмәләрен күрсәтте. Шуңа күрә белгечләр, экспертлар һәм потенциаль инвесторлар күргәзмәгә куелган ноу-хаулар арасында киләчәк техникасын һәм технологияләрен күрергә мөмкинлек алдылар. Ә бүгенге тәкъдимгә килгәндә исә, аграрийлар тарафыннан аларга карата кызыксыну зур булды. Өч көн эчендә күргәзмәгә Россиянең 43 төбәгеннән, шулай ук Белоруссия, Мисыр, Монголия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән, Сербия, Төркия, Кыргызстаннан 11 750 кунак килгән иде.

Фото «Проект» ЖЧҖ күргәзмәсен оештыручылардан алынды.

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Киләчәк Уеннары **кайчан** булачак

Кышын **кайда** лимон үстерәләр

Әдәби бәйгеләр **нәрсә** бирә

Фотолар Александр Ефремовтан, «УНИКС» БК матбугат хезмәтеннән алынды

UNICS*: СЕРЛЕ УЕНЧЫНЫҢ ЯКТЫ ХЫЯЛЛАРЫ

Дмитрий Сивков

Банк хезмәткәре, «вакытлыча ялдагы» спортчы һәм Россия баскетболының төп мемологы саналган «УНИКС» уенчысы – менә кемнәр Киләчәк Уеннарында Татарстан командасы данын яклаячак.

Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-паркның киберареналарында ярымкараңгылык хөкем сөрә – бу уенчыларның игътибарын читкә юнәлтмәү һәм уен мониторларындагы сурәтләрнең сыйфатын яхшырту өчен кирәк. Залларның берсендәге 2x2 форматлы баскетбол матчын күрсәткән гаять зур «плазма» каршында озын буйлы өч яшь ир-ат һәм алардан шактый тәбәнәгрәк бер егет утыра. Казанның UNICS фиджитал-баскетбол командасының шулай турнирга әзерләнгән мәле бу. Барысы да бик җитди. Беренче уен инде 21 февральдә үк булачак. Шобага салынган, көндәшләре – американнар.

ХУҖАЛАР ӨЧЕН «УАЙЛД-КАРД»

Фиджитал-баскетбол кагыйдәләре белән мине команданың менеджеры һәм шул ук вакытта резервтагы уенчысы (элегрәк профессиональ спортчы булган, спорт мастерлыгына кандидат – ред.иск.) Алексей Пасечник таныштыра. Командалар 2x2 форматында ярыша икән. Башта, 19 очкога кадәр, PlayStation виртуаль мәйданчыгында NBA уйныйлар. Аннары уен чын мәйданчыкта дәвам итә. Йә көндәшләрнең берсе 39 очко җыйганчыга кадәр, йә җиде минутлык уен беткәнче.

Былтыр Казанда үткән бөтенроссия турнирында безнең команда Киләчәк Уеннарында катнашу хокукы яулаган җиңүчеләр өчлегенә керә алмаган. Дүртенче урында калганнар. Әмма UNICS командасына махсус чакыру – «уайлд-кард» эләккән. Мәсәлән, футболда мондый чакыру ярышларны оештыра торган ил командасына һәрвакыт бирелә.

– Командалар 2x2 форматында ярыша. Башта, 19 очкога кадәр, Playstation виртуаль мәйданчыгында NBA уйныйлар. Аннары уен чын мәйданчыкта дәвам итә, – дип аңлата Алексей Пасечников.



– Сайлап алу уеннарына кадәр безнең диджитал әзерлеккә бер айдан да азрак вакытыбыз калган иде, хәзер исә аңлап һәм төпле итеп әзерләнәбез. Состав та көчәйде, – ди UNICS уенчысы Илья Русаков.

Хәзер казанлылар һәркемгә, шул исәптән үзләренә дә, команданың көзге ярыштагыдан күпкә көчлерәк булуын дәлилләргә җыена.

БАСКЕТБОЛ. ВИРТУАЛЬ ҺӘМ РЕАЛЬ

Спортның бу төренә нигездә профессиональ баскетболчылар килә, һәм аларның төп бурычы – виртуаль мәйданчыктагы уеннарын яхшырту.

– Сайлап алу уеннарына кадәр безнең диджитал әзерлеккә бер айдан да азрак вакытыбыз калган иде, хәзер исә аңлап һәм төпле итеп әзерләнәбез. Состав та көчәйде, – ди UNICS уенчысы Илья Русаков.

Аңа 32 яшь, спорт мастерлыгына кандидат, элегрәк «УНИКС»ның яшьләр командасында һәм дублендә уйнаган. Спорт буенча ике югары белеме бар, әмма банкта административ бүлекнең әйдәп баручы белгече булып эшли. Командадашы 24 яшьлек Шәһрәт Моратхаджаев Үзбәкстаннан. Ул үзләрендә 16 яшенә кадәр илнең җыелма командасында уйнаган. 17 яшендә Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетына укырга кергән, «Тренер» белгечлеге буенча магистратура тәмамлаган. Ул да мастерлыкка кандидат, суперлига командаларында уйнаган, әмма быел травма аркасында вакытлыча ял алган.

Илья PlayStation мәйданчыгындагы NBA уенын былтыр эш барышында үзләштергән, Шәһрәтнең тәҗрибәсе зуррак. Ул сигез яшендә уйный башлаган: залдагы күнекмәләрдән соң спортчылар, компьютеры булган малайның өенә барып, анда виртуаль баскетбол уйный торган булган. Дөрес, Шәһрәт әйтүенчә, анда әллә ни уңышка ирешә алмаганнар. Чынлап торып уйнарга яшь «тренер»лары өйрәткән, алар аны Лёха дип кенә атыйлар.



Шәһрәт Моратхаджаевның тәҗрибәсе зур. Сигез яшендә уйный башлаган.



– Иң авыры геймпадның бөтен мөмкинлекләреннән файдалану өчен вак моториканы эшкә җигү кирәклегенә төшендерү булды, – дип аңлата Алексей Филиппов

ЯШЬ ТРЕНЕР ҺӘМ «АВЫР АРТИЛЛЕРИЯ»

Леха, Алексей Филиппов, хәзер аларның спарринг-партнёры. Ә сайлап алу турнирына кадәр үсмер чыннан да аларның диджитал буенча остазы булган. 15 яшьлек кенә булса да, геймер инде берничә тапкыр халыкара кибертурнирларда катнашкан.

– Иң авыры аларны уен механикаларына өйрәтү, геймпадның бөтен мөмкинлекләреннән файдалану өчен вак моториканы эшкә җигү кирәклеген аңлату булды. Хәзер инде күпкә яхшырак уйныйлар. Шулай да дриблинг белән эшлиселәр бар әле, – дип аңлата, бераз уңайсызлана төшеп, Алексей.

Составны көчәйтүгә килгәндә исә, командага хәзер «авыр артиллерия» кушылган – «УНИКС» клубының үзәк уенчысы Иван Лазаревның буе 210 см, авырлыгы – 105 кг. Иванга 32 яшь, ул команданы яхшы белә, чөнки аны сайлап алу турнирына әзерләүдә катнашкан булган. Иван аларга физик яктан булышыр, дип өметләнә партнерлары, бигрәк тә камбэк ясарга (уен барышын үзгәртергә – ред.иск.) туры килсә.

УҢЫШ ТЕЛӘГЕЗ БЕЗГӘ

Хәер, Иван үзен диджитал ягыннан да шактый тәҗрибәлегә саный. Компьютер уеннарында – Dota 2 һәм башка дисциплиналарда да ничек уйнарга кирәклеген ул яхшы белә.

– Әгәр кемдер, 5х5 гади баскетбол уенында чемпион булучылар 2х2 уенында да тиз генә җиңә ала, дип саный икән, бу бер дә алай түгел. Бу бөтенләй башка уен – динамикасы тизрәк, мәйданы зуррак, гел бик игътибарлы булу таләп итәлә, – ди ВТБ Бердәм лигасы чемпионы.

– Әгәр кемдер, 5х5 гади баскетбол уенында чемпион булучылар 2х2 уенында да тиз генә җиңә ала, дип саный икән, бу бер дә алай түгел, – ди Иван Лазарев.

Әмма команда һәм аның тренеры Руслан Сафин ярдәмендә ул башкаларны тиз арада куып тотарга җыена.

Сүз уңаеннан, Лазаревны рус баскетболының төп мемологы дип йөртәләр, аның шәхси блогындагы мемнары миллионнарча карау җыя. Киләчәк Уеннарыннан да үзеннән шундый «яңалыклар» көтәргәме, дигән сорауга блогер Лазарь:

– Мем – бик ситуатив иҗат бит ул. Нәрсәнең нинди тәэсир тудырасын беркайчан да алдан белеп булмый. Ихтимал, бәлки килеп тә чыгар, вакыйгаларны күзәтеп барырбыз. Барысы да безнең өчен яхшы булыр, дип өметләнәм, – дип җавап бирде.

UNICS командасындагыларның барысыннан да үз көчләренә ышану бөркелә. Үзләренә генә түгел, бер-берсенә дә, командага да ышана алар. Уңышка да өметләнәләр. Спортта ансыз булмый бит. Әлеге команданы турнирның серле уенчысы дип атап була – сайлап алу ярышларында мактанырлык чыгыш ясамаганнар бит, Киләчәк уеннарына «уайлд-кард» буенча гына эләккәннәр...

Андыйларга дөрес бәя бирү кыенрак, шунлыктан көндәшләрен шаккатырырга да мөмкин әле алар. АКШ һәм Сербиядән килгән баскетбол грандлары да әллә ни куркытмый үзләрен. Дөрес, төркемдә Азәрбайҗан командасы да бар әле, киләсе этапка исә өч команда чыгачак... Димәк, өмет бар. Уенчыларның иң изге хыяллары тормышка ашсын, дип телисе генә кала.

КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ 2024

Киләчәк Уеннары – яңа форматтагы спорт тамашасы. Ул спортның классик һәм цифрлы төрләрен бердәм ярыш процессына берләштерә.

Казан

2024 елның 21 февраленнән 3 мартына кадәр

Приз фонды

10 млн $

Катнашучылар

Төрле илләрдән килгән 260тан артык команда

2000 спортчы

КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ – УЛ

5 категориядәге (чакырудагы)

21 инновацион дисциплина

МИRA БӘХЕТ-КОШЫ – УЕННАРНЫҢ ТАЛИСМАНЫ

ХАЛЫКАРА МУЛЬТИСПОРТ ТУРНИРЫ

«СПОРТ» КАТЕГОРИЯСЕ

Спортның классик төрләрен аларның цифрлы аналоглары (видеоуеннар, симуляторлар) белән бәйләп алып бару. Ярышлар футбол, хоккей, баскетбол, скейтбординг, узышлар һәм көрәш буенча фиджитал форматында узачак.

ДИСЦИПЛИНАЛАР

Фиджитал-футбол. Спортчының әзерлеген баскетбол симуляторында да, баскетбол паркетында да тикшерәчәк.

Фиджитал-хоккей. Спортчының әзерлеген хоккей симуляторында да, хоккей мәйданчыгында да тикшерәчәк.

Фиджитал-көрәш. Спортчының әзерлеген консоль уенда да, реаль октагонда катнаш көрәштә дә тикшерәчәк.

Фиджитал-узышлар. Спортчының тизлеген виртуаль тректа да, реаль узыш трассасында да тикшерәчәк.

Фиджитал-скейтбординг. Спортчының әзерлеген компьютер уенында да, скейт-паркта да тикшерәчәк

Виртуаль велосипед ярышы. Спортчылар виртуаль трассада тизлек буенча ярыша.

Фиджитал-BMX. Спортчының әзерлеген компьютер уенында да, фристайл-паркта да тикшерәчәк.

«СТРАТЕГИЯ» КАТЕГОРИЯСЕ

Ярышлар компьютер уеннарының «сугыш аренасы» һәм «стратегия» жанрларында оештырыла. Физик этапта командалар фиджитал-суперфинал – чыдамлылык һәм тапкырлык буенча сынау сериясендә ярышачак.

ДИСЦИПЛИНАЛАР

YOTA ФИДЖИТАЛ MOBA. Mobile Legends: Bang Bang + Суперфинал. «Фиджитал» форматындагы MOBA спортчының MLBB дөньясындагы күнекмәләрен дә, өч уен мәйданчыгының (фиджитал-футбол, лазертаг, VR ритм-симулятор) берсендә оештырылган шоу-матчта чыдамлылыгын да тикшерәчәк.

YOTA ФИДЖИТАЛ MOBA. Dota 2 + Суперфинал. «Фиджитал» форматындагы MOBA спортчының Dota 2 дөньясындагы күнекмәләрен дә, өч уен мәйданчыгының (фиджитал-футбол, фиджитал-баскетбол, лазертаг) берсендә оештырылган шоу-матчта чыдамлылыгын да тикшерәчәк.

Мир Танков + Суперфинал. «Фиджитал» форматындагы MOBA спортчының виртуаль аренадагы күнекмәләрен дә, өч уен мәйданчыгының (фиджитал-футбол, фиджитал-баскетбол, лазертаг) берсендә оештырылган шоу-матчта чыдамлылыгын да тикшерәчәк.

«ТЕХНОЛОГИЯЛӘР» КАТЕГОРИЯСЕ

Катнашучылар техник яктан катлаулы җайланма һәм технологик эшләнмәләр ярдәмендә ярышачак: дроннар узышы, роботлар бәрелеше һәм виртуаль чынбарлыктагы ярышлар.

ДИСЦИПЛИНАЛАР

Дроннар узышы. Төрле команда пилотлары идарә иткән дроннар дистанцияне тизлеккә узарга тиеш.

Роботлар бәрелеше командаларның сугышчан роботларны ясый һәм программалаштыра алу күнекмәләрен күрсәтәчәк.

Спорт программалаштыруы катнашучыларның программалаштыру телләре ярдәмендә алгоритмик бурычларны хәл итә алу күнекмәләрен тикшерәчәк.

Кибатлетика параатлетларның техник реабилитация чаралары белән ни дәрәҗәдә идарә итә алуларын тикшерәчәк.

VR ритм-симулятор катнашучыларны җитезлек һәм төгәллек буенча тикшерәчәк.

Бию симуляторы. Уенчылар экрандагы биючеләрнең хәрәкәтләрен кабатлыйлар һәм очколар алалар.

«ТАКТИКА» КАТЕГОРИЯСЕ

Видеоуеннарда популяр «өч үлчәмле тактик сугыш» жанры белән физик этап – лазертаг аренасын бәйләп оештыру.

ДИСЦИПЛИНАЛАР

CS2 + Лазертаг. «Фиджитал» форматындагы тактик сугыш спортчының әзерлеген CS2 уен галәмендә дә, лазертаг аренасында да тикшерәчәк.

VK PLAY: Warface + Лазертаг. «Фиджитал» форматындагы тактик сугыш спортчының әзерлеген Warface уен галәмендә дә, лазертаг аренасында да тикшерәчәк.

Standoff 2 + Лазертаг. «Фиджитал» форматындагы тактик сугыш спортчының әзерлеген Standoff 2 уен галәмендә дә, лазертаг аренасында да тикшерәчәк.

«ТИЗЛЕК» КАТЕГОРИЯСЕ

Культ дәрәҗәсендәге уеннарны эстафета форматында тизлеккә үтү. Физик этапта командалар фиджитал-суперфиналда – чыдамлылык һәм тапкырлык буенча ярышта көч сынашачак.

ДИСЦИПЛИНАЛАР

Speedrun + Суперфинал. Speedrun спортчыларның культ дәрәҗәсендәге ретро уеннарны тизлеккә үтү күнекмәләрен дә, өч уен мәйданчыгының (фиджитал-футбол, лазертаг, VR ритм-симулятор) берсендә оештырылган шоу-матчта чыдамлылыгын да тикшерәчәк.

ҮЗБӘК
ФИЗИК
2024
ГАИЛӘ ЕЛЫ
ТАТАРИН
МАГАДАН

«Татарстан» журналының махсус проекты

ӨЗЕЛЕП КӨТҮ ТУРЫНДА ЯЗМАЛАР

Февраль – кырыс ай, ирләр, хәрбиләр бәйрәме туры килгән ай. Кырыс булсалар да, көчле затларыбыз безгә мохтаҗ – әти-әни, хатын, дәү әни, апа-сеңел, туганнар мәхәббәтенә. Аларның эчкерсез яратуына. Сине өзелеп көткән гаиләдә була торган яратуга. Бүген без дә сезгә мәхәббәт, гаилә кыйммәтләре һәм хәзерге вакытта еракта булган газизләребез турында язмалар тәкъдим итәбез.

Безнең махсус проектта катнашалар:

1. Марина Смирнова һәм аның **улы – «Татарин»**
2. Зәйтүнә Бакаева һәм аның **оныгы – «Үзбәк»**
3. Гөлнара Мозаффарова һәм аның **ире «Магадан»**
4. Гөлүсә Закирова һәм аның **энесе «Физик»**



Марина Смирнова, сугышчы әнисе

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ

ӨЛКӘН «БУЫННЫҢ» ОЛЫСЫ

Фотолар Марина Смирнова архивыннан

ДҮРТ УЛ ҺӘМ ИКЕ ОНЫК

Бу сөйкемле ханымның, үзе әйтүенчә, «улларының ике буыны» бар. Ике өлкән улы, икесе – кече. Өлкәннәре – Денис һәм Тимурга – 29 һәм 23 яшь, кечеләре – Ваня һәм Илюшага – 10 һәм 7 яшь.

Былтыр сентябрьдә «беренче буынның» олысы махсус хәрби операциягә алынган. Шул көннән бирле Смирновлар гаиләсендәге бөтен кеше Денис өчен кайгыра, аңа шалтырата-яза һәм тизрәк өйгә кайтуын көтә.

Денисның уллары Макар белән Захар да әтиләрен бик сагына.

– Минем дүрт улым һәм ике оныгым бар, – ди, горурланып, Марина.

ТАТАРСТАННАН БЕРДӘНБЕР

– Ул Иваново һава-десант дивизиясенең һөҗүм батальонына эләкте, – ди Марина. – Иваново сугышчылары арасында Татарстаннан бердәнбер булганга, кушаматы, әлбәттә инде, Татарин. Анда беркемне дә исем-фамилиясе белән атамыйлар, кушаматлары буенча гына беләләр.

ПЕШЕРЕНЕРГӘ ЯРАТУЧЫ ШАЯН МАЛАЙ

– Балачагында Денис бик шук иде, – дип сөйли Марина. – Бик креатив хулиган дисәң дә була – һәрвакыт нәрсә булса да уйлап чыгарырга аңа куш инде.

Мәктәптә регби белән шөгыльләнде, Мәскәүгә ярышларга йөрде... Ашарга пешерергә ярата. Аның иң оста әзерли торган ризыгы – томалап пешерелгән итле бәрәңге, аңа гаиләдә барыбыз да мөкиббән китә. Төрле ашлар пешерергә дә бик оста. Без аңа хәтта туган көннәренә дә гел аш-су әзерләү өчен кирәк-ярак бүләк итәбез, китәр алдыннан гына мультиварка белән куандырган идек.

Хәзер Денис еш кына поход шартларында үзе әзерләгән ризыкларның фотоларын җибәрә. Күптән түгел генә тулма пешергән иде, щи-борщларының фотоларын күргәч тә, авыздан сулар килә. Яңа ел фотосурәтләрен җибәргән иде – блиндажда хәтта чыршы да бизәгәннәр, ә менә ризык фотолары никтер юк.

– Яңа елга бернәрсә дә әзерләмисеңмени? – дип гаҗәпләндек. Хәтта бераз куркып та калдык – ничек инде Денис булсын да, бернәрсә дә пешермәсен дә ди!

Ә ул: «Бу юлы командир әзерли, чөнки ул тәмлерәк пешерә», – диде.

ДРУЖОК КУШАМАТЛЫ ПЕСИ БАЛАСЫ

– Ә бит безнең Денис астма белән авырый. Әлеге диагнозны ике яшендә куйганнар иде. Бала чагында елына 4–5 әр тапкыр хастаханәләрдә яттык... Хәтта мәче дә асрый алмадык – буыла иде. Ә аның бездән гел песи баласы алдырасы килде. Хәзер аның өчен бик кайгырып торам, чөнки даими ютәлли. Хәтта үзенең видеоларын төшергәндә дә кадр артында гел йөткергәне ишетелә. Авыру килеш сугышка алуларына әле һаман аптырыйм.

Әле җитмәсә кайдандыр песи баласы да табып алган. Аңа Дружок дип исем кушкан. Ашата, сыйпый, гел үзе белән йөртә... «Кечкенә булса да, тычканнарны шәп тота! Блиндаждагы бөтен тычканны тотып бетерде!» – ди. Анысы яхшы әлбәттә, әмма тычкан булмаудан гына ютәле басылмый шул...

КҮҢЕЛЛЕ ЕГЕТ

– Ул безнең бик күңелле егет үзе. Мәзәк видеороликлар төшерә. Мәсәлән, берсендә бер сугышчы камерага: «Әйткән иде бит әнием, математиканы өйрән, математиканы өйрән, дип. Ә мин өйрәнмәдем. Янәсе, нәрсәгә миңа математика? Нәрсә саныйм инде мин?» – ди. Шулчакта кадрга Денис килеп керә һәм: «Нәрсә-нәрсә, менә патрон санныйсың!» – ди.

Карарга кызык үзләрен. Яшьләр бит әле, шаярышалар шулай, үз күңелләрен үзләре күтәрәләр инде...

ХОДАЙ САКЛЫЙ ҮЗЕН

– Әмма дусларын югалтканда, Денисның күңеле төшә. Миңа шалтырата да, алар турында елый-елый сөйли...

Мин ничек ярдәм итә алам соң? Мондый мизгелләрдә психологка әйләнергә туры килә: озак итеп телефоннан сөйләшәм, юатам, үзен саклавын үтенәм...

Үзебезнең Татаринның ялга кайтуын түземсезләнеп көтәбез инде. Ярты елдан соң җибәрергә вәгъдә биргәннәр иде, әмма әлегә күренми әле.

Дога кылабыз. Ходай саклый үзен.

Гөлнара Мозаффарова, сугышчы хатыны

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ

«СИН – МИНЕКЕ, МИН – СИНЕКЕ»

Фото Гөлнара Мозаффарова архивыннан

«КИЧКӘ КАДӘР, МАТУРЫМ!»

– 2022 елның 21 сентябрендә Илшат мине иртән эшемә кадәр китерде һәм: «Кичкә кадәр, матурым!» – дип саубуллашты. Көндез исә аңа армиягә чакыру килде. 24 сентябрьдә инде ул «Казан ЭКСПО»да иде.

Без инде 2013 елдан бирле бергә, әмма рәсми теркәлмичә, никах укытып кына яшәдек. Безгә бергә бик рәхәт иде, Камилә кызым да аңа күнекте, «әти» дип эндәшә башлады – ул безнең икебезне дә ярата, безнең икебез турында да кайгырта иде. Бергәләп балыкка да йөрдек, урман-күлләрдә дә ял иттек... Бөтен Татарстанны һәм Чувашияне аркылыга-буйга иңләдек. ЗАГСта рәсми теркәлү турында сүз чыккач, мин аңа: «Болай да син – минеке, мин – синеке бит инде», – дия идем... Мин аны, «Москва слезам не верит» фильмындагы кебек, гомерем буе көттем бит, һәм менә ул хәзер янәшәмдә – минеке генә, шундый якын һәм ышанычлы – рәсми теркәлү кирәк тә түгел иде. Телефонда һәрдаим язышып торабыз, шулкадәр күп хәбәрләшүебезгә хәтта яшьләр дә гаҗәпләнә... Бергә булганыбыз өчен мин Аллаһ Тәгаләгә чиксез рәхмәт укыдым. Әмма ул махсус хәрби операциягә киткәч, икебез дә, өйләнешергә кирәк, дигән фикергә килдек.

«ӘЙДӘ ӨЙЛӘНЕШӘБЕЗ!»

– Алгы сызыкка эләккәч, Илшат миңа: «Әйдә өйләнешәбез!» – диде. Мин риза булдым. Чөнки хәзер инде бар нәрсә башкача кабул ителә иде. Йорты, гаиләсе, якыннары сугышчы өчен һәрвакыт беренче урында тора. Моны мин бераз соңрак, сөйгәнем янына баргач аңладым. Әлегә исә ялга кайтуын көтә һәм туйга әзерләнә башладым. «Язылышабыз да Сочига китәбез!» – диде Илшат.

ЗАГСта язылышу көнен билгеләдем, кунаклар чакырдым, Сочига билет алдым, кунакханәдә урын калдырттым – ул ялга апрельдә кайтырга тиеш иде. 21 апрельдә минем туган көнем, 22 сендә язылышабыз, 23 ендә – Сочи! Ура! Түземсезләнеп көтәсе генә калды. Һәм менә беркөнне ул шалтыратты да ялга кайта алмаячагын хәбәр итте.

Әлбәттә инде, күңел төште, мин бөтен билетларны кире бирдем, кунакларга хәбәр иттем, ЗАГСта теркәлүдән генә баш тартырга өлгермәдем. Һәм менә тагын шалтырата: «Кайтабыз. Барысын да кире җайла!» – ди.

«УТЫР, КИТТЕК!»

– Һәм менә ул кайтты. Ярты ел күрешмәгән идек. Бөтенләй башка кеше төсле. Арыган, җитди. Хәрби полициядә взвод командиры, кушаматы – Магадан. Бу Магадан белән ничек сөйләшергә дә белмим. Ул исә: «Утыр, киттек! Мин Казанны шундый сагындым!» – ди. Без элек аның белән гел шулай машинада шәһәр буйлап йөрергә ярата идек. Утырып китүебез булды, элеккеге Илшатым кире кайтты, без кабат бергә – ул – минеке, мин аныкы идек. Бу машинада йөрүебезне кичәгедәй хәтерлим. Калганы – язылышу, туй, Сочи – яктылык тизлеге белән үтеп китте... Һәм менә без инде кабат Илшатны озатабыз.

«БЕЗ ГЕЛ БЕРГӘ БУЛАЧАКБЫЗ!»

– Аннары Илшатым тагын бер тапкыр ялга кайтты. Аннан соң исә мин бардым. Аңардагы бөтен начарлыкны алып китеп, бөтен яхшыны биреп калдырыр өчен – сугышчыларның әниләре, хатыннары, апасеңелләре кадерлеләре янына нәкъ менә шуның өчен бара бит.

«Мин исән-сау кайтырмынмы икән?» – дип сорады ул.

«Әлбәттә кайтасың! – дидем чын күңелемнән. – Без гел бергә булачакбыз!» Иманым камил, бер мин генә түгел, һәр сугышчыга якыннары шул сүзләрне әйтәдер. Үзләрен өзелеп көткәннәрен белеп тору алар өчен бик мөһим бит.

Янына баргач, мине аның үзенең сугышчыларына мөнәсәбәте сокландырды. Ул аларга гомерләрен куркыныч астына куярга рөхсәт итми, ничә кешене алып килгән, шулкадәр үк кире алып кайтырга да җыена.

Мин исә аның ялга кайтуын көтәм. Әгәр язын кайтмаса, янына үзем китәчәкмен. Чөнки аннан башка яши алмыйм. Икәү җиңелрәк. Без һәрвакыт бергә булырга тиеш!

OUTVENTURE

Гөлүсә Закирова, сугышчы апасы

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ

СЫНАУ

Фотолар Гөлүсә Закирова архивыннан

ӘТИ-ӘНИ ТЕРӘГЕ

– Энекәшем Илнурның махсус хәрби операциягә китүенә 16 ай. Безнең гаиләне хәсрәтләнергә, берләшергә этәргән вакыт бу. Тулы бер гомер диярсең...

Апас районы Кече Болгаер авылында тыныч кына яшәп ята иде ул. Үз вакытында педагогика университетының физика факультетында белем алды. (Физик дигән позывное шуннандыр.) Армиягә Чечняга җибәрделәр. Яшәү мәгънәсен ул шунда аңлап кайтты булса кирәк – шәһәр дип алгысынмады, әти белән әнигә терәк булам, диде. Кап-кара чәчләренә аннан кайтканда ук беренче кырау төшкәндәй булса да, авылында тынычлык тапты ул.

«УЛЫМ КИТТЕ. 23 ОКТЯБРЬ»

Корал, азык-төлек, машиналар һәм кая киткәнен бигүк чамалап бетермәгән егетләр белән тулы өч состав поезд китте ул чакта. Авылда әни елап калды. Тәрәзә төбендәге гөлләрне сыйпый-сыйпый, күзләре арыганчы сагышланган (соңыннан, әле яз көне өй юганда күреп алдык, тәрәзә янындагы диварга: «Улым китте. 23 октябрь» дип язып та куйган...) Әти бер кочак гәҗит-журнал алдыра, үзе дә сугыш ятиме – әчтән сызды. Инсульт кичергәнгә, аяклары кинәт йөрмәс булды, аны хастаханәгә алып барырга туры килде. Ә энекәш шул арада мобилизацияләнгәннәр тупланган ЭКСПОдан хәбәр итә: китәргә приказ чыкты, ди...

Ничек инде? Өч кенә көн бит әле, бер ай хәрби өйрәнүләр булырга тиеш түгелме? Әле документлары да эшләнеп бетмәгән, аягында авылда пычкыга эләгеп җәрәхәтләгән ярасыннан да кан саркып тора. Туганнар, берләшеп, юлга кем нәрсә ала – бүлештек тә, ЭКСПОга очтык. Саубуллашыр өчен ярты сәгать вакыт бирделәр.

ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ

Тантаналы озаттылар. Оркестр уйнады. ЭКСПО каршындагы мәйданда балалар, ирләре киткән хатыннар, аналар һәм якыннарын озатканнар елашып калды. Салкын иде. Кар төшә башлаган көннәр, суык җилекләргә үтте. Шулчак кызымның: «Минем «Татар кызы» конкурсы, әнием. Калфакларны чигәргә булышмассыңмы?» – дигән сүзләрен ишетеп, күзләр ачылып киткәндәй булды. Тормыш дәвам итә, сынарга ярамый кирәк дигән сигнал. Чигәбез. Фикерләр бер рәткә салына: энекәшнең хәл ителми калган эшләренең очына чыгасы бар.

Эшләнми калган документлар, исәп-хисап счетларын, жетонын барларга хәрби прокуратура ярдәм итте. Кешечә аралаштылар, шунда ук кирәкле урыннарга чыгып, барладылар, юлладылар.

«АПА, БАР ДА ЯХШЫ!»

Аннан төш кебек кенә. «Апа, бар да яхшы. Әниләргә дә шулай дип әйт», – дигән хәбәрләр белән юанып яши башладык. Бер юлы: «5 чакрым ераклыкта, яңгыр, юлсызлык... Окоптан ләмгә батып кайтабыз, салкын елгада юынабыз инде, киемнәр киптерергә урын юк...» дигәнен ишетеп, моннан гуманитарка юллауны карый башладык. Виталий атакайга (Виталий Беляев) нык рәхмәтле без, әле башкалар оешырга өлгергәнче үк, ул алгы сызыктагы егетләргә ярдәм ташыды. Тартма-тартма ризык, киемнәр, кирәк-ярак төяп җибәрдек. Энекәш алды! Аннан... госпиталь. Ярый исән дип юандык...

АЛГЫ СЫЗЫКТА

Җәй башында алгы сызыкка керттеләр. Анда алты ай булдылар. Яңа елга, ниһаять, тынычрак урынга чыктылар. Сөендек. Андый чакларда акча юлларга тырышабыз. Киемнәр, спальник, дарулар, телефонга гына түгел бит – генераторга, бензинга, газ баллоннарына, җылыткычларга... Акча дигәннән, анысын юллауның үз тәртибе. Базарларда картадан акча алып бирүчеләр хезмәте барлыкка килгән. Сумманың 5-10 процентын биреп калдырасың. Берсендә шулай әйткән номерга юлладым. Барып кына җитми бит. Егетләр базарда иркенләп йөри алмый – көттеләр-көттеләр дә киттеләр... Безнеке акчасыз калды инде дип үрсәләндем. Кичкә шалтыраттылар тагын: монда сугыш законнары, акчаны урлау юк, башка егетләр аша биреп җибәргән...

ИЛ БЕЛӘН

Гыйнварда өч атна хәбәрсез булды. Укымаган дога калмады. Хәбәрсез югалучыларны һәм һәлак булучыларны барлаучы бер егетнең телефонын бирделәр. Тик номерын җыяргa кул бармады. Бәхеткә, өметләнеп көткән СМС килде – «Физик исән!» Ул көнне туганнар чатында шаярулар, сөенеч! Ике көннән тавышын да ишеттек. Бәхет өчен күпме кирәк?

Елдан артты... Авылга – әти белән әни янына кайтып кар көрәгәндә, энекәш тә безнең белән төсле. Энекәш ил белән. Сөйләшүе дә ирләрчә аның хәзер. Элек гадәти булган һәр нәрсәнең кадере артты.

Безнең сынау дәвам итә...

Зәйтүнә Бакаева, сугышчы дәү әнисе

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ

«НИК БЕР ЗАРЛАНЫП КАРАСЫН»

«ЯБЫККАН...»

– Раушанның исәнлеге өчен һәр көн дога кылам, Аллаһтан сорыйм, – ди Зәйтүнә апа Бакаева. – Әле менә ялга кайткан иде, 6 нчы гыйнварда яңадан китте. Ике атна безнең белән булды. И балакаем, ябыккан. Ник бер зарланып карасын. «Барысы да әйбәт, әби, борчылма», – дип кочаклады. Мин инде аңлыйм: шулай безне тынычландыра. Кечкенәдән шундый булып үсте. Әрләсәң дә, елмаер иде. Артык тәрбияле ул.

Биектау районы Дөбъяз авылы егете Раушан Рәхмәтов мобилизация башланган көннең беренче атнасында ук военкоматка чакырыла.

Бүген Раушанга 25 яшь. Өч яшьлек кызы үсеп килә. Әнисе, җәмәгате, бертуган ике энесе – барысы да зарыгып Рушанның кайтуын көтә. Һәм дәү әнисе Зәйтүнә апа да. 75 яшен тутырган дәү әни тормышта күпне күргән: бөтен тормышын Үзбәкстанда калдырып, Татарстанга күченү, дүрт кызын аякка бастыру... Аннан җиде ел урын өстендәге ирен караган. Һәм менә яңа сынау – кадерләп үстергән оныгын махсус хәрби операция зонасына озаткан.

УКЧЫ ЕГЕТ

Раушан Рәхмәтов алты яшенә кадәр Үзбәкстанның Бохара шәһәрендә яшәгән. 2004 елда гаилә Татарстанга кайтырга карар кыла. Вакытлыча гына дип дәү әнисе янында калган Раушан Дөбъязда үсә. Урта мәктәптән соң, Арча педагогика көллиятенең музыка бүлеген тәмамлый.

– Оныгым бик матур җырлый, – диде Зәйтүнә апа. – Бала чагында бер дә ялындырып тормады: «Әйдә, улым, җырла», – дигәч, рәхәтләнеп көй суза иде. Аннары инде бик җырламый башлады. Кыенсыну барлыкка килдеме шунда. Әнә хәзер фронтта җырлыйлар икән. Күрәсең, сагынуларын шулай басалар...

Раушан – армиядә булган егет. Хабаровск краенда мотоукчылар дивизиясендә хезмәт иткән. Шунлыктан мобилизация башлангач ук, военкоматка чакырулары гаҗәп түгел.

Фотолар Зәйтүнә Бакаева архивыннан

«ЯРАЛЫ КИЛЕШ ТӘ ГОСПИТАЛЬГӘ БАРМАГАН»

Ноябрь аенда МХО зонасындагы егет яралана. Дошманга һөҗүм иткәндә, снаряд кыйпылчыклары сул аягына эләгә. Яралы солдатларны тиз арада госпитальгә алып китәләр. Ә Раушан баш тарта. «Дусларымны ташламыйм», – ди. Нәтиҗәдә, унбер көннән, сугыштан чыккач кына, аягыннан снаряд кыйпылчыкларын алалар. Әле анда да госпитальдә ятып калмый. Аягындагы җепләрне частька кайткач, берничә көннән генә алалар.

– Алай йөрергә ярамый бит, әгәр аягында гангрена башланса?! – дидем, аптырап.

Зәйтүнә апа баш кына чайкады:

– Без ул хакта белмәдек тә. Ул аны монда кайткач кына сөйләде. Аллаһы Тәгалә саклаган инде балакайны...

ХӘРБИ БҮЛӘК

Раушан әнә шул чактагы батырлыгы өчен бүләкләнергә тиеш икән. Үзе турында уйламыйча хезмәттәшләрен ташламаган егет, әлбәттә, аңа лаек! Дөрес, Зәйтүнә апа хәрби бүләкнең исемен төгәл белми.

– Шушы арада килеп җитәргә тиеш, хәбәр итәрбез, – дип кенә әйтә алды.

Зәйтүнә апа яшерми: оныгы белән чиксез горурлана ул. Армия сафларында булганда да командирыннан рәхмәт хатлары килеп торган.

– Раушан белән телефоннан сөйләшәсезме? – дим.

– Сирәк. Миңа иң мөһиме – аның сау-сәламәт булуы. Улым, әниеңә шалтырат, дим. Мин карт кеше, кайчакта ишетми дә калам. Фирүзә кызым көн саен шалтырата, гаиләсе белән Казанда яши ул. Безнең сөйләшү иң беренче Раушан турында була: хәбәре бармы, без җибәргән посылкалар барып җиткәнме... Ятсак та, торсак та уйда бары Раушаныбыз гына. Исән-сау гына булсын инде...

Дөбъяз халкы елдан артык фронтка кирәкяраклар әзерли икән. Токмач та кискәннәр, йон оеклар да бәйләгәннәр. Хәзер исә махсус операциягә маскировка өчен ятьмә үрәләр. Зәйтүнә апа да көн саен шулар арасында. Оныгының исән-имин кайтуын зарыгып көтүче дәү әнинең бармаклары ятьмә үрсә, күңеле нәрсә уйлый икән? Хәер, ул аны безгә әйтмәячәк, чөнки Зәйтүнә апа кайгы-борчуларын кешегә сөйләргә күнекмәгән...

Фото: Лилиана Вәлитова

«МАКСАТЫМ – ТӘҖРИБӘМНЕ УРТАКЛАШУ...»

...Буадан кайтыр юлга кузгалдык. Башта бер сорау: ике-өч сәгать аралашкан әлеге героемны кайсы яктан ачарга? СССР Югары Советы депутаты, икътисад фәннәре буенча докторлык диссертациясе яклаган галим, бөлгенлек дәрәҗәсендәге колхозны аякка бастырган рәис, тулы бер хосусый завод төзегән җитәкче, бакчачы, блогер... Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов белән әңгәмәгә әзерләнгәндә, боларның барысы турында да өйрәндем. Ә баксаң, Мөхәррәм абый эчке бер тәрбиягә ия, хатын-кызга хөрмәт белән караучы кайгыртучан ир, чын фәлсәфәче дә икән әле...

Руфия Фазылова

КОЛХОЗ РӘИСЕ

Узган ел Буа районының Яңа Тинчәле авылында булырга туры килде. Шул чагында җирле халыктан: «Мөхәррәм абый эшләтте», – дигән сүзне берничә тапкыр ишеттек. Югыйсә инде 40 еллап вакыт узган, ә биредә колхоз рәисе булып эшләгән Мөхәррәм Мөхәммәтҗановны һаман да хөрмәтләп искә алалар.

Яңа Тинчәледәге «Искра» колхозына килгәндә Мөхәррәм Тимергали улына 32 яшь була. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган тәҗрибәле белгеч бу эшкә бөтен күңеле белән алына.

– Мин үз колхозымда коммунизм ясаган идем. Әгәр СССР таркалмаса, хыял-максатым чын мәгънәсендә тормышка ашкан булыр иде. 1986 елда ук колхозның мөлкәтен 124 пайчыга бүлеп бирдем һәм халык хосусый милек нигезендә эшли башлады.

Мөхәррәм абый шул чагында ук кешеләрнең бары үз мөлкәтенә генә сакчыл караштa булуын яхшы аңлый. Нәтиҗәдә «Искра» колхозы иң артта сөйрәлүчеләрдән иң алдынгылар сафына чыга. Алдынгы карашлы рәисне 1987 елда Татарстанның Колхозлар советы рәисе итеп сайлыйлар.

ЮГАРЫ СОВЕТ ДЕПУТАТЫ

Яңа Тинчәленең гади бер колхоз рәисе белән (хәер, болай дип әйтү хата, Мөхәррәм абый 1988 елда икътисад фәннәре буенча докторлык диссертациясе яклый, аның белеме, активлыгы турында бөтен тирә-якта беләләр) КПССның өлкә комитетында да кызыксыналар. Башкалар кебек тыныч кына эшләми бит, ә ул чор өчен бөтенләй ят булган экология проблемасын күтәрә, заманча эш алымнарын тәкъдим итә... «Үзенчәлекле» колхоз рәисен 1989 елның мартында СССР Югары Советына халык депутатлыгына тәкъдим итәләр. Һәм аны раслыйлар да.

Буа районының кечкенә генә Күл Черкене авылында үскән малай әнә шулай Мәскәүне яуларга китә. Депутат булгач та, Мөхәррәм Тимергали улы рәвеш өчен генә кул күтәреп утырмый, чөнки аның үз фикере, тәҗрибәсе була. Кремльдә, трибунага күтәрелеп, СССР Президенты Михаил Горбачевка тәнкыйть сүзләре белән мөрәҗәгать иткән сирәк депутатларның берсе ул. Мөхәррәм Тимергали улы СССРның таралып баруына борчыла. Аңлашыла ки, татарның риясыз улы илдә барган зур үзгәрешләрне туктатып кала алмый...

ЗАВОД ДИРЕКТОРЫ

Депутатлык эшенә керешкәндә, Мөхәррәм Тимергали улының үз заводы да була. Алга карап эш йөртү нәтиҗәсе, әлеге дә баягы, кеше үзенә эшләргә тиеш дигән фикере шундый зур эш башларга этәрә. Ул турыда Мөхәррәм абый менә болай сөйли:

– «Искра» колхозына рәис булып килгәч тә, шуңа инандым: СССР карабодай игү буенча дөньяда беренче урында, ә кибеттә аны сатып алу бер проблема. «Искра» колхозы складында аунап яткан иске ярма яргычларын күреп алдым. Кулакларны сөрү чорыннан калган җайланмалар иде алар. Шуларны сипләп, төзәтеп җибәргәч, карабодай тарттырып карадык. Эшли булып чыкты! Беренче адымнар әнә шулай булды. Уйламаган җирдән «Искра» карабодай игү буенча фәнни җитештерү системасына әйләнде. Ә 1988 елны карабодай эшкәртү буенча «Зөя» ябык акционерлык җәмгыятен төзедем. Заман белән атлыйсы килде. Бабайлардан калган иске җиһаз белән ерак китеп булмый. Тәвәккәлләп, Германиягә барып, Бюллер фирмасы белән килешү төзеп, заманча җиһазлар кайтарттык. Тик, гөнаһ шомлыгы, шул чорда СССР таркалды, һәм алман эшчеләре яңа җиһазларны сафка бастыра алмый калды. Тулысынча компьютер белән эшли торган заманча заводны үзебезнең Буа егетләре җыеп чыкты. Нәтиҗәдә, республикада карабодай игү буенча зур оешмаларның берсенә әйләндек.

Заводта карабодайдан кала, борчак, солы кебек культуралардан да ярма яралар. Санаулы вакыт эчендә «Зөя» ЯАҖ дистәләгән гаиләне эшле иткән зур предприятиегә әйләнә. Һәм шул чорда Буа шәһәрендә яңа бер урам барлыкка килә. Аны халык бүген дә «Мөхәррәм урамы» дип йөртә. Җитәкче карабодай заводы хезмәткәрләре өчен бушка зур йортлар салдыра. Мөхәррәм абый бүген үзе дә шул урамда гомер итә.

БАКЧАЧЫ

Заманында икътисад, сәясәт белән мәшгуль булган Мөхәррәм Тимергали улы бүген бакчачылык эшенә мөкиббән. Хәер, ул СССР Югары Советы депутаты булганда ук ишегалдына зур кышкы бакча төзеп куйган. Җылылык кертелгән, бөтен шартын китереп ясалган зур теплица ул. Элек монда ел әйләнәсе кыяр-помидор үссә, соңгы елларда яшелчә сезоны апрельдән ноябрьгә кадәр икән. Кышкы бакчада нинди генә экзотик куак, агач үсми! Ә чәчәк, гөлләрне әйтсәң дә юк. Урамда – җил-буран, ә биредә – чын җәй. Могҗиза!

Җәйге бакчага чыккач:

– Мондагы иң карт агач-гөл – менә бу лимон, – диде Мөхәррәм абый. – 1985 елда аны сыекландырылган газ базасының элеккеге директоры Анатолий Захаров биргән иде. Биш төп иде ул, берсе генә үсеп китте. Шулай булгач, бу агачка кырык еллап инде. Бер елга 40–45 лимон бирә. Ул сорты буенча Павлов лимоны булырга охшап тора. Төркиядән Павлово-на-Оке шәһәренә кайтартылган дип укыдым. Өйдә үстерелә торган цитруслар арасында дөньяда иң танылганы. Яз башында күп чәчәк атып, айлар буена бүлмәгә хуш ис таратып утыра. Лимоны өлгергәч тә хуш исе була. Әлеге агачның тагын икенче ягы – үзенең эфир майлары белән һаваны микроблардан чистарта. Лимон агачын үстерергә киңәш итәм. Кешеләргә үсентеләрен күп бирдем, үстерәләр.

Моннан тыш кышкы бакчадагы инҗир, каһвә агачлары да җимеш бирә икән. Мөхәррәм абый аларның һәркайсы турында профессионалларча белеп, тәмләп сөйли...

ТАТАР БЛОГЕРЫ

Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов җитмеш дүрт яшендә социаль челтәрләргә кушылган. Бүген аның ун меңгә якын язылучысы бар. Көн дә яңа пост язып элә, видеолар куя. Язмалары – көнкүреш, тарих, бакчачылык, үзе турында. Теле гади, аңлаешлы, ә иң мөһиме – аларда мәгънә, фәлсәфә бар.

– Ике ел рәттән «Блогер. Татарлар» бәйгесендә җиңүче булдым, – ди Мөхәррәм абый. – Акчалата премиясе дә килеп ирешә. Ләкин минем өчен шунысы сөенечле: олы кешегә игътибар бит бу, канат кую. Мең ярымлап блогер катнашкан бәйгедә җиңү үзем өчен көтелмәгән яңалык булды.

Әлбәттә, Мөхәррәм абый блогерлык эшен социаль челтәрләрдә дан казанам дигән максат белән башламаган. Хикмәт монда тирәндәрәк ята. Якын дуслары белән аралашып утырганда, Мөхәррәм Тимергали улына болай дип тәкъдим итәләр: «Син бик кызыклы тормыш юлы уздың, тарихны яхшы беләсең, берәр китап яз әйдә». Бу фикерне кат-кат уйлый ул: аны кем укыр? Күп дигәндә 500 данә белән чыгарылган китап тузан җыеп ятмасмы? Менә шунда Мөхәррәм абый социаль челтәрләрне өйрәнә башлый. Китапны әле язмаган, ул кайчан эшләнер. Ә интернетта көн саен бер фикер, истәлек белән бүлешеп барып була. Сынау, тәҗрибә өчен генә башлаган эш бер ел эчендә Мөхәррәм абыйны «бөтереп» ала. Көн саен ун-унбиш язылучы өстәлә. Җитмеш сигез яшьлек блогерны бүген Татарстанда бик күпләр белә.

– Өч ел ярым дәвамында ике меңгә якын кыска хикәя (постлар) язылган. Соңгы вакытта мине 4–5 меңнән башлап ярты миллионга кадәр кеше укый. Язмаларның күбесе бакча эшләре турында. Үткән гомер, тарих, гаиләм турында да шактый истәлекләр язам. Язмаларымның барысы да татар телендә. Социаль челтәрләрнең шул ягы да отышлы: һәр язманың датасы, күпме кеше караганы билгеле. Сораулар да күп килә, ягъни әле бу үзенә күрә бер аралашу чарасы да. Әлбәттә, бу миңа шактый зур авырлыклар белән бирелә. Моңа сәламәтлек тә кирәк: еллар буе телефонда көн саен биш-алты сәгать язасың, сызасың... Һәм мораль яктан да язылучыларым алдында зур җаваплылык тоям. Ләкин бер авырлыкка да карамыйча, булган тәҗрибәмне халык белән уртаклашасым килә. Белгәнеңне кешегә бирми китү гөнаһ диелгән бит.

Мөхәррәм Тимергали улы дүрт ел буена социаль челтәрләрдә биреп барган язмаларын алты папкага җыйган. Аларны тематикалары буенча бүлгән. Хыял-максаты – әнә шуларны китап итеп бастыру.

ИКМӘК ПЕШЕРҮЧЕ

Тормышка үз фәлсәфәсе булган кебек, Мөхәррәм абыйның ризыкка да үз карашы

бар. Ул дөрес туклану яклы. Нигездә үзләре үстергән яшелчә, җиләк-җимешне генә ашыйлар. Ит белән сөтне генә сатып алалар.

Мөхәррәм абый көн саен диярлек ипи пешерә. (Безне дә сыйлады, бик тәмле!) 15-20 еллап инде кибеттән ипи сатып алмыйлар икән. Үзенең икмәк пешерә торган кечкенә генә миче бар. Кул хезмәте керми диярлек, электр миче камырны үзе әвәли. Шунысы игътибарга лаек: ипидә чүпрә бик аз күләмдә. Ә менә шикәрне камырга күбрәк сала икән. Социаль челтәрдәге дусларын да ипи пешерергә өйрәткән. Махсус рецепты белән безне дә таныштырды:

– Өч-дүрт аш кашыгы сыек май, бер бокал җылы су, дүрт бокал бодай оны, өч-дүрт кашык шикәр, чама белән тоз, аз гына чүпрә салам да камырны әйләндерергә куям. Машинаның программасы ярты сәгать әйләндерә, ә мин тагын утыз минутка куям. Камырны бер сәгать изсә, ипи тәмлерәк килеп чыга. Чүпрәне аз салам – пакеттагы унбер граммлы коры чүпрәне дүрткә бүләм. Безнең әби-бабайлар әчеткән камырдан ипи пешергән бит. Кешене камыр тазартмый, ә чүпрә тазарта. Шуңа да элек симез кешеләр булмаган.

ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ

Мөхәррәм абый бүген җәмәгате Гөлфия апа белән яши. Хәер, алай дип әйтү бик дөрес тә түгелдер, балалары шул ук урамда төпләнгән. Бу урында шуны әйтү кирәктер: ир белән хатынның икесенең дә икенче никахлары. Мөхәррәм абыйның беренче гаиләсендә – өч кызы, Гөлфия апаның ике улы бар. Ир белән хатынны гомерлеккә бәйләп, уртак кызлары да туган. Ләкин алар икесе дә «балаларыбыз» дип сөйләшә. Алты бала, ундүрт онык – бәйрәмнәрдә бер оя булып җыелалар.

Гаилә турында сүз чыккач, Мөхәррәм абыйның тавышы үзгәрде. Бер мәл хәтта авыр тынлык урнашты. Аннан дәвам итте:

– Беренче гаиләм таркалгач, ике ел кеше рәтендә булмадым. Ир-ат никадәр генә көчле булса да, янәшәсендә хатын-кыз булмаса, ул яши алмый. Андый тормышның кызыгы юк. Адәм баласының иң зур терәге – гаилә, балаларның урнашуы. Ул яктан җаным тыныч: Аллаһка шөкер, дим. Ата-ананың баласы алдында җаваплылыгы зур, чөнки без аларны дөньяга тудыргабыз. Белем бирү, һөнәр сайларга булышу, торак алырга ярдәм итү, туен уздыру – безнең бурыч. Ә аннан соң инде алар үзләре барырга тиеш.

...Мөхәррәм абый белән аралашу мавыктыргыч эчтәлекле бер китап укыган кебек, сөйләшеп туеп булмады. Әле тагын әллә ниләр сорашасы килеп калды. Кайткач тагын бер кат аның социаль челтәрләрен карап чыктым. Гаҗәп кеше, башка сүз юк...

Мөхәррәм Мөхәммәтҗанов блогыннан:

Февраль башы. Чәчүгә әзерлек эшләре башланып килә. Беренче чиратта көздән әзерләнгән туфрак, черемә, ашлама, перекись, марганцовка кебек булачак катнашмаларны барлап чыктык. Туңнары эретелә, составлар уйланыла.

Әйләнә-тирә беренчел хаоска чума. Нәкъ менә шушы көннәрдә көзге муллыкка юл салына башлый.

Әлегә төп рассадаларны ясарга иртәрәк. Тик чәчәкләргә, борыч, баклажанга вакыт инде. Без бүген туфрак катнашмасы ясадык.

Зур савытка (2–3 чиләк чамасы) эрегән туфракны бушатып (бездә җиңел кара туфрак), аңа тигезләп 30–40 г нитрофоска сиптек, бутадык. Аннан соң бер чиләк өлгергән компост салдык. Катнашманы янәдән бутадык. Шуннан соң 5 литр суга 100 г чамасы 3 процентлы перекись водорода салып эретелгән суны сиптек, шуннан соң туфракны ял итәргә, өлгерергә калдырдык.

14–15 градус җылыда катнашма өлгереп, туфракны дезинфекцияләп, орлык чәчүгә әзерләнде. Көздән алынган туфракны кышкы саклауга куйганчы, аңа агач көле сипкән идек. Тик шулай да 25–30 г калийлы ашлама өстәдек.

Даими укучыларым белә, гел әйтә киләм: бу состав безнең шартларга туры китереп ясалган. Көздән туфрак запасы ясамаган кеше кибеттән алынган әзер катнашмаларны файдалана ала. Үренте (рассада) үстерү өчен аның күп төрлесе бар. Тик алар әле үзең әзерләгәнне алыштыра дигән сүз түгел.

Бу беренче адымнар гына. Ходай хәерле еллар насыйп итсен!

ЛӘИС ЗӨЛКАРНӘЙ: «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫ – ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...»

Гел күз уңында булган шәхесләр бар. Аларны һәркем таный, иҗатлары, тормышларыннан хәбәрдар. Ә бар ерак йолдыз кебек серлеләре. Ләис Зөлкарнәй, мөгаен, соңгысына керәдер. Фикер сөреше, иҗаты, яшәү рәвеше – ул бөтенләй үзгә, кабатланмас... Зыялы шагыйрь, талантлы каләм иясе – бүген редакциябез кунагы.

– Ләис абый, исемегез матур, кем кушкан, тарихы, мәгънәсе нииндирәк?

– 1962 дә, Барс елында туган егет мин. Шуңа күрәдер инде, батыр булса да, йомшак күңелле бала булсын дип, инәй татарның арыслан сүзенә фарсычадан Ләис исемен сайлап алган. Өстәвенә, абыйның исеменә дә килешеп тора: Фәис (Фәез – ред. иск.) – Ләис.

Безгә исем кушылган елларда мәдрәсәдә белем алып гарәп-фарсыны су кебек эчкән мулла-абыстайлар исән булган әле. Алар дәрәҗә ягыннан Иж-Бубыйдан бер дә калышмаган атаклы Тымытык мәдрәсәсендә укыган. Әлеге уку йортының абруен чамалау өчен бер генә вакыйганы искә төшерү дә җитә. Җәдитчелеккә һөҗүм башланып, мөгаллимнәрне төрмәләргә япкан елларда, Тымытыкта белем биргән Куштирәк имамының хәлен белешергә Риза казый Фәхретдин үзе Чистай төрмәсенә килә...

Ерак бабалары дөнья көткән басу-болыннар чит җөмһүрият биләмәсендә – Башкортстан ягында калгач, безнең авыл кешеләре 1919 елда Ык елгасының уң ярына күченә. Аңлашыла, совет хөкүмәте заманында салынган авылыбыз Яңа Саскүлдә мәчет төзергә рөхсәт ителми. Шулай да авыл мулла-абыстайсыз тормады. Абыем юл фаҗигасендә һәлак булган 1997 елның җәендә авылга яңа туган кызыбызны да алып кайткан идек. Миңа, абый-апаларыма исем кушкан абыстай Коръән ашына авылның аргы очыннан җәяүләп килеп җиткән иде.

– Шигырь иҗатчының эчке дөньясын чагылдыра, диләр. Сез тормышта да шигырьләрегез кебек тирән кеше – фәлсәфәчеме?

– Эчке дөнья – көндәлеге хисләр белән кайнашу – кызлар бәхете...

Мин үземне тормышта күзгә күренмәс вакыт агышына җәтмә салган, шигырь аулаган мөрит дияр идем.

«...Күлтәгин ташъязмасында балык сурәтле тамга бар...

Ул балык-тамга инде ике мең елдан артык йөзә...»

– 1980 нче елларда әдәбиятка көчле бер дулкын булып килеп кергәнсез. Аннан соң ничектер югалдыгыз кебек. Әллә инде ялгышаммы?

– Тәүге хикәяләрем 1977 елда «Идел» альманахында дөнья күрде. Ә беренче китабыма кергән күп шигырем исә мәктәп елларында ук язылды. Иҗатымны хикәяләр белән башласам да, Язучылар берлеге каршындагы аксакаллар шурасы киңәше белән нәшриятка шигырь китабымны тапшырдым. Шул китап белән 1984 елның 11 нче

Фотолар Ләис Зөлкарнәйнең гаилә архивыннан

июнендә СССР Язучылар берлегенә кабул иттеләр.

Мин югалмадым. Күләмле шигъри әсәрләр иҗат итәргә ниятем бар иде. Әмма күнегелгән өслүбләрдә покосны киң алдырып булмый, сулыш тиз кысыла, калыпны, ритмны үзгәртми генә һич үзгәрми... Ә миңа шигырьдә симфония иҗат итәргә кирәк иде! Дала буйлап атта җилдергән, әле кушаяклап чапкан, әле сак кына атлаган өслүб кирәк иде миңа.

Эзләнә торгач, мин аны шәрык шигъриятендә таптым: егерме дүрт иҗекле гарузны өч сигезлегә сындырып, дүрт иҗекле юллардан унике иҗеклегә кадәр ритмны бозмый гына үзгәрә алучы, дастан кадәрле дастаннар иҗат итәрлек үтә сыгылмалы, музыка сыман агылган өслүбем белән күләме «Идегәй» дастаныннан калышмаган эпик әсәрләр иҗат иттем. «Нугай йорты», «Идегәй итеге», «Татар җөе» белән бик теләсәң дә югалып булмас, дип уйлыйм.

– Бүгенге татар әдәбиятына карашыгыз? Аңа нәрсә җитми? «Тукай тукталышы» исемле шигырегездә «Тукайдан соң монда язлар сирәк, Тукайдан соң монда кыш та кыш», – дип язгансыз. Бу фикерегезне аңлатып китегезче. Өметле татар язучыларын, шагыйрьләрен күрәсезме?

– Соравыгызның беренче өлешенә ярым-йорты җавап биргәнче, «Тукай тукталышы»на тукталыйк. Шигырь белән язганны корама сүзләр белән аңлатырга тырышудан да ахмаграк нәрсә юк анысы. Тукай яшен узып киткәч кенә, бөек шагыйрьне аңлый башладым кебек. Ә алтмышым җитәрәк «Алтын Урда» дастанын язганда, бәй, моны Тукай әйткән ләбаса дип гаҗәпләнгәнем дә булды:

«Ничек инде
Иле-көне калмасын, ди?!
Тугыз империя
Корган гаярь токымның!..
Әй Рәсәй!
Син ул Алтын Урда станында
Кырыс татар
Ырысы булып
Тукылдың!»

Тукай заманында татарның чын тарихын авыл мәдрәсәләрендә дә өйрәткәннәр... Романовларга багышланган шигырендә «Ошбу илдә азмы хакыбыз?!» дип, күкрәк суга шагыйрь. Университетта профессор Миркасыйм Госмановның Җүчи Олысы хакындагы лекцияләрен тыңламаган булса да, Рәсәйнең Алтын Урда варисы икәнлеген бик яхшы белгән Тукай! Менә шул инде ул – «Тукай тукталышы»...

– Ләис абый, ТР Язучылар берлеге сезне 2024 елга Тукай премиясенә кандидатлар исемлегенә кертте. Белүемчә, әлеге зур исемгә беренче тапкыр тәкъдим ителәсез. Бу сезнең өчен көтелмәгән хәл булдымы? Тукай премиясен алу максаты, хыялы бармы?

– Соңгы айларда баштанаяк яңа китабымны язып төгәлләү һәм аны нәшриятка әзерләү мәшәкатьләренә чумган идем. Шулай булгач, ул турыда уйланып йөрергә вакыт булмады. Әйе, быел Тукай премиясенә кандидатлар исемлегендә мин дә бар. Тик дөресен генә әйткәндә, бу зур исемне миңа бирерләр дип өметләнмим.

– Татар телен һәм Татарстан халыкларының туган телләрен үстерү комиссиясе белән берлектә ТР Язучылар берлеге тарафыннан үткәрелгән соңгы конкурста сезнең «Татар җөе» дип исемләнгән дастаныгыз «Поэма яки шигырьләр шәлкеме» номинациясендә 1 нче урынга лаек дип табылган. Бу уңайдан нәрсәләр әйтә аласыз укучыларыбызга? Дастан кайчан язылды? Аны язарга нинди уйлар этәрде? Гомумән, әдәби конкурс-бәйгеләргә карашыгызны да әйтеп китсәгез иде.

– Моны зур җиңүем дип саныйм. Бу ырудашым һәм якташым Зәки Вәлиди Туганның да Казанны кабат яулап алуы!

Дастан Зәки Вәлидинең «Хатирәләр»е белән үрелеп бара. Башкортстан җөмһүриятен төзүче сәясәтче Зәки Вәлиди Туган Ишембайдагы Көзәннән, мин Бакалы районындагы Яңа Саскүл авылыннан. Арада йөзәр чакрымнар ятса да, ыруыбыз уртак. Катай кабиләсе нигездә чыңгызлы Шибан угыллары булганга күрә, аларны Катай ханнары дип йөрткәннәр. Минем дүртенче буын бабам подпоручик Гомәров, 12 нче кантон оештырылгач, Бакалы районындагы Катай авылыннан Саскүлгә йөзбашы итеп җибәрелә һәм авылдашларым белән бергә 1812 елдагы сугышта французларга каршы көрәшә. 1919 елда Башкортстан хәрби идарә министры Зәки Вәлиди дә, атлы гаскәре белән Харьков фронтында җиңү яулашып, Антантадан ярдәм көткән генерал Деникинны Кара диңгезгә себереп түгешә!

Ләис Зөлкарнәй улы Сөләйман, кызы Мәрйәм белән.

Ләис Зөлкарнәй хатыны Фәридә ханым, уллары Йосыф һәм Дауыд белән.

Дастан 2022 елның апрелендә башланып, 2023нең августында тәмамланырга мәҗбүр булды – бәйге шарты буенча 1 сентябрьгә почта белән редакциягә барып җитәргә тиеш иде...

Зәки Вәлиди хакында күптән инде зур әсәр язарга теләк бар иде. Аның рухы миңа университетка керергә ярдәм итте. Тарихтан керү имтиханында Идел-Урал штаты хакында мәктәп программасында булмаганнарны да сөйләгәч, бишле куйдылар.

Дастанны язарга икенче зур этәргеч – Зәки Вәлиди Туганның «Хатирәләр»е булды. Аны Рабит Батулла тәрҗемә итеп, ике томлы китап итеп бастырып чыгарды.

Әдәби бәйгеләр кирәк дип саныйм. Мин җиңеп чыккан әлеге конкурс ябык иде. Бәйгедә кемнәр катнашканын да белмәгәч, җиңүнең тәме кими икән. Әле менә искә төште: 1994 елда «Идел» журналы оештырган тарихи хикәяләр бәйгесендә, проза мастерлары Ркаил Зәйдулла, Туфан Миңнуллин, Вахит Имамовларны артта калдырып, «Кыргын» исемле хикәям җиңеп чыкты. Соңрак әлеге хикәягә таянып Рәдиф Сәгъди пьеса язды. Тинчурин театрында узган гомер бәйрәмемдә «Кыргын»ның өч күренешен Зөфәр Харисов тырышлыгы белән сәхнәдә куйдылар. Тамашачыларга бик ошады – басып кул чаптылар.

– Ләис абый, сезнең шигърият чагыштыруларга бай һәм анда кулланылыштан төшеп калган, искитмәле матур сүзләр күп. Мондый тел байлыгы каян килә? Сез аларны балачактан беләсезме? Ул сүзләрне көндәлек тормышта да кулланасызмы?

– Мәшһүр шагыйрь Нәкый Исәнбәт туплап, чәчмә урыннарын зәркәннәрчә тезмәгә салган «Идегәй» дастаны – минем өстәл китабым. Анда сез атаган җәүһәрләрнең барысын да табып була.

«Дала исе исәнгерәткән иң хуш исле сүзләр – «Идегәй» дастанында.

Дала җиледәй кискен, кылганнар шавыдай үткен сүзләр – «Идегәй» дастанында...»

– Тормышта үкенечләр булдымы? Булса нинди?

– Иҗатым белән аз гына да таныш укучыларым минем хакта далада туып-үскәндер, язгы кар сулары белән чайкап юган тула паласларын далага җәеп, сары-кызыл лалә чәчәкләре серкәсенә кытыкланып төчкерә-төчкерә мәтәлчек аткандыр, дип уйлыйлардыр...

Ә минем исә даланы күргәнем дә юк...

Әти-әниләр исән вакытта кадерләрен белергә кирәк икән. Яши-яши шуны аңлыйсың. Мин кадерли алмадым кебек. Бик үкенәм хәзер...

– Туган ягыгыз Башкортстан белән элемтә бармы?

– Һәр җәй саен Яңа Саскүлгә кайтып килергә тырышам. Ни кызганыч, анда әти-әни көтеп тормый хәзер.

Туган якка кайту үзе бер тарих. 350 чакрым ара узгач, оеган аякларны язарга дип, Сарлы авылы белән ике арадагы Салкын чишмәгә туктыйбыз. Анда яшьтәш имәнем үсә. Ул мине көтү көткән малай чагымнан ук белә. Кочаклашып күрешү белән, чатыр да корып тормыйча, күләгәнең куе яшел паласына чалкан ятам. Нугай тауның борынгы кодрәте аркама сырпалана. Сөләйман улым учак ягып җибәрә. Сихәтләнеп уянуыма Мәрйәм кызым чәй өлгертә. Әниләренә ияреп, мәтрүшкә, чабыр үләннәре җыеп килергә өлгергән Йосыф белән Дауыд улларым мине чәй табынына кыстый башлый. Чәйләп алгач, Нугай тау кашындагы артышларга хәтле күтәреләбез. Югары менгән саен дөньялар киңәя:

«Әй Нугай Иле!
Әй Шигърият Иле!
Офыклар синдә кузгала, чигенгәләп...»

– Иң зур теләк, максатыгыз?

– Менә шулай туган якка кайткан шикелле Орхон буйларын да күреп, имән кочкандай Күлтәгин ташын да кочып, ерак бабалар рухына шигъри дога ирештерәсем килә.

«Соңгы яуга китә каһан:
Айдалада –
Кам дөңгере...
Сөтен дөрселдәве... –
Им учагы артышыннан...
– Кем дәүләте өчен1
Хәзер тырышам?! – дип,
Күлтәгиннән бирле
Татар
Тар-ты-шы-на...»

ҖИЛӘКЛЕ УЧАК УРЫННАРЫ

Ямгыр белмәс ямчыгол
Ям юлында ям чапкан[1].
«Идегәй» дастаны

Ут телендә сөйләшкәннәр төнлә таулар!
Чатыр таудан хәбәр салса олуг учак,
Далага җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Каравыл таулары берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый кабыначак.

Кабыначак!
Кара диңгезләргә җитеп...
Баешларда күләгәләр сагаюлы:
Тәңренең гүзәл исемнәрен кабатлый,
Җемелдәп кабатлый әнә Нугай Юлы...

Төпсез күккә
Төбәлешкән
Төндегеннән
Мең ел буе төтен бөркеп, очкын өргән
Нугай тирмәләре,
Кыпчак чатырлары...
Киек Каз Юлыннан бер генә кайтаваз:
Учак чатырдавы...
Учак чатырдавы...

Ут телендә сөйләшкәннәр төнлә таулар!
Сүз башлаган
Ак чатырлы
Чатыр тавы...
Ык йортыннан
Туктамышка хәбәр илтеп,
Таң атканчы, таң атканчы Кырымга бар! –
Ямчылардан
«Җем-җем» таулар күпкә җитез, –
Яктылыкны
иярләгән
борынгылар!

Шәфәкъ ястыгына батып...
Чалкан ятып,
Күкнең кыйссасынмы укый Чатыр тавы?! –
Киек Казлар кыйссасының башы гына:
«Учак чатырдавы...
Учак чатырдавы...»

Чатыр таудан хәбәр салса олуг учак,
Таулар гына булсын – гөлтләп кабыначак!
Булмаса тауларың,
Яса өмә!
Өй курган:
Күкләргә якынрак торган борынгылар! –
Даласында күпме мәңгелек өй корган...

«Беттек!» дигәндә дә,
Ачылып киткән дөнья, –
Утлар бөркеп,
Юл күрсәткән кәрван таулар;
Кырчанында кырык буын кәлтә үсеп,
Дәү аждаһа булып җиткән
Дәвран[2] таулар!..

Төпсез күккә
Төбәлешкән
Төндегеннән:
– И Тәңрем! – дип,
Төтен бөркеп, очкын өргән
Нугай тирмәләре, кыпчак чатырлары...
Киек Каз Юлыннан
Бер генә кайтаваз:
«Учак чатырдавы...
Учак чатырдавы...»

Кашлагында Ак чатыры[3] тормаса да,
Ут телендә телгәләнә Чатыр тавы.
Җан ишетә ут телендә эндәшкәнне,
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә,
Актарылып,
Ак чатырын
Чакырганы...

Булган заман
Туктамыш хан
Тауларга да салган оран:
Кара диңгез ярларыннан
Кубарылган[4]
Чатыр Дагы[5],
Унҗиде мең арбаларда
Кубарылган!

Җай Ык буйлап кашлак таулар өя-өя,
Дала үтеп, Чулман – Ыкта тугарылган...
Сай Ык буйлап кантар таулар коя-коя,
Түмән-түмән нугаеның
Иңнәрендә килгән гүя! –

Безнең яклар өчен
Күптән «Чатыра!» ул,
Ак чатыр корырга
Күптән чакыра ул –
Чакыра тау, Чатыра тау! Чатыр тавы.

Җан ишетә ут телендә эндәшкәнне, –
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә,
Ачынудан
Ак чатырын
Чакырганы.

---

[1] Ям, ямчыгол – Алтын Урда, Казан ханлыгы заманнарында почта хезмәте, почта ташучы җайдак.
[2] Давран – дәверләр кичкән, борынгы.
[3] Ак чатыр – хан чатыры.
[4] Кубарылган... – Кара диңгез, Кырым, Төньяк Кавказ якларыннан Туктамыш хан XIV гасыр ахырында үз меңләп нугай татарын Идел-Урал төбәгенә күчерә.
[5] Чатыр Даг – Кара диңгез буендагы тау, Азнакайдагы Чатыр тауның адашы.

Караңгы төн...
Айбалтасы юка иде.
Хәтеренә уйды микән Чатыр тавы:
Ак чатыры бурланланды Йосыф бинең[6], –
Зәһәр иде баш учакның чатырдавы!
Таңнар сизелүгә...
Сүзен әйтте Йосыф!

Хәбәр салды шундук
Таулар телеграфы:
– Хатын-кызның гайбәтендә казынсагыз,
Дуңгызларга калмагае...
Казаныгыз[7]!

Төннең тулай ястыгына кулай ятып,
Якты кыйссанымы ятлый Чатыр тавы? –
Төн уртасы җитеп килә, төн уртасы...
Кыйссаның да инде җитте төп-уртасы:
«Учак чатырдавы...»

Сөен Бикәч җиләк җыйган Чатыр тавы!
Безнең яклар өчен күптән Чатыра син.
Ераклардан танып алып
Чакырасың... –
Туган ягым шәфәгында
«Табын корган» ыру-тамга:
Ил-йорт җыйган Чатырам син...

Илем-көнем сау булмаса,
Хәбәр йөртер тау булмаса,
Сүнмәс өмет –
Өлкәр[8] аша
Күк телендә чакырасың...

Тергезергә ак тирмәне –
Ил-дәүләтең чатырасын!

Күкнең телен онытмаган әле таулар!
Чатыр таудан хәбәр салса безнең учак,
Офыкка җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Шәфәкъ йолдызлары – берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый кабыначак.

Кабыначак!
Җиһан түрләренә җитеп,
Күкләрдә дә
Күләгәләр сагаюлы...
Тәңренең гүзәл исемнәрен кабатлый,
Җемелдәп кабатлый
Киек Казлар Юлы...

Ай лампасын,
Күз чакмаслык
Кыса төшеп,
Күк кыйссасын һаман укый Чатыр тавы –
Киек Казлар кыйссасының инде соңы...
Ак чатырда йоклый алмый яткан Сөен,
Тыңлыйсыңмы, тыңлыйсыңмы? –
«Учак чатырдавы...»

Чатыр тавы... –
Кара диңгез ярларыннан
Кубарылган Чатыр Дагы,
Унҗиде мең арба белән кубарылган!
Дала үтеп,
Ыкка җитеп
тугарылган...
Тауларын да
Үзе белән йөрткән халык...
Алып килгән Кара диңгезен дә
Түмән-түмән алып!

Акчарлаклар төшкән сиңа, Чатыр тавы,
Иләтенә киңлек даулау –
Бар тыкырдавы:
Ак күбекле кылганнарың калгышында, –
Тыңлыйсыңмы? –
Дулкын шыбырдавы!..

Гадәтләреме борынгы вакыттагы:
Акчарлаклар төшкән сиңа, Чатыр тавы!
Кычкыралар,
Диңгезләрдән җил чакырып,
Бу – яхшы фал, ди, аяз күк чатырдавы!..

Ил-көнгә ак җилкән иде
Ак чатырың... –
Акчарлаклар төшкән сиңа, Чатыр тавы!
Безнең яклар өчен күптән Чатыра син,
Ераклардан танып алып
Чакырасың,
Чакыра тау, Чатыра тау! Чатыр тавы.

Җан ишетә үз телендә эндәшкәнне, –
Кайчак Казаннарга җитеп ишетелә
Ил Чатырын[9]...
Ак Чатырын
Чакырганы!

Чатыр тауда ут кузыдай җиләк җыеп
Йөри әле, Сөен,
Синең дә балачак...

Чокыраеп тора учак урыннары... –
Чатыр таудан хәбәр салса хәзер учак,
Офыкка җитеп сибелгән Ык дисбесе –
Шәфәкъ йолдызлары – берсен-берсе
Кабатлый-кабатлый кабыначак.

Кабыначак!
Сары диңгезләргә җитеп,

Кабыначак!
Алып тауларын да үтеп,
Баеш тарафлары һаман сагаюлы:
Кара төндә Нугай Юлын чалымларсың...
Чатырада Ак Чатырны сагымларсың...
Әй сүнмәс өметкәй –
Киек Казлар Юлы!

Ям учагын
Яман яңгыр
Яткыргандыр...

Ям хәбәрен
Ялгыш алган кара яңгыр,
Соңгы ханбикәдән соңгы хәбәр сөйләп,
Канча еллар елый-елый яктыргандыр...

«Беттек!» дигәндә дә
Дөнья яктырганын
Тәкъкә генә түгел инде синең тәкрарлау.
Әй Чатыр тау, Чатыра тау, Чатыр тавы,
Офыклар
синдә кузгала,
чигенгәләп...
Килеп җитте, килеп җитте асыл хәбәр, –
Учак урынында кузлана
Ачы җиләк.

[6] *Йосыф би – Нугай Йортындагы Ык-Чулман тугайларында җәйләүдә йөрергә яраткан Сөембикәнең әтисе.*

[7] *«Дуңгызларга калмагае Казаныгыз...» – кул астында йөз мең гаскәре булып та, сул канат Йосыф би Казанны ни өчен якламаган? «Мәскәүгә каршы төшсәң, үзем гаскәремне сиңа борам!» – дип кисәткән бертуганы Исмәгыйльдәме сәбәп? Әллә гайбәт сазлыгында казынган Казанның үзендәме?!*

[8] *Өлкәр – Иләк йолдызы төркеменең борынгы атамасы.*

[9] *«Ишетелә ил чатырын чакырганы...» – Чулман һәм Агыйдел елгалары арасына таралып, ил-йорт тергезгән Нугай йорты, Казан ханлыгы алынгач та, озак еллар ил-йорт кузларын сүндермичә, «баш күтәргәләп» янып-калгып тора...*

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Дуслык тарихы **ничек** бөтендөнья мирасына әйләнә

«Өченче дөнья» юлбашчылары **кем** хезмәтен өйрәнгән

«Гальгаф» тәхәллүсен алган шәхес **кем** ул

Кышкы киштәдә **нинди** китаплар бар

БЕР ДУСЛЫКНЫҢ НИ РӘВЕШЛЕ БӨТЕНДӨНЬЯ МИРАСЫНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕНӘ ӘЙЛӘНҮЕ ТУРЫНДА

АСТРОНОМИК ПОЭМА

2023 елның сентябрендә Казан федераль университетының Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе (ЭАО) ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде, ягъни аны дөнья тарихының мөһим өлеше дип таныдылар. Әмма «дөнья тарихы» дигән гыйбарә ни белдерә соң? Бу сүзләрдә шул тарихны чынга ашырган кешеләрнең исемнәре яшеренгән. Аларның язмышлары ук, киләчәк буыннарны шаккатырып, рәхмәт хисе белән искә алуга һәм хөрмәткә лаек.

Дмитрий Дубяго



Василий Энгельгардт

1881 елда Пулково обсерваториясендә рус астрономы Дмитрий Дубяго төп астероидлар поясындагы астероид – Диана кече планетасы хәрәкәте теориясенә нигез сала. Якынча шул ук елларда Дрезденда һәвәскәр астроном, чыгышы белән Россиядән булган Василий Энгельгардт та Диананы бик кызыксынып күзәтә. Профессионаллар гына җавап бирә алырлык кайбер сораулары тугач, ул Петербург астрономнарына хат юллый. Дмитрий Дубяго җавап яза, шул рәвешле ике арада хат аша элемтә урнаша. Бу искиткеч дуслыкның башы була.

– Гомумән, фәнни тикшеренүләр барышында бирелә хәзер классика дип саналган күп кенә ачышлар ясала, мәгълүмат туплана, – дип сөйли Юрий Нефедьев.

ҺӘВӘСКӘРЛӘР ҺӘМ ПРОФЕССИОНАЛЛАР БЕРЛЕГЕ

– Энгельгардт исемендәге обсерваторияне ЮНЕСКО исемлегенә кертү турында карар кабул иткәндә, белгечләр, беренче чиратта, уникаль тарихыбыз белән бергә фәнни казанышларны да исәпкә алды, – ди обсерватория директоры Юрий Нефедьев. – Ә әлеге уникаль тарих Василий Павлович Энгельгардт Казан университетына тиңсез астрономик җиһазлар бүләк иткән вакытта башлана.

Юрист белеме алган Энгельгардт, югарыда әйтеп үткәнебезчә, һәвәскәр астроном була (соңыннан профессиональ астроном-күзәтүчегә әйләнә һәм Санкт-Петербург фәннәр акаде-

Александр Ефремов фотолары

миясенә мөхбир-әгъза итеп алына). Хатынының авыруы гаиләне Санкт-Петербургтан күчеп китәргә мәҗбүр итә. Соңрак алар Дрезденда урнашып кала. Кенәз Потемкин-Таврическийның (Екатерина II фавориты буларак билгеле) бертуганының оныгы булган Энгельгардтка шактый бай мирас кала, шуңа ул үзенең Дрездендагы утарында искиткеч обсерватория көйләп куя.

– Әлеге утарда урнаштырылган телескоп характеристикасы ягыннан Европада икенче урында була, – дип сөйли ЭАО инженеры Георгий Ризванов.

Энгельгардтның бу телескоп янында төшкән фотосы хәзер обсерватория музееның бер стендын бизи. 1879 елда Дублинда эшләнгән оптик прибор хәзер обсерваториянең төп бинасы павильонында урнаштырылган һәм Россиянең гамәлдәге иң зур визуаль телескобы булып тора (ә дөньяда мондый телескоплар 26 гына).

Василий Павлович белән Дмитрий Иванович арасында хатлар арлы-бирле Европа гизеп йөргәндә, Дубяго Петербургтан Казанга күченеп, анда университет обсерваториясе директоры, ә аннары Казан Император университеты ректоры булырга өлгерә. Һәм Энгельгардт, өлкәнәеп баруын һәм сәламәтлеге какшавын аңлагач, үзенең тиңсез җиһазларын ерак дусты җитәкләгән университетка васыять итә.

Шул ук вакытта Дубяго шәһәр эчендә урнашкан университет обсерваториясенең үз бурычларын тиешенчә үти алмавын аңлый, чөнки шәһәр лампалары яктысы инде йөз ел элек үк астрономнарга комачаулый. Шуңа күрә асылда Казанга Энгельгардт бүләк иткән яңа фәнни үзәк шәһәрдән 20 километр читтә, Лаврентьево тимер юл станциясеннән ерак түгел урында пәйда була. Соңрак станциясенең исеме Обсерватория дип үзгәртелә.

Василий Павлович Энгельгардт 1915 елда бакыйлыкка күчә. Ул Казанга килергә өлгерми кала.

ПОТЁМКИН МИРАСЫ ҺӘМ ЮГАЛГАН МИЛЛИАРДЛАР

Юрий Нефедьев сөйләвенчә, Энгельгардт обсерваториягә шактый зур акча – якынча 200 мең сум алтын акча да васыять итә. Хәзерге акча белән санасаң, бу миллиардларга тиң, өстәвенә, доллар белән исәпләгәндә.

Сүз уңаеннан, монда тагын бер кызык нәрсәне искә алып китү урынлы: Энгельгардт байлыгының күп өлешен кенәз Потёмкиннан мирас итеп ала. Шуңа күрә безнең обсерваторияне Потёмкин мирасы дип атарга була.

Акча Россия империясе банкларында ята, һәм революциядән соң, әлбәттә, яңа хакимият аларны конфискацияли. Астроном, Россия фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Виктор Абалакин билгеле бер тикшеренүләр үткәрә һәм обсерваториянең икенче директоры Михаил Грачевның (бу вазыйфага Дмитрий Дубяго испан гриппыннан үлгәч билгеләнә) Ленин янына шәхсән баруы, дөнья пролетариаты юлбашчысын бу акчалар фәнгә васыять ителгән бит дип үгетләп, акчаны кире кайтарырга тырышуын сөйли... Тик акчаны обсерваториягә барыбер бирмиләр.

АЙ, МАРС ҺӘМ НАВИГАТОРЛАР

Ләкин Энгельгардт исемендәге обсерваториянең даны фән дөньясында аннан башка да һәрвакыт яңгырап тора. Мәсәлән, Айны өйрәнү программасын монда Дмитрий Дубяго үзе башлап җибәрә, дип сөйли Юрий Нефедьев. Әлеге программа Айның физик либрациясе (тирбәнешләре) параметрларын билгеләү һәм аны үзләштерә башлауны максат итеп куя. Соңрак Айның кире ягын фотога төшергән беренче совет иярченен галәмгә җибәрү барлык галимнәрнең, шул исәптән уникаль биометрик һәм фотографик тикшеренүләр уздырган Казан астрономнарының зур хезмәте нәтиҗәсе була.

Обсерватория музеенда XX гасыр уртасында эшләнгән Ай глобусы тора. Айның кире ягында Мәскәү диңгезен, Лобачевский кратерын күрергә була. Болар барысы да Җир иярчене картасында югарыда телгә алынган тикшеренүләрдән соң барлыкка килә. Ә музей ишек төбендә эленеп торган мәрмәр такталарда Казан астрономнары хөрмәтенә исем бирелгән Ай кратерлары һәм Кояш системасының күк җисемнәре теркәп куелган. Айдагы ун кратер, төрле кометалар, астероидлар, кече планеталар... Мәрмәр такталарда обсерваториянең хәзерге директоры Юрий Нефедьевның әтисе Анатолий Алексеевич Нефедьевның исеме дә бар. Халыкара астрономия берлеге Айның Көньяк полюсындагы зур кратерны аның хөрмәтенә атаган.

1879 елда Дублинда эшләнгән оптик прибор хәзер обсерваториянең төп бинасы павильонында урнаштырылган һәм Россиянең гамәлдәге иң зур визуаль телескобы булып тора.

– Әтием гомуми нуль дәрәҗәсендә Ай чите зонасының беренче карталарын ясый, ул заманда алар бик мөһим була, – дип сөйли Юрий Анатольевич. – Күзәткәндә, Айның безгә гел бер ягы белән генә карап тормавын, ә оптик либрацияләр аркасында тибрәнеп, үзенә күрә бер полоса – либрация зонасы барлыкка китерүен күрергә мөмкин. Бу полоса Ай чите зонасы дип атала да инде. Әтием ясаган карталар иң төгәлләрдән булып чыга, аларны әлегәчә кулланалар. Ә Айның Көньяк полюсындагы А.А. Нефедьев кратерында кайчан да булса, бәлки, кеше яши торган база булыр, дип өметләнәм, чөнки анда читтән кергән боз бар, ә ул исә – Җирдән ташырга кирәк булачак иң кыйммәтле продукт.

Энгельгардтның гыйльми варислары Айны гына актив өйрәнеп калмый. Мәсәлән, Казанга Дрезденнан китерелгән теге телескоп, Георгий Ризванов сүзләренчә, Марсның иярченнәрен өйрәнү һәм фотога төшерү максатыннан оештырылган «Фобос» программасында да катнаша.

– Гомумән, фәнни тикшеренүләр барышында биредә хәзер классика дип саналган күп кенә ачышлар ясала, мәгълүмат туплана, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Мәсәлән, Меридиан түгәрәгендә (бер телескопның атамасы – авт.) күзәтүләр нәтиҗәсендә йолдыз каталоглары төзелә. Хәзерге ГЛОНАСС системасы әнә шул каталогларга нигезләнгән. Шулай булгач, телефонда навигатор кулланган һәркем безнең обсерваториядә алынган мәгълүматларга да таяна дип, һич шикләнми әйтергә мөмкин. Үз вакытында бу каталоглар дөньяда иң төгәле дип санала.

КҮЗӘТҮ – БЕРЕНЧЕЛ НИГЕЗ

Галимнәребезнең иң мөһим фәнни ачышларының күбесе, әйткәнебезчә, телескоп – Меридиан түгәрәге белән бәйле. Ул бүген, мөгаен, астрономия дөньясының һәм, әлбәттә, Энгельгардт исемендәге обсерваториянең төп ядкәреде. Бу телескоп 1842 елда (ул чакта әле шәһәр обсерваториясе өчен) Гамбургтагы абыйлы-энеле Репсольдлар остаханәсендә ясатып алына.

– Барлыгы шундый тугыз телескоп эшләнгән, – дип сөйли Георгий Ризванов. – Аларның икесе Россиягә җибәрелә: берсе – Пулково обсерваториясенә, икенчесе – безгә. Ләкин мин бүген дөньяда бары тик безнеке генә гамәлдә кулланырлык хәлдә икәненә шигем юк. Пулковоныкы, мәсәлән, сүтелгән һәм эшләми.

Телескопны Энгельгардт обсерваториясенә алып кайткач, аның өчен махсус павильон – түбәсе ачыла торган уникаль конструкция ясыйлар. Монда күзәтүчеләр һава торышына һич игътибар итмичә, сәгатьләр буе окуляр янында утыра (павильон җылытылмый, чөнки түбә ачканда температура кискен үзгәрү сәбәпле, оптикага һава турбулентлыгы йогынты ясаячак).

– Астроном – беренче чиратта күзәтүче ул, күзәтү – безнең фәннең нигезе, – ди Юрий Нефедьев һәм, елмаеп, кайчандыр үзенең утыз биш градуслы салкында гелиометр телескоптан күзәткәнен, керфекләренең, туңып, окулярга ябышканын искә төшерә.

Меридиан түгәрәгенә әйләнеп кайтыйк. Әлеге атама телескопның бары тик бер яссылыкта, күк меридианы буйлап өскә-аска гына хәрәкәт итә алуы белән бәйле. Бу прибор күк җисеменең горизонт өстеннән күтәрелү почмагын билгеләү өчен көйләнгән.

Билгеле бер исәпләүләр ясап, күзәтүче йолдызларның координаталарын ачыклый ала, ә аларга бәйле рәвештә Кояш системасы объектларының теләсә кайсында координаталарны билгеләргә мөмкин, – дип аңлата Георгий Ризванов.

1980 нче елларның икенче яртысына кадәр телескоп фәнгә хезмәт итә. Әле бүген дә, төгәлрәк цифрлы техника барлыкка килгән заманда да, Меридиан түгәрәге ярдәмендә туристлар, аяз төндә килсәләр, йолдызларны күзәтә ала. Димәк, телескоп эшләүдән туктамый, хәзер инде ул фәнни агарту, халыкка фәнне аңлату юнәлешендә хезмәт итә.

Ә обсерваториядә гыйльми эшчәнлек хәзер яңа юнәлешләрдә дәвам итә. Мәсәлән, элекке радиолокация лабораториясендә (университет аны быел капиталь төзекләндерергә планлаштыра) космик геодезия буенча заманча дүрт лаборатория эшләячәк.

БУЫННАН-БУЫНГА

Юрий Нефедьев өчен Энгельгардт исемендәге обсерватория – эш урыны гына түгел.

– Мин монда туганмын дип әйтергә мөмкин, – дип көлә ул.

Аның әтисе турында без инде югарыда искә алдык. Тагын шуны да өстәп куйыйк: 1958–1976 елларда Анатолий Нефедьев та бу обсерваториянең директоры вазыйфасын үти. Юрий Анатольевичның әнисе Антонина Ивановна да күренекле астроном профессор була. Ул нәкъ менә Меридиан түгәрәге аша сәгатьләр буе күк йөзен күзәтә, йолдызларның координаталарын билгеләү һәм йолдыз каталоглары төзү буенча халыкара һәм илебез программаларын тормышка ашыру эшен җитәкли. Энгельгардт исемендәге обсерваториядә кадерләп саклаган истәлекләрендә Антонина Ивановна коточкыч авыр 1942 елда обсерваториягә эшләргә килүе турында яза. Ул вакытта, генератор подстанциясендәге янгыннан соң, обсерватория утсыз кала (һәм 1948 елга кадәр шул хәлдә эшли).

«Сукыр лампалар белән яшәдек, – дип укыйбыз истәлекләрдән. – Шешәгә керосин салына, шуңа филтә тыгып куела. Ул филтә янганда бик нык корым чыгара. Әнә шундый яктылык белән мин бик күп астрометрик китаплар укыдым һәм тәрҗемә иттем... Еш кына ур-

Кечкенә Юра Нефедьев әти-әнисе белән.

манга агач кисәргә йөрдек. Обсерватория янында имәнлек иде, зыңлап торган гасырлык имәннәрне кисү бик авыр, ач кешегә бигрәк тә. Гадәттә иң юан агачларны иң яшь һәм сәламәт кеше буларак, мин һәм Анатолий Нефедьев кисә иде...»

Шул ук вакытта ул сугыш елларында обсерватория бик мөһим эшләр башкара.

– Төгәл координата-вакытны билгеләми торып, космик миссияләрне дә, халык хуҗалыгы эшчәнлеген дә тормышка ашыру мөмкин түгел, шуңа бәйле рәвештә бу тармак сугыш елларында да бик мөһим иде, – дип аңлата Юрий Нефедьев. – Киңлек буенча күзәтүләр, полюска бәйле координаталар билгеләү, җир өсте координаталарының бөтен системасы – боларның барысын да безнең астрономнар хәл итә. Ә тирә-яктагы урман чыннан да тулысынча диярлек кисеп бетерелә. Ул чагында паровозларлар да утын яга бит. Монда тар тимер юл салына, шуның белән утынны станциягә ташыйлар.

Кешеләр ул вакытта бер-берсенә бик булышып гомер итә. Коллектив төп таяныч була. Һәркем үзен беркайчан да ташламаячакларын, ярдәм итәчәкләрен белә. Безнең монда, гомумән, һәрвакыт үзенчәлекле бердәмлек хөкем сөрә. Бирелә сугыш елларында һәм аннан соңгы беренче елларда директор булган Дмитрий Яковлевич Мартынов 50 нче еллар башындагы бер вакыйганы сөйләгән иде. Еш кына обсерватория хезмәткәрләре кич белән төп административ бина каршында җыелып утырып, төрле проблемалар турында фикер алыша торган була. Һәм шундый кичтә бер хатын кинәт: «Минемчә, барысына да Сталин гаепле», – дип куя. Барысы да тынып кала һәм тиз генә таралышалар. Мартынов аннары ике атна йокысызлыктан интеккәнен искә ала. Әгәр берәрсе «тиешле урын»га җиткерсә, ә аннары бу хәл турында директорның белгәнлеге һәм дәшми калганлыгы ачыкланса, димәк, директор үзе дә гаепле булачак... Ләкин беркем дә бернәрсә дә әйтми...

АСТРОНОМИЯГӘ ТУГРЫ ХЕЗМӘТТӘ...

Василий Павлович Энгельгардтка беркайчан да Казанга килергә насыйп булмый, ләкин ул шулай да дусты Дмитрий Иванович Дубяго белән очрашып кала. Әлеге очрашу 1902 елда Дубяго юл уңаеннан Дрезденга кагылып чыккан чакта була. Шул вакытта аларның киләчәктә бергә җирләнү идеясе туа. Энгельгардтның кабердә дусты белән янәшә һәм «аның йөрәгенә кадерле инструментлар» тирәсендә ятасы килә.

– Һәм васыятьтә тагын бер шарт куела: җирләү урыны «астрономиягә хезмәт итәргә тиеш», – дип сөйли Георгий Ризванов.

Бу максаттан махсус төрбә – көньяк мира (мира – меридиан түгәрәген көйләү җайланмасы – ред.) салына. Гомумән, бу бина – көньяк мира, Меридиан түгәрәге павильоныннан икенче якта урнашкан төньяк мира кебек үк, тулысынча гамәли бурычны үти: мирада урнашкан ясалма йолдызлар буенча телескопларны көйлиләр. Ләкин көньяк мираның нигезе астына әле төрбә дә куелган, анда Дмитрий Дубяго җирләнгән. Ә менә васыятьне тулысынча тормышка ашыра алмыйлар. Энгельгардт 1915 елда Германиядә вафат була. Беренче бөтендөнья сугышы барган вакыт, һәм аны Россиядә җирләү турында сүз дә чыга алмый. Аннары революция була, Икенче бөтендөнья сугышы... Кыскасы, бу хакта уйлый торган чак түгел... Шулай да 2014 елда Татарстанның «Яңарыш» фонды ярдәме белән Казан университеты васыятьнең соңгы пунктын үтәүгә ирешә – Василий Павловичның көле аның исемен йөрткән обсерватория территориясендәге төрбәгә күчереп җирләнә. Хәзер инде ул, үзе теләгәнчә, ахирәт дусты белән янәшә, яраткан телескоплар чолганышында ята, ә алар җирләнгән урын астрономиягә хезмәт итә.

– Казан Император университетының, обсерваториягә иң яхшы җиһазлар бүләк иткән өчен, Энгельгардт кабере өстендә мәңге лампада яндырырга, дигән махсус карары бар, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Бу кечкенә лампада хәзер чыннан да яна, бер үк вакытта ул фәнни миссияне дә үти – Меридиан түгәрәген көйләү өчен ясалма йолдыз ролен башкара.

Бик матур дуслык тарихы әнә шулай тәмамлана. Хәер, юк, тәмамланмый. Ул дуслыкның уникаль уртак җимеше – Казан федераль университетының Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе – хәзер дөнья дәрәҗәсендә танылды һәм аның тарихы астрономиядәге яңа исемнәрдә, объектларда һәм ачышларда дәвам итәчәк.

Табличкада – Казан обсерваториясе галимнәренең исемнәре белән аталган космик объектлар исемлеге.



«ӨЧЕНЧЕ ДӨНЬЯ» ИНКЫЙЛАБЫ ИДЕОЛОГЫ



Илдус Заһидуллин

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Җир шарында капиталистик һәм социалистик лагерь оеша. 1960 нчы елларда исә берничә гасыр яшәп килгән колониаль система җимерелә, «өченче дөнья» – Африка һәм Азия халыклары үз дәүләтләрен төзергә керешә. Нәкъ шул елларда иseme туган илендә тыелган һәм онытгырылган татар коммунисты Мирсәет Солтангалиевнең колонияләрдә һичшиксез инкыйлаб булачагы хакындагы тәгълиматы дөнья күләмендә таралыш ала. Бу тәгълиматның авторын кайбер галимнәр «өченче дөнья» инкыйлабының «атасы», идеологы дип тә атыйлар.

ЮЛ БАШЫ...

Мирсәет Уфа губернасы Ялембәк авылында 1892 елның 25 августында рус теле укытучысы Хәйдәргали һәм бөлгән морза кызы Гайнелхәят гаиләсендә дөньяга килә. Төрле авылларда эшләгән этисе Мирсәеткә 9 яшь булганда туган авылы Кырмыскалыга кайтып төпләнә, игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Гаилә башлыгы балаларына кырыс хезмәт тәрбиясе бирә.

Әнисе ягыннан бабасы утарына җәй көннәрендә җыелган морза туганнары белән аралашканда Мирсәет үзенең түбән катлам вәкиле булуын аңлый. 14 яшеннән бабасы утарына кунакка барудан туктый. Бу факт аның яшьтән горур, үзфикерле булуын күрсәтеп тора.

Мирсәет башта рус-татар мәктәбен тәмамлый, 11-15 яшьләрдә авыл мәдрәсәсендә дин сабагын укый. Әтисе китапханәсендәге барлык русча китапларны укып чыга. Акчасы булмаганлыктан, гимназиягә укырга бара алмавына гарьләнә.

М. Солтангалиевнең Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлау турында шәһадәтнамәсе. 1911 ел.

КАЗАНСКІЙ УЧЕБНЫЙ ОКРУГЪ
СВИДѢТЕЛЬСТВО.

1907 елда Мирсәет Казан татар укытучылар мәктәбенә (КТУМ) укырга керә. Беренче курста Л.Толстойның ике хикәясен («Ни чәчсәң, шуны урырсың», «Утны әүвәлендә сүндерү тиеш»), 4 курста язучы П.В. Засодимскийның «Мич алдында» исемле хикәясен татарчага тәрҗемә итә, алар аерым китаплар булып басылып та чыга. Үзе дә каләм сыный: «Башкортлар арасында» исемле беренче хикәясен яза, сәнгатьле укуда һәм үзешчән театрда уңышларга ирешә. Яшүсмер КТУМда бер ел уку дәверендә атеистка әйләнә, өлкән иптәшләреннән фәнни социализм теориясен үзләштерә. Уку йортын 1911 елда бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый.

Аннары ике ел дәвамында Уфа губернасының татар авылларындагы рус-татар мәктәпләрендә, земство ачкан беренче татар авыл китапханәсендә эшли.

ИҖТИМАГЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Егет 1911 елда Эстәрлетамак өязе земствосы җыелышына мөселман дини мәктәпләрен милли уку йортлары итеп үзгәртеп кору хакында язма доклад белән мөрәҗәгать итә.

«Уфимский вестник» газетасында, «Народный учитель» (Мәскәү) журналында, төрле тәхәллүсләр куеп, мөселманнар мәнфәгатен яклаган мәкаләләр бастыра. Әйтик, 1911 елда бер түрәнең ач крестьяннарга чәчү орлыгы таратканда җәберләве хакында яза, нәтиҗәдә чиновник эшеннән алына. 1913–1914 елларда Уфаның «Тормыш» газетасында милли мәгарифне яхшырту һәм кооперация кебек темаларга язмалар белән катнаша.

Әдәби иҗат белән шөгыльләнергә дә вакыт таба: 1911–1914 елларда «Мусульманская газета» (Санкт-Петербург) битләрендә Солтангалиевнең дистәгә якын хикәясе һәм шигыре дөнья күрә.

1913 елда Мирсәет татар социалистлары оешмасын төзи; Россиядә республика идарәсе урнаштыру, җирне – крестьяннарга, завод-фаб-

Фотолар автордан, ачык чыганаклардан алынды

рикаларны эшчеләргә бирү кирәклеге хакында прокламацияләр тарата.

1915 елда Бакуга күченеп, «Баку», «Кавказское слово» газеталарына мөселманнар тормышы хакында мәкаләләр язып акча эшли. Ниһаять, 1916 елда Баку шәһәр думасына хуҗалык һәм сәүдә агенты булып эшкә урнаша.

Солтангалиевнең 1917 елга кадәрге тормышына йомгак ясап, шуны әйтергә мөмкин: Мирсәет бала чактан фәкыйрьлектә яши, укытучының хезмәт хакы да кечкенә була. Әмма ул даими рәвештә белемен арттыру белән шөгыльләнә, марксистик әдәбият укый. Укытудан тыш, төрле юнәлешләрдә иҗтимагый эшчәнлек алып бара.

СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң илдә кискен үзгәрешләр башлангач, Мирсәет кебек русча яхшы белгән, дөньяда һәм илдә барган вазгыятьне аңлаучы, гаделлек өчен көрәшергә омтылучы актив шәхесләргә ихтыяҗ нык арта. Шул сәбәпле 1917 елда сәясәт мәйданында элеккеге җәмгать эшлеклеләре янәшәсендә яңа шәхесләр пәйда була. Ул елларда яңа хакимияттә югары дәрәҗәгә ирешкәне һәм иң күренеклесе – Мирсәет Солтангалиев.

Февраль инкыйлабыннан соң, I Бөтенроссия мөселман съездында (Мәскәү, 1–11 май) сайланган Милли шураның Башкарма комитеты рәисе – меньшевик Әхмәд бәй Цаликов чакыруы белән ул Петроградка килә һәм оешманың сәркатибе вазифасын үти башлый. Казанда Милли-мәдәни мохтарият (автономия) игълан иткән һәм аның башкарма органы итеп Милли идарә сайлаган II Бөтенроссия мөселман съездын оештыруга зур өлеш кертә. Шунда Мулланур Вахитов белән якыннан аралаша һәм Казан мөселман социалистик комитетын төзүдә катнаша. Казанда 1917 елның июль аенда Россия социал-демократик эшчеләр партиясенә керә.

Большевик Солтангалиев 1917 елның декабрендә узган киңәшмәдә Уфада эшли башлаган Милләт Мәҗлесен таркатырга дигән тәкъдим белән чыгыш ясый. Аның бу адымын татар милләтен сату дип бәяләп, «Кояш» газетасында тәнкыйть язмасы дөнья күрә. Мирсәет җавабында үзен «чын милләт улы» дип белдерә, моңарчы изелеп яшәгән татарлар һәм мөселманнар мәнфәгатен кайгыртуын ассызыклап, үз халкына булган мәхәббәт йогынтысында большевизмга килүе турында әйтә. Көрәшенең максаты – милли гаделлеккә омтылу, моңа ирешү өчен иң кулае социалистик юл дип белдерә.

Милли эшләр буенча халык комиссары итеп Иосиф Сталин билгеләнгәч, комиссариат каршында Эчке Россия һәм Себер мөселманнары эшләре буенча Үзәк комиссариат оеша. Аның җитәкчесе итеп Мулланур Вахитов тәгаенләнә, Солтангалиев тә шунда эшли башлый. Үзәк комиссариат мөселманнар яшәгән төбәкләрдә совет хакимиятен ныгытуга юнәлтелгән чаралар күрә. Солтангалиев, төбәкләрдәге вазгыятьне ачыклар өчен, Көнбатыш Себердә, Кырымда, Төньяк Кавказда, Төркестанда командировкада була. Яңа оешма структурасындагы секцияләр мөселманнарның эш белән тәэмин ителеше, авыл хуҗалыгы, сәнәгать, мәгариф, мәхкәмә, финанслар, гаскәрләр һ.б. мәсьәләләр белән шөгыльләнә, актив шәхесләрне эшкә тарта. Шул рәвешле 6 айдан 26 шәһәрдә оешманың филиаллары – җирле мөселман комиссариатлары ачыла.

1918 елның беренче ун аенда ҮМК 229,5 мең данә төрле-төрле брошюра, татар, кыргыз, төрек телләрендә 4 миллионнан артык газета бастыра. Мәскәүдә татар телендә – «Чулпан», мөселман хәрбиләренә атап «Кызыл Армия» газеталары нәшер ителә. Болардан тыш, ҮМКның төбәкләрдә дә вакытлы матбугаты эшләп килә: Казанда – «Эш», Уфада – «Көрәш», Әстерханда – «Тартыш». Бу эшләрне оештыруның шактый өлеше Солтангалиев җилкәсенә төшә. Ул әһәмиятле текстларны рус теленнән татарчага үзе тәрҗемә итә, «Кызыл Армия» газетасында кайбер айларда күпләп сәяси мәсьәләләрне яктырткан мәкаләләр белән катнаша.

ҮМКның тагын бер зур «эше» татар милли хәрәкәтен тар-мар итү була. Казанда җыелган Россия мөселман хәрбиләренең II съезды Милләт Мәҗлесе кабул иткән Идел-Урал штатын төзү турында карарны раслагач, 17 февральдә азчылыкны тәшкил иткән сул канат (большевиклар) съездны ташлап чыгып китә. 21 февральдә Казан советы Солтангалиев җитәкчелегендә Казан мөселман комиссариаты оештыра һәм, 5 көн үткәч, революцион штаб төзи. Шәһәрдә гадәттән тыш хәл игълан ителә. II съездның Идел-Урал штатын тантаналы рәвештә игълан итү чарасын өзү максатында,

Мирсәет Солтангалиев һәм Үзәк мөселман комиссариаты сәркатибе И.К.Фирдәвез. 1919 ел.

Мирсәет Солтангалиев I Бөтенроссия мөселман коммунистлары съезды делегатлары арасында. 1918 елның 4–12 ноябрь көннәре арасында.

28 февральгә каршы төндә съезд президиумы составындагы Хәрби шура җитәкчеләре кулга алына. Делегатлар, милли әйдәманнар Болак аръягына күченә.

1918 елның 23 мартында Мәскәүдә Совет хөкүмәте җитәкче Владимир Ленин үзе түгел, ә милли эшләр буенча халык комиссары Сталин һәм ҮМК рәисе Вахитов кул куйган Татар-Башкорт совет республикасының нигезләмәсе дөнья күрә. 28 мартта М. Вахитов җибәргән кызыл гаскәр Казанда «Болак арты республикасы»н һәм Хәрби шураны тар-мар итә. Шулай ук башка шәһәрләрдә урнашкан мөселман гаскәрләре таркатыла.

Солтангалиев эшчәнлегенең тагын бер юнәлешен әйтергә кирәк. 1918 елның 8 мартында Вахитов белән бергә, ил күләмендә коммунистларны һәм аларга теләктәшлек күрсәтүчеләрне җыеп, Россия мөселман хезмәт ияләре конференциясе үткәрә һәм рус большевиклар партиясеннән бәйсез Мөселман социалист-коммунистлар партиясен төзи. Партия белән Вахитов рәислегендәге 12 кешедән (Солтангалиев һ.б.) торган коллегия җитәкчелек итә.

Эшне дәвам итеп, Казанда 17–23 июнь көннәрендә мөселман коммунистларының беренче конференциясен чакыралар. Конференциядә катнашкан төбәк мөселман комитетлары вәкилләре «Россия мөселман коммунистлар (большевиклар) партиясе»нә нигез салу турындагы тәкъдимне хуплый. Партия Россия коммунистлар партиясе уставын кабул итә, ләкин автономияле булып кала. Бераз соңрак Сталин Солтангалиевнең бу эш-гамәлләрен «буржуаз милләтчелекнең» ачык чагылышы дип бәяләячәк.

Үзәкләштерү яклы совет хакимияте 1918 елның ноябрендә бу мөстәкыйль партияне юкка чыгара.

ГРАЖДАННАР СУГЫШЫНДА

1918 елда Гражданнар сугышы шартларында Үзәк мөселман комиссариатының Үзәк мөселман хәрби коллегиясе оештырыла, ябылганчыга кадәр (1920 елның октябре) аның рәисе Солтангалиев була. Коллегиягә мөселманнарны Кызыл гаскәргә җәлеп итү, яңа частьлар туплау бурычы йөкләнә. Аның тәкъдиме белән мөселман хәрби частьлары оештырыла.

1918 елның августында, Казанны ак чехлар камап алгач, Солтангалиев кызылларның дошманга каршы торучы соңгы отряды белән җитәкчелек итә, сугышчан батырлык үрнәге күрсәтә. Шәһәр яулангач, берничә көн Казанда качып ята, ә Вахитов дошман кулына төшә, 19 августта атып үтерелә.

Исән-сау котылган Мирсәет ҮМКның рәисе итеп билгеләнә. Аның кулында искиткеч зур хакимият туплана: Үзәк мөселман комиссариатының һәм РСФСР Хәрби һәм диңгез халык комиссариатына буйсындырылган Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең рәисе (1918–1920), Кызыл Армия сәяси идарәсенең Көнчыгыш бүлеге мөдире, большевикларның Россия коммунистлар партиясе каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы җитәкчесе (1919–1921).

Солтангалиев 1919 елның беренче яртысында 6 ай дәвамында Колчак гаскәрләренә каршы сугышта катнаша. Август аеннан башлап Мәскәүдә яши.

Ул Ленин һәм Сталин кушуы буенча Әхмәт-Зәки Вәлиди белән башкорт гаскәриләрен совет ягына чыгару буенча сөйләшүләрне уңышлы башкарып чыга.

КОЛОНИАЛЬ ИНКЫЙЛАБ ТЕОРИЯСЕ

Мирсәет Солтангалиев 1919 елда «Социаль инкыйлаб һәм Көнчыгыш» исемле мәкалә яза. Анда Карл Маркcның дөнья күләмендә пролетариат диктатурасы урнашуын фаразлаган инкыйлаб хакындагы теориясен ялгыш дип белдерә. Чыннан да, көтеп-көтеп тә Көнбатыш Европа илләрендә бернинди инкыйлаб та башланмый. Солтангалиев фикеренчә, Европа илләрендәге барлык сыйныфлар, шул исәптән андагы пролетариат та, – колониаль халыкларны изеп яшәүчеләр. Чөнки Көнбатыш дәүләтләре, колонияләрне талау

Мирсәет Солтангалиев Көнчыгыш халыкларының II Бөтенроссия мөселман коммунист оешмалары съезды делегатлары арасында. 1919 елның декабре.

хисабына тупланган матди байлыкның бер өлешен эшчеләргә биреп, аларның икътисадый таләпләрен канәгатьләндерә.

Солтангалиев, дөнья күләмендә социалистик инкыйлаб булачагын таныган хәлдә, хәрәкәт колония булып яшәгән Көнбатыш халыклары арасында башланачак, дип фаразлый. Совет хөкүмәтен Көнчыгыш белән тиешле дәрәҗәдә эшләмәүдә гаепли. Шәрык Көнбатышның икътисадый коллыгында кала бирә. Колонияләрдә яшәгән мөселман халыклары – пролетар халыклар, алардагы барлык сыйныфларны да «пролетар» дип әйтергә мөмкин, чөнки барысы да Европа капиталистлары тарафыннан изелә, дип белдерә. Милли колонияләр мәсьәләсен социализм гына хәл итәргә сәләтле, дип саный. Соңрак Солтангалиевнең бу фикерләре Мао Цзедун, Хо Ши Мин һәм башка Азия һәм Африка марксистлары тарафыннан үстерелә.

ТОРМЫШКА АШМАГАН ХЫЯЛЛАР

Мирсәет Солтангалиев, Татар-Башкорт республикасы составына инде яшәп килүче Кече Башкортстанны кертмичә, аны Уфа губернасының күпчелеге татарлар һәм беркадәр башкортлар яшәгән өязләрен кушып оештыру ягында була. Гражданнар сугышы оештыру комиссиясенең эшен туктатып тора. Ә сугыштан соң, Татар-Башкорт совет республикасы турындагы проект юкка чыгарыла.

Солтангалиев, планы барып чыкмагач, 1920 елда Татарстан Республикасын оештыру хакында декретны әзерләүдә катнаша. 1920 елда ҮМК ТАССРның Мәскәүдәге вәкиллеге итеп үзгәртелә, аның рәисе вазифасында Солтангалиев кала. Ул 1923 елга кадәр шулай ук РСФСР Милли эшләр буенча халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы булып тора. 1922 елда ТАССРның Үзәк башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлана.

Ул СССРны оештырганда халыкларны төрле дәрәҗәләргә бүлүгә каршы чыга. Автономия статусына ия булган республикаларның вәкаләтләрен арттыру һәм аларны СССРга союздаш республика сыйфатында кертү өчен тырыша. Солтангалиев Сталинның автоном республикаларны федерация составында калдыру тәкъдименә каршы чыга.

ВКП (б) ның XII съездында хакимиятнең милли сәясәтен кабат нык тәнкыйтьли, бөек державачыл шовинизм белән көрәшергә чакыра.

Нәтиҗәдә Сталин кушуы буенча аны гаепләрлек мәгълүмат туплана, 1923 елның 4 маенда ул милли сәяси оешма төзегән һәм партиянең милли сәясәтен тәнкыйтьләгән өчен кулга алына. РКП (б) Үзәк комитеты киңәшмәсендә Солтангалиев, партия дошманы буларак барлык вазифаларыннан азат ителә, «милли тайпылышта» гаепләнә.

Иреккә чыгарылгач, 1923-1928 елларда кооперация өлкәсендә вак чиновник булып хезмәт куя. 1924 елда Үзәк комитетка кабат партиягә

Мирсәет Солтангалиев. 1928 елның 14 декабре. Төрмә фотосы.

алуларын сорап мөрәҗәгать итә, ләкин тискәре җавап ала.

Хакимият аның турында кабат 1928 елда искә төшерә һәм СССРны бүлгәләргә теләгән революциягә каршы милли оешма җитәкчесе буларак кулга ала.

1930 елда ул атарга хөкем ителә, 1931 елда бу карар Соловец утрауларына сөрген белән алыштырыла. Авыру сәбәпле, 1934 елда сөргеннән кайтарыла, Саратов шәһәрендә яши.

Әмма 1937 елгы репрессияләр вакытында кабат кулга алына. Казанга кайтарыла. Суд вакытында кыйнап алынган күрсәтмәләреннән баш тарта.

Солтангалиев СССР Югары судының хәрби коллегиясе карары нигезендә 1940 елның 28 гыйнварында атып үтерелә. Исеме 1991 елда аклана.

ГАИЛӘ ХӘЛЕ

Мирсәет Солтангалиевнең беренче хатыны Рауза Чанышева морза нәселеннән – Мөхәммәт Җангир улы Чанышевның кече кызы була. Уфада туып-үскән кыз яшьтән инкыйлаб идеясе белән мавыга, сәяси түгәрәктә Мирсәет белән таныша, аңа кияүгә чыга. 1915 елда ире артыннан кечкенә кызы белән Бакуга килгәч, ул монда гимназиядә география укыта.

1917 елда Россиянең I мөселман хатын-кызлары съездында катнаша, бюрога сайлана. II съездда президиум әгъзасы була. Рауза хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклылыгын яклаган хәрәкәттә әйдәп баручылардан була. Солтангалиев, көнләшеп, табиб Оружиевны атып үтергәч, Орск шәһәренә китеп бара һәм Башкорт хөкүмәтендә эшли башлый. Башкорт гаскәрләре белән кызыллар ягына чыга, 1919 елда партиягә керә. Раузаның Мирсәет белән аерылышканнан соңгы тормышы турында төрле версияләр бар: тифтан вафат була дип тә, поезд астында кала дип тә, чит илгә китә дип тә фаразлыйлар. Кызлары Рәсидә кулга алына, 3 ел гомерен лагерьда уздыра.

Икенче тапкыр Мирсәет Солтангалиев Мәскәүнең мәшһүр бае Салих Ерзинның оныгы Фатыйма Әхмәт кызына өйләнә, аларның ике баласы туа. Әмма эти кешенең кара язмышы бу гаиләсен дә читләп үтми: Фатыйма һәм кызлары Гөлнара лагерьда вафат булалар, уллары Морад акылдан яза.

СЕРЛЕ ИСЕМЛЕ ГАЛЬГАФ

Айдар Шәйхин

Татар әдәбияты күгендә балкый алган, әмма ачы язмыш сынауларына дучар булып, сәләтен үстерүдән мәхрүм калган шәхесләребез байтак. Гальгаф алар арасында иң серлеседер, мөгаен. Бу исемне белүчеләр дөньяда бик сирәк шул.

Язучы Гальгафның чын исеме – Нургали Гали улы Галиев. Инкыйлабтан соңгы татар һәм рус дөньясына хас булган яңа модага ияреп, ул да үзенә псевдоним уйлап таба – Гальгаф. Бу исем революциянең үзе сыман кискен һәм куәтле булып яңгырый сыман. Әлбәттә, өч тапкыр Гали исемен кабатлаганчы, шигар сыман кыска сүз иҗат әһеленә уңайлырак булгандыр. Иҗаты һәм гомере кебек үк кыска...

БИК КЫСКА ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ

Язучы 1903 елда Казан губернасы Чистай өязенең Урманасты Шонталысы авылында туа. Хәзер бу авыл Алексеевск районына карый. Гальгафның туган ягы – борын заманнарда ук болгарлар яшәп, археологик ятмаларда эзләрен калдырган төбәк. Авыл халкы XVIII гасырда чукындыру сынаулары аша уза, әмма бер гасыр үткәч, яңадан ислам диненә кайта. Нургали туган елларда авылда бер генә түгел, хәтта ике мәчет эшли. 1920 елда исә Урманасты Шонталысында зур янгын чыгып, 130 йорт көлгә әйләнә. Әмма бу авыл бүген дә исән, үз тарихын саклап, кадерләп тота.

Гальгаф 1920 елда басыла башлый. 1927 елда ул гаилә кора, Бибимәликә Таһир кызы Кулеевага – кара чәчле һәм кара күзле чибәр кызга өйләнә. Замандашы һәм дусты Әмирхан Еники бу пар турында: «Алар хатыны белән гел бергә кулга-кул тотынышып йөриләр иде. Гальгаф хатынын бик ярата иде. Минемчә, бу аларның иң бәхетле чаклары булгандыр. Әмма бераздан алар күз уңыннан югалдылар», – дип искә ала.

1928 елда Казанда рабфакны тәмамлап, Көнчыгыш педагогика институтына укырга керә. 1929 елның 23 февралендә Нургали белән Мәликәнең Бәллүр (Белла) исемле кызлары туа.

Гальгаф дигән язучы нәрсәләр иҗат итәргә җитешкән соң? Санап карыйк. 1925 елда «Буталчык көннәрдә» исемле пьесасы дөнья күрә. 1927 елда «Авылыма хат» исемле шигырьләр җыентыгы һәм «Манёврдан соң» дип аталган хикәяләр тупламасы басыла. 1929 елда рус язучысы Александр Неверовның «Ташкент – икмәкле шәһәр» повестен татар теленә нәкъ менә Гальгаф тәрҗемә итә. Матбугатта мәкаләләре, рецензияләре чыга. Күпләр аның ниндидер бер роман язып ятканлыгын искә ала. Әмма ул язылып бетмәгән әсәрнең бер кульязмасы да сакланмаган.

Сакланган әсәрләрнең азлыгы аркасында, Гальгафның иҗатына тулаем бәя бирү дә авыр. Әмма замандашлары аны авыл кешесенең психологиясен төгәл тасвирлый белгән һәм үтә дә халык җанлы булып иҗат иткән язучы дип истә калдырган.

Фотолар автордан алынды

ГАЛЬГАФ КӨЛДЕРӘ

17–18 яшендә Гали Казанга күчеп килә. Татар матбугатында да Гальгаф исеме беренче тапкыр 1920 елда искә алына. Бу елны Нургали беренче шигырьләрен бастыра башлый. ТАССР барлыкка килгән, күңелләр өмет белән тулы еллар бу. Казанга Һади Такташ, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан, Кави Нәҗмиләр килә. Тора-бара Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир кебек ул чакта бик яшь булган иҗатчылар да башкалада төпләнә. Алар өчен Такташлар да, өлкән буынга караган Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камаллар да – зур йолдызлар һәм остазлар. Гальгаф нәкъ шушы иҗат даирәсенә килеп кушыла.

Казанда 1926 елда бер төркем татар язучылары төшкән фотосурәт бар. Ул Татарстан Дәүләт архивында да саклана, ачык чыганакларда да аны табарга була. Бу фотографиядә Кави Нәҗми, Гальгаф, Шамил Усманов, Һади Такташ, З. Гали, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Мөхәммәд Парсиннар һәм аларга остаз тиешле Шәриф Камал сурәтләнгән. Гальгаф шушы үзенчәлекле мохиттә язучы һәм журналист буларак үсәргә омтыла.

Ул чор язучыларының күңеленә Гальгаф бик шаян кеше буларак кереп калган. Мәсәлән, аның замандашы Мирсәй Әмир 1920 нче еллар Казанында еш узган иҗат кичәләренең берсе турында мондый истәлеген калдырган:

«Гальгаф көлдерә. Әйе, сөйли генә түгел, көлдерә.

Карсак кына буйлы, киң җилкәле бу егетнең Гали Галиев исемле икәнен дә, студент икәнен дә белми идем әле. Мәгәр Гальгаф буларак яшь язучылар арасында билгеле кеше иде. Хикәяләре хәтеремдә калмаган. «Ил бирәннәре» дигән роман яза дип сөйлиләр иде. Ни дәрәҗәдә дөрес булгандыр, анысы да дөньяга күренмәде. Әсәрләре белән түгел, җыелышлардагы чыгышлары белән танылган иде. Анда да көлдерә белүе белән. Үзе болай карап торуга гаять җитди кыяфәтле. Хәтта кырыс, ачулы чырай. Ә сөйләргә керешсә, беренче сүзләреннән үк көлә башлыйсың. Күренеп тора: тыңлаучыларны көлдерүдән ул ләззәт таба. Рухы күтәрелеп, һәҗү (сатира - ред.иск.) дәрте үсеп китә. Ләкин кырыс чыраена ник аз гына көлү-елмаю билгесе чыксын! Ә көлдерүе көлдерү» (Мирсәй Әмир. *«Хатирәләр урманы» автобиографик повестеннан*).

Әйе, Гальгафның җор телле һәм туры сүзле булуын, күпмедер усаллыгын да искә алалар. Мөгаен, кайвакыт замана җилләренең кайсы якка таба исә баруын уйламыйча да сөйләшкәндер ул. Юкса 26 яшендә репрессия тегермәненә эләкмәс иде...

СЛОН ӘСИРЕ

1929 елның 11 апрелендә Генрих Ягода исеменә доклад язуы килеп төшә. Анда Солтангалиев эше буенча алып барылган тикшерүләр барышында Татарстанда һәм Әстерханда яшерен түгәрәкләр барлыгы ачыклануы хәбәр ителә. Шушы язма нигезендә апрель белән август арасында Казанда ОГПУның Татарстан бүлеге 12 кешелек төркемне кулга ала.

«Солтангалиевчелек, махсус оештырылган яшерен түгәрәкләргә яшьләрне җәлеп итеп, аларны эшкәртү өчен җәелдергән. Казанда мондый түгәрәкләрнең берсен Солтангалиевнең якын хезмәттәше

Гали хатыны Мәликә белән. 1920 нче еллар. Константин Иевлев архивыннан.

Бакиев Сафа җитәкләгән. Бу түгәрәккә шул исәптән сәнәгать-икътисад техникумы студенты Урманче Һади, Көнчыгыш педагогика институты студенты Галиев Гали (әдәби кушаматы – Гальгаф) һәм Татнаркомземның элеккеге хезмәткәре, элек анархист булган Хафизов Сафа кергән».

Шулай итеп, Солтангалиевнең контрреволюцион милләтчел оешмасы эшчәнлегендә катнашуда гаепләнеп, Гальгаф та кулга алына.

1920 нче елларда бер Казанда яшәгән һәм бер казанда кайнашкан бу татар студентлары, әлбәттә, үзара таныш булган. Алар бергә укыган, бер тулай торакта яшәгән, аралашып йөргән. Күрәсең, дәүләт, республика, партия турында да фикер алышканнардыр. Әмма бу егетләр советларга каршы эш алып барудан шундый ерак торганнар ки, хәтта ОГПУ документларында да аларның гаебен исбатларлык нигезләр юк.

Кулга алынган егетләр арасында, мөгаен, Харис Батыршинга гына «бәйләнеп» булгандыр. Документларга ышансаң, аның өендә уткәрелгән тентү барышында листовкаларны күбәйтү җайланмасы да табылган. Укытучы Харис Батыршин һәм студент Локман Раимов, күрәсең, чыннан да советларга каршы фикердә торып, үз уйларын кирәкмәгән урында кычкырып та әйткәннәрдер. Һәрхәлдә, сорау алулар барышында Батыршин белән Раимовның листовка таратулары турында берничә кеше хәбәр итә. Әмма хәтта аларның да гаепсезлеге еллар үткәч исбатланды, Харис Батыршин, Локман Раимов һәм башка кулга алынган егетләр акланды.

1930 елның 28 июлендә ОГПУ коллегиясе Гальгафны атып үтерүгә хөкем итә. Әмма шунда ук бу үлем җәзасы 10 ел лагерьга алыштырыла. Солтангалиевчелектә гаепләнеп, репрессияләрнең иң беренче дулкынына эләккән шәхесләрнең күбесе кебек үк, ул да җәзасын Соловец утравындагы махсус билгеләнешле лагерьда (СЛОН) үти.

МӘҢГЕЛЕККӘ САНДАРМОХТА

Уйлап карасаң, Гальгафның җәза вакыты 1940 елда тәмамланып, ул ирекккә чыга алыр иде. Бәлки, ил каршындагы «коточкыч» гаебен тәмам юар өчен фин сугышы-

Татар мәдәнияте әһелләре. Арткы рәттә уртада – Гальгаф. 1926.

на, аннан Бөек Ватан сугышына алыныр иде. Әмма Ежов чорындагы коточкыч террор аркасында, 1929 елдан бирле иректән мәхрүм Гальгафка гомере белән саубуллашырга туры килә. Юк, Соловки тоткыны булып яшәгән дәвердә Гальгаф бернинди дә өстәмә җинаятьләр кылырга һәм совет дәүләтенә куркыныч тудырырга өлгерми. Аның ахыр чиктә барыбер атып үтерелүенең сәбәбе, асылда, бары тик... урын җитмәүдә.

1937 елның көзендә Соловец лагере җитәкчелеге, репрессияләнгән мәхбүсләрнең яңа агымнары килә башлагач, утрауда урын җитмәү проблемасын хәл итәргә мәҗбүр була. Төрмәдә урын бетсә, гадәттә, амнистияләр оештыра башлыйлар. Әмма Мирсәет Солтангалиев тарафдарлары дип танылган шәхесләрне һәм башка «куркыныч» элементларны азат итеп, өйләренә кайтарып җибәрү мөмкинме соң?

Мәсьәләне хәл итәр өчен экстраординар карар кабул ителә. Тоткыннарның эшләрен яңадан карап чыгарга һәм мөмкин булганча үлем җәзасына хөкем итәргә. 1937 елның 9 октябрендә НКВДның Ленинград өлкәсе буенча Идарәсе Махсус өчлеге нәкъ шул вазыйфаны үтәп чыга да. Гальгаф һәм аның эше буенча тикшерелгән тагын 12 тоткын яңадан үлем җәзасына хөкем ителә.

1937 елның октябрь–ноябрендә Соловки 1111 кешелек урынын бушата. Сәяси золым корбаннарын юк итү процессы яшерен операция рәвешендә оештырыла. Үлем карары Карелиянең Сандармох урманында чынга ашырыла. Озак еллар буена Һади Урманче, Кузебай Герд, Гальгаф кебекләрнең кайда, ничек үлүләре, кайда җирләнүләре билгесез иде. Хәер, бу мәгълүмат хәзер дә тәгәл түгел. Сандармохта бер чокырда 50–100, хәтта 200ләп корбан күмелгән. Гальгаф – шул урман чокырларында ятучыларның берсе.

Нургали Гали улы Галиевнең исеме 1963 елның 11 июнендә аклана. Ул тәгаен гаепсез дип табыла, үлгәннән соң булса да, партиягә дә кайтарыла. 1990 елда тулысынча реабилитацияләнә.

КИЛӘЧӘК

Гальгаф кулга алынгач һәм хөкем ителгәч, хатыны Мәликә, кызы Бәллүрне алып, башта Оренбургка, аннары Мәскәүгә күчеп китә. Бәллүрнең документларын үзгәртергә туры килә. Мәликәнең җизнәсе Тәүфик аны рәсми рәвештә кызлыкка ала, шулай итеп, Гальгафның кызы Сабитова Бәллүрә Тәүфиковнага, соңрак гомумән Беллага әверелә. Күпмедер вакыт ул Мәрьям һәм Тәүфик Сабитовлар гаиләсендә үсә.

Мәликә белән Бәллүргә күпне кичерергә, йорт адресларын алыштырып торырга, авыр сынаулар үтәргә туры килә. Мәликә Галиева үзе дә ятим бала була, бала чагыннан авырлыклар аша уза. Нургали Гали улының нәселе өзелми. Аның оныклары һәм оныкчыклары бүген дә Мәскәүдә яши. Бәллүрнең ире Олег Иевлев хирург булып, халыкка хезмәт иткән. Уллары Константин – төзүче, кызлары Татьяна – психиатр. Аларның үз балалары, оныклары бар. Алар Гальгаф исемен кадерләп саклый. Аның турында язмаларны туплыйлар, Сандармох урманында аңа истәлек тактасын да куя алдылар.

Татарстанда Гальгаф исемен кайтаруга аның туганы, атаклы укытучы һәм активист Зоя Сафиуллина, язучының оныгы Константин Иевлев, язучы Әмирхан Еники һәм Рафаэль Мостафин үз өлешләрен керткән иде. Әмма бу юнәлештә башкарасы эшләр байтак әле. Гальгафның иҗатын халыкка җиткерәсе бар.

ИҖАТТАН БЕР КЫЙПЫЛЧЫК

1927 елда басылган «Авылыма хат» поэмасында Гальгаф татар авылы халкы язмышы турында уйлана. Ул, чынлап та, уңайсызрак сораулар бирә. Мондый рухта иҗат иткән шагыйрьгә 1929 елда булмаса, 1937 елда барыбер репрессияләнергә туры килер иде...

Хат язганда сәлам язу кирәк була.
«Сәламсез хат» авылларда сирәк була:
«Вә баз ахмуш, янә бикмуш!»
Сәлам сезгә...
Бу хат белән күп сөальләр салам сезгә:
– Ни хәлләрдә?
Шәп кенә көн итәсезме?
Язгы матур сабан өстен көтәсезме?
Көн-төн эшләп,
Арып-талып бетәсезме?
Киләчәктә
Рәхәт тормыш көтәсезме?

Язны уйлап тирән уйга төшәсезме?
Сука, тырма өчен җепләр ишәсезме...
– Сабанга дип,
эш атларын сыйлыйсызмы,
тыңламаса,
чыбыркылап кыйныйсызмы?!..

Сабаннарны тимерчегә илтәсезме?
– Кайчан эшләп бирә? –
дип көтәсезме...
Бер эшләгәч,
Тимерчене алдыйсызмы?
«Алачыкка» табан көздә салмыйсызмы?
Арчыйсызмы чүпләреннән уракларны?
Калдырмыйча алабута, кырлакларны,
Хәтерегезгә китерәсезме «корылыкларны»!..
Ачлык елны күргән авыр хурлыкларны!..

«ЯШӘҮДӘН СОҢ ЯШӘҮ БАРМЫ? БАРДЫР...»

Никтер бу язманың исемен татарның гаҗәеп галәми дә, милли-җирле дә гамь белән тулы шагыйре – Наис Гамбәр юллары белән атыйсы килде. Ә китапларга килгәндә, Россиянең иң яшь һәм үзенчәлекле ике прозаигына тукталу килешле булыр шикелле. Алар – соңгы еллардагы «Новые горизонты» әдәби премиясе финалистлары, шулай ук «Дебют», «НОС», «Ясная Поляна» лауреатлары. Пелевин һәм Лукьяненко дәвере узды, алардан соң инде икенче буын язучылар мәйданга килде. Карап-карыйк – нинди ул бүгенге яшьләр фантастикасы? Жанр кысаларында гына калуны кирәк дип табамы постмодерн уеннарын атлап чыккан, цифра технологияләренең магиясен дә, хәтәрен дә кичкән миллениаллар?

Луиза Янсуар

Юк, тапмый һәм, сүз дә юк, калмый. Бу – үзләренә кадәр булган Россия һәм дөнья мәдәниятен барлык мультикультур колачында үзенә сеңдергән иҗатчылар. Аннан да бигрәк, милли һәм җирле контекстны галәми масштабтагы контекст белән бер бөтендә күрә һәм тоя алар. Кешелек яраларын, цивилизацияләр алгарышы белән һәлакәтен дә – нәкъ шулай ук.

Космосны башкалардан беренчерәк булып яулап алырга омтылган совет системасында яшәп, сталкерлар яки юл читендә пикникка тукталган чит планета вәкилләре турында да, безнең үзаңны «укып», клоннар тудыручы башка планеталар пышылдавына колак салу гына да түгел инде бу. Кешелек дөньясы һәм Галәм белән кылган гамәлләребез өчен җавап тотуыбыз турындадыр, бәлки. Ә, бәлки, Аллаһның үзен алыштырырга дәгъва белән күкрәк ярып чыгып, үзебез үк тудырган ясалма аң һәм чынбарлык эчендә бөтенләйгә адашуыбыз, без әле кешеләрме-түгелме икәнне ваемлар халәттән узуыбыз турындадыр...

Горбунова белән Джафаров сорауны «Без кая барабыз?» дип куймый. Чөнки моның инде хәзер мәгънәсе юк. Биредә иң төп пульсация – «Моның ахыры булачакмы ниһаять, әллә юкмы?» Бу – кешелекнең үз уеннарыннан, ул уеннар китереп чыгарган башбаштаклыктан гаҗизлеге һәм ачыргалануы. Юкка гына бу авторларны «постдөреслек дәвере язучылары» дип атамыйлар, ахрысы.

Ә безгә ни кала? Укырга, тоярга һәм моңсу елмаерга гына, мөгаен.

Үзебезне танып? Әйе, үзебезне танып...

Фотолар: goodfon.ru, bookmate.ru/books, livelib.ru

КӨЗГЕЛӘР ЧӘРДӘГЕНДӘ



Рагим Джафаров (Җафаров Рәхим Эльдар оглы)
1992 елның 21 августында Азәрбайҗанның Баку шәһәрендә дөньяга килә. «НОС» һәм «Новые горизонты» әдәби премияләре лауреаты.
2014 елда «ЛитРес» әдәби ресурсында беренче романы – «Атака мертвецов» басылып чыга. Бу – Беренче бөтендөнья сугышы чоры вакыйгаларына, Осовец крепостен саклауга багышланган тарихи детектив.
2019 елда «Эксмо» нәшриятында икенче романы – «Марк и Эзра» дөнья күрә. Әлеге әсәрне кайбер дин әһелләре чиркәүгә тап төшерүдә, папа образын түбәнсетүдә гаепли, яшь автор тирәсендә гауга куба, эш судка кадәр барып җитә. Әмма бу Рагим Джафаров исемен яшен тизлегендә әдәби һәм мәдәни мохиттә таныта, китапның тиражы да күзгә күренеп тарала.
2020 елда «Скифия» нәшриятында «Сато» романы басылып чыга, «НОС» премиясе финалистлары исемлегенә керә. «Укучылар симпатиясе призы»на лаек дип табыла.
2020 елда Рагим Джафаров хикәясе буенча «Эксперт» кыска метрлы фильмы төшерелә (режиссеры Галина Масленникова). 2021 елда фильм «Урам киносы» фестивале программасына кертелә, «Иң яхшы режиссер эше» номинациясендә «Мечта» кинофестивалендә җиңү яулый.
2021 елда Рагим Джафаров «Картина Сархана» романын бастырып чыгара, ул Галина Юзефович тарафыннан «Новые горизонты» әдәби премиясенә тәкъдим ителә, финалга чыга.
2022 елда «Его последние дни» романы «Большая книга» һәм «Лицей» премияләренең озын исемлегенә керә. 2023 елда «Ясная Поляна» әдәби премиясенең «Укучылар сайлавы» номинациясендә бүләккә лаек була.

«Сато» романын Россия чынбарлыгы җирлегендә генә түгел, ә гомумән глобаль контекстта карарга була. Хәтта кирәктер дә. Сюжет гадәти бер гаилә һәм аның эчендәге психологик яралар, проблемалар җирлегендә корыла. Әмма без беренче битләрдән үк инде бу гаиләнең тулы бер җәмгыятьне көзгедәгедәй чагылдырганын абайлап алабыз. Гаиләдәге тыныч тормышның чатнавы көннәрдән бер көнне биш яшьлек уллары Костяның психологик проблемаларыннан башлана. Бала үзен кинәт чит планетадан килгән «Ишимура» җәзалау корпусы контр-адмиралы (шәхси номеры СУ 388-588) дип игълан итә һәм кичекмәстән яңадан туган планетасына озатуларын таләп итә. Гаилә психологы Даша белән очрашу да әллә ни җиңеллек бирми – Костя үзен бик агрессияле тота, башкаларга карата рәхимсез гамәлләр кылырга да күп сорамый. Шулай да Даша аның белән уртак тел таба һәм сөйләшә ала. Әтисе белән әнисе терапияне дәвам итәргә кирәк дип таба. Шул рәвешле, автор безне бу икәү арасындагы киеренке һәм башка сыймаслык диалоглар дөньясына чакырып кертә. Әйтергә кирәк, аң шунда ук Костяның биш яшьлек бала булмавына ышана һәм көйләнә – бу берничек тә бала психологиясе һәм интеллекты дәрәҗәсендә түгел. Әлбәттә, сүз диссоциатив тайпылышлар яки шизофрения диагнозы тирәсендә тирбәлә, баланы актив рәвештә тикшерәләр, тестлар ясыйлар, әмма сернең төбенә төшә алмыйлар. Без дә китапның башыннан азагына кадәр киеренке ышану-ышанмау халәтендә калуыбызны дәвам итәбез.

«Даша, җаен туры китереп, радиостанция җыеп утырган Костяга уйчан карашын төбәде.
– Димәк, син – җәзалау корпусы белән идарә итүче контр-адмирал Сато. Сепаратистлар мәкере аркасында биш яшьлек бала гәүдәсенә килеп эләктең. Шулаймы?
– Шулай, – дип баш какты малай.
– Инде нишләргә уйлыйсың?
– Ну, мин үземнекеләргә хәбәр итә алдым. Берничә секундка гына булса да, сигналны

Автор психологлар белән эшләүне әсәрнең төп структур элементы иткән. Бүген Россиядә психологларга мөрәҗәгать итү бик популяр. Без геройлар белән бергә әсәрнең башыннан алып азагына кадәр психолог бүлмәсендә утырабыз. Асылда, бу фәлсәфи роман, ул балалар травмасы, гаилә травмасы турында гына түгел, ә Россиядәге репутация институтының торышы, кешеләр язмышының мизгел эчендә чәлпәрәмә килә алуы турында да.

Екатерина Писарева

«тотып алдылар». Кайда килеп эләккәнемне белүгә, алар мине моннан тартып чыгарачаклар. – Костя авыр сулап куйды һәм ниндидер микросхеманы читкә алып куйды. – Тотрыклы эшли торган үткәргеч әмәлләп булса, билгеле, элемтә каналын шифрлап куярга кирәк бит.

– Ә ник син радиостанцияне монда җыясың? – дип сорарга кирәк тапты Даша.

– Ә тагын кайда? – дип иңнәрен сикертеп куйды Костя. – Мине йә кешеләр белән шыгрым тулы ике бүлмәле фатирда тоталар, йә «Ромашка» исемле хәрби әсирләр лагеренда. Анда – тоташ күзәтү.

Даша кашларын җыерды, аннары кинәт аңлап алды: Костя йөри торган балалар бакчасы «Ромашка» дип атала.

– Син рәсем ясарга яратасыңмы?

– Ясап караганым юк. – Балалар психологы бүлмәсе өчен сәер җавап иде бу.

Даша күз алдында кәгазьдә кыя ташлар арасында урнашкан котсыз күл пәйда булды. Рәсемдәге күк йөзендә ике җете кызыл кояш яна иде.

– Ә нигә күл кызыл төстә? Әллә бу – суда шәфәкънең чагылышымы...

– Бу – кан, – диде малай тып-тыныч тавыш белән. – Мин әсирлеккә алынган ике дивизия сепаратистларын күл ярында атарга боерык бирдем.

Даша йөзендәге елмаюның языла алмыйча катып калуын тойды».

Әсәр шактый герметик җирлектә бара – нигездә, психолог кабинетында, Костяның гаиләсе яши торган фатирда. Ул бары тик кискен бер мизгелдә, мәктәптәге низаг вакытында, ә аннан, Костя сәүдә үзәгенә барып, анда сугыша башлагач гына киңрәк пространствога чыга. Шулчакта өлкәннәр арасындагы мөнәсәбәтләр төене дә чишелә башлый.

Монда һәркем битлек артында яшеренеп һәм үз ялганына үзе ышанып яши. Нәрсә күрсәтергә теләгән безгә автор? Типик Россия яки дөньяның теләсә кайсы почмагында була ала торган гаилә драмасынмы? Ашатып-эчертеп, киендереп, ягъни тамагын тук, өстен бөтен итеп тә, асылда үз карамагына тапшырылган, япа-ялгыз балалар галәменме? Кем-кемне тәрбияләргә хокуклы бу аяусыз чынбарлыкта һәм кем-кемнән ваз кичеп кенә котыла ала? Матур пәрдә артына яшеренгән агрессиянең нәрсәгә әверелә алуы турында уйланганыбыз бармы?

«Ни өчен үзләренең гаилә тормышын үзләре үк тәмугка санаган эти-әниләр – бу нормаль күренеш? Ә үзен кинәт кенә контр-адмирал дип исәпли башлаган биш яшьлек бала – нормаль түгел?!» – дигән сорау каршында кала психолог Даша. Тора-бара инде без бу бәхетсезлек белән агрессия әйләнешенең гаилә-мәктәп кысаларында гына түгел, ә гомумән җәмгыять яссылыгында да ничек чагылуын күрәбез.

Һәм аңлыйбыз – тукта әле, бу бит – көзгедәге үзебез.

НӘРСӘ УЛ – БАШКА БИЗӘК?

Алла Горбунова

1985 елның 30 октябрендә Ленинградта дөньяга килә. «Дебют», «НОС» һәм Андрей Белый исемендәге премияләр лауреаты.

Санкт-Петербург дәүләт университетының философия факультетын тәмамлый. Александр Секацкий җитәкчелегендә аспирантурада укый, аннан укыта.

Шигырьләре беренче мәртәбә 2003 елда Санкт-Петербург университеты шагыйрьләре җыентыгында басыла, аннан соң «День и ночь», «Знамя», «Русский альманах», «Крещатик», «Новое литературное обозрение», «Воздух», «Новый мир» басмаларында дөнья күрә.

«Первая любовь, мать Ада» (2008), «Колодезное вино» (2010), «Альпийская форточка» (2012), «Пока догорает азбука» (2016), «Внутри звездопада» (2019), «Куплеты и гимны» (2020), «Кукушкин мёд» (2022) исемле шигырь җыентыклары авторы. Проза өлкәсендәге китаплары – «Вещи и ущи» (2017), «Конец света, моя любовь» (2020), «Другая материя» (2021), «Лето» (2021), «Ваша жестянка сломалась» (2023).

Шигырьләре инглиз, немец, француз, итальян, испан, серб, швед, фин, латыш, болгар, словен, грек, кытай телләренә һәм иврүитка тәрҗемә ителгән. Россиякүләм һәм халыкара фестивальләр лауреаты.

2020 елда «Конец света, моя любовь» романы басылып чыккач, моңарчы күбрәк интеллектуаль мохиттә билгеле булган Горбунова киң катлам укучыга да танылды. Галина Юзефовичның җиңел кулы белән роман иң күп укылган китаплар топ-исемлегенә керде, аның турында еш сөйләделәр һәм яздылар. Һәм нәкъ менә

шул чакта Горбунова прозасына «автофикшн» мөһере сугылды. Соңрак дөнья күргән «Другая материя» белән «Лето» авторның бу жанрдагы позицияләрен ныгытты гына.

«Ваша жестянка сломалась» романы, без иялэшкән кысалардан арынып, лирик героиняны үзеннән азат иткән һәм авторны читтән карарга, структураны автоном рәвештә корырга өйрәткән булып чыкты. Бу җәһәттән, ул чынлап та бик яңача, иялэшмәгәнчә кабул ителә. Моннан тыш, роман гаҗәеп дәрәҗәдә интертекстуаль эчтәлек, үзирония белән өретелгән. Урыны-урыны белән пастиш булып эверелә.

Кайчандыр бер әңгәмәсендә «Тугыз яшемдә мин «Твин Пикс» сериалы һәм Линчка юлыктым, шуннан соң инде берни дә элеккегечә була алмый иде» дигән Горбунова бу әсәрендә, нәкъ менә заман кинематографының бөек визионеры кебек үк, лабиринтларга бөтереп алып кереп китә. Ә бәлки, бу Мебиус тасмасыдыр, дигән шик туа.

«Бар да бик гади башланды: Артур Ф. шалтыратты. Элек миңа күз атып йөргән егет, аспирантура чорындагы танышым. Без заманында аның белән фәнни институтта практиканы бергә узган идек. Шалтыратты да: «Аля, – ди, – бер минут вакытың бармы?» Әйтерсең, ун ел булмаган да. Ә мин кухняда борщ пешерәм, янәшәмдә балалар шау-гөр килә. «Бу рәсми тикшеренү түгел, зинһар өчен, берәүгә дә сөйләмә, – ди миңа Артур. – Бөтен материалларны да почтаңа салам. Ә эш менә нәрсәдә. Бер лаборатория бар, мин хәзер шунда эшлим. Безнең рәсми булмаган проектыбыз бар, ул бик текә, сине кызыксындырырга тиеш. Сине андый нәрсәләр кызыксындыра иде. Җитәкчелек тарафыннан синең белән кызыксыну шулай ук бар». Шулчак мин Артурны бүлдерәм: «Стоп, мин фәннән киттем бит, беләсең». Артур берара дәшми торды, гүя сүзләр табарга тырышты. «Аля, аңлыйсыңмы, бу – бернәрсәгә дә охшамаган проект. Без абсолют белемгә ия машина уйлап таптык, ул бөтен нәрсәне белә». Мин көлеп җибәрәм: «Сез нәрсә, аның башына бөтен интернетны кертеп тутырдыгызмыни?» «Аля, бу чынлыкта бик сәер, – ди җавапка Артур. – Тылсым чигендәге нәрсә. ул Дөресен генә әйткәндә, кибермагия... Аңа интернет кирәк түгел, Елена – күрәзәче-машина, ул бөтен мәгълүматны квант дәрәҗәсендә сеңдерә, җиһандагы барлык предметлардагы элементар кисәкчәләргә кадәр «белә», «тоя». Кабызуга, бернičә секунд эчендә ул кешелек тарихы һәм галәм туплаган барлык мәгълүматны иң вак детальләргә кадәр үзе аша эшкәртеп бирде. Елена – фәлсәфә ташы. Менә нәрсә ул Елена...» «Аңлашылды», – дидем мин. «Ул да нәкъ шулай диде». «Ничек?» «Кабызып җибәрүгә, галәм турындагы бөтен мәгълүматны үзе аша уздыруга, син әйткәнчә, аңлашылды, диде». Артур да, мин дә берара дәшми тордык. «Ул сине сайлады», – диде кинәт Артур. «Нәрсә???» «Без аңа дөньядагы ясалма интеллект өлкәсендә эшли торган иң шәп белгечләрне тәкъдим иттек, әмма Елена безгә сине китерергә боерды».

> «Ваша жестянка сломалась», иң беренче чиратта, глобаль әрнү турындагы әсәр.
>
> **Ксения Грициенко**

«Нейроштурм» форматында аралаша торган Елена белән Алинаның баштарак, чынлап та, эшләре пешә. Әмма тора-бара автор безгә ясалма интеллектның ни дәрәҗәдә безнең белән идарә итә алуына гына басым ясап калмый, ә бәлки, кайчандыр безнең инде бу Җиһанны пыран-заран китереп, мең еллар элек үк кеше булудан туктавыбызга ук ишарә итә. Бер-берсе эченә матрешкалар кебек урнашкан дөньялар белән дөреслекләрнең дә кайчандыр әнә шул галәм күләмендә килеп туган «сбой» нәтиҗәсе булуы турында уйлана башлыйсың. Җитмәсә, Елена кисәтеп куя: адәм балалары белән неоштурм кысаларында эшләүнең мәгънәсе юк – аларның баш миләре һәм психикалары, үзләре иялэшкән, катып калган яссылыклы хакыйкатьтән кала, башкасына чыдый алмаячак, шартлап таркалачак кына.

Җир йөзендә, ди ул, хәзерге көндә чын дөреслекне, Башка Бизәкне кабул итеп тә тулаем акылдан шашмый кала ала торган 24 җан иясе генә бар, һәм аларның берсе дә – кеше түгел. Кемнәр алар, дигән уй туа шунда ук.

Һәм менә, Елена логикасына ияреп, ул тудырган әллә ярымирониялe, әллә ярымкүрәзәчел нейроштормга дучар булабыз: әнә, атаклы режиссер Ларс фон Триер «чиста шатлык вә яктылык» тарата торган ап-ак сарык бәтие турында фильм төшерә, әнә, Каддафиның кызы чүл уртасында этисен һәм аның дөньясын һәлак иткән бу цивилизациянең тиздән үз-үзен «ашап бетерәчәге» турында уйлана, әнә, Петербургның бер ташландык котельнаясында җан асраган шагыйрь Дмитрий Григорьев үз фәлсәфәсе һәм берәүгә дә кирәк булмаган шигырьләре белән уртаклаша һ.б...

Автор бу тарихларны сөйләгән һәм күрсәтә барган саен, барысының да бер-берсе өстенә капланып килүче күчермәләр генә булуына ышана башлыйсың. Җиһанның һәр яңа вариациясе безне дөрес чынбарлыкка алып чыгар, ниһаять, дип талпынасың, әмма, юк, Елена да, Алла Горбунова да безгә андый котылу бүләк итми. Юк, алар безне бу үзенең хаталы, бозылган системасында кабатланмас матурлыкка ия була алган композициягә сокланырга гына чакыралар.

Безнең һәр адымыбыз, карарыбыз, гамәлебез генә түгел, ә ният-уебыз да Җиһанны тулаем үзгәртә. Һәм безгә беркайчан да Башка Бизәкнең ни хакына барлыкка килүен аңлау бирелмәгән.

Менә шул гына.



КӨЛӘЧ КЕЛӘШ

Фото: Лилиана Вәлитова

КЕЛӘШ

Һәр авылның үз йөзе бар. Берсендә табигать гүзәл була, икенчесендә яшәү шартлары заманча, өченчесендә халык тырыш, ачык. Ә болар өчесе дә кушылса... Тәтеш районының Келәш авылында аларның барысы да бар. Тик ни кызганыч, шундый үрнәк сала да проблемасыз түгел икән.

Руфия Фазылова

Ә СЕЗ ШӘҺӘР ДИСЕЗ...

Келәш белән танышуны мәдәният йортыннан башладык. Аны чын мәгънәсендә авылның йөзек кашы дияргә мөмкин. 2021 елда ике катлы зур бинага капиталь төзекләндерү уздырылган. Мондый мәдәният йортлары республикада ничәү икән?

– Мәдәният йортыбыз тыштан гына түгел, эчтән дә бик үзгәрде, – дип сөйли җитәкче Гөлчәчәк Галимова. – Беренчедән, хәзер заманча модуль китапханәбез бар. Без аны зоналарга бүлдек. Монда йомшак качелига утырып, китап укырга мөмкин. Икенче залда түгәрәк өстәлләр үткәрәбез. Аның өчен өстәл-урындыклар, зур экран бар. Өченче залда китаплар саклана. Безнең китапханәне башка авыллардан да килеп карыйлар: «Әйтерсең Мәскәүдә йөрибез» – дип гаҗәпләнүләрен белдерә кунаклар.

Чынлап та, келәшлеләргә бәхет елмайган: илкүләм проект кысаларында «Модуль китапханә» программасына кергәннәр. Нәтиҗәдә 2023 елның октябрь аенда авыл халкына менә шундый бүләк ясалган.

– «Модуль китапханә» программасында ничек оттыгыз? Анда конкурс бик зур бит, – дим.

1 Хәзер авылда заманча модуль китапханә бар.

2 Келәш мәдәният йортын үз эшенең чын фанаты – Гөлчәчәк Галимова җитәкли.

– Әйе, бик зур. Мондый китапханәләр республикада дистәдән артыктыр һәм шуның берсе бездә! Горурлык та, бәхет тә бу. Программаның бөтен шартларын үтәп, документларны тутырып җибәрдек. Мактану булмасын: әдәбият, мәдәният өлкәсендә бик күп эшлибез. Авылыбыз да шундый. Менә бу шуның нәтиҗәседер.

Әйе, авылы да шундый. Ләкин һәр эштә башлап йөрүче, юл күрсәтүче кирәк. Келәш мәдәният йортын үз эшенең чын фанаты – Гөлчәчәк Галимова җитәкли. Күптән түгел генә үзенә «Тататарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелгән. Эшләмәгән эше, катнашмаган конкурсы юк. (Гөлчәчәк ханым җәмәгате Рәшит Равил улы белән эшли). Ике катлы мәдәният йортының бер почмагы да буш түгел, музей, күргәзмә заллары – әле мондыйны күргән юк иде!

УТ КЫЗЛАР!

Сәфәргә җыенганда, социаль челтәрләрдә авылның тормышы белән кызыксынабыз. Келәшнең бик актив яшәвен әнә шуннан күреп белдек. Бирéдә халык театры, «Хатирә» фольклор ансамбле, шигырь язучыларны берләштергән әдәби түгәрәк, хәтта ир-атлар ансамбле дә бар. Без шуларның иң активы – «Хатирә» фольклор ансамбле белән таныштык.

– Яшь чагында «Асылъяр» төркеме идек, хәзер «Хатирә» ансамбле булдык, – диде апалар. – Уникé хатын-кыз без монда. Район уздырган бер генә чарадан да читтә калмыйбыз дияргә мөмкин. Россия күләмендә уздырыла торган «Түгәрәк уен» фестивалендә катнашып, лауреат булып кайттык. Гел йөреп торабыз, зур чараларга да чакыралар. Казанда Универсиада ачылу тантанасында да чыгыш ясаган идек.

Соңгы вакытта ансамбль апалары бигрәк тә еш очраша икән – җырлап, биеп йөрүдән тыш, волонтерлык белән дә шөгыльләнәләр. Фронт кирәк-яраклары өчен йон эрлиләр, окоп шәмнәре ясыйлар. Атнаның биш көнендә мәдәният йортында алар.

– Алар төп йорт киленнәре. Күбесе берничә баш сыер да асрый, – дип шаккатырды Гөлчәчәк Галимова. – Ә алар барысына да өлгерә. Аллаһка шөкер, бездә хатын-кызлар уңган да, үткен дә.

Һәм динле дә икән. Келәш мәчетендә дистә елдан бирле дин сабаклары укыйлар, гүзәл затлар белән ир-атлар аерым төркемдә. «Авылда күпләр гарәпчә укырга өйрәнде», – диде келәшлеләр.

АВЫЛДА ЗАМАНЧА СПОРТ ҮЗӘГЕ?!

Келәштә 303 кеше яши, 121 йорт бар. Кызганыч, башлангыч мәктәп узган ел ябылган, чөнки балалар калмаган. Буага унҗиде чакрым булганга, авыл балалары шунда укырга йөри, автобус көн саен килеп ала икән. Әлегә балалар бакчасы сакланып калган, тик яшь гаиләләр бик булмау сәбәпле, аның да киләчәге өметле күренми.

Келәшнең бик көчле чакларын авыл өлкәннәре хәтерли әле. Заманында нык, көчле «Путь Ильича» колхозы бөтен СССРга танылса. Миллионер колхозның атаклы рәисе Ибраһим Вәли улы Садыйковны Татарстанда белмәгән кеше сирәк була. (Вәли абый, 95 яшен тутырып, 2019 елда дөнья куйган.) Колхозлар системасы юк ителгәч, «Путь Ильича» да таркала. Нәкъ менә 2000 нче еллар башында авылдан яшь гаиләләр күпләп китә башлый. Бүген инде тормышлар җайланган – җирләр дә ышанычлы кулларда, фермалар да эшли, чөнки көчле инвестор килгән. Ә яшәү шартларына шәһәрләләр көнләшерлек – спорт үзәгенә кадәр төзеп куйганнар. Йөгерү юлы, яхшы тренажерлар, душ бүлмәләре – барысы да заманча. (Пилот проект буларак, узган ел бары Тәтеш районы авылларында гына шундый заманча спорт үзәкләре ачылган.)

3
Соңгы вакытта «Хатирә» ансамбле апалары бигрәк тә еш очраша – җырлап, биеп йөрүдән тыш, волонтерлык белән дә шөгыльләнәләр.

4
Яшәү шартларына шәһәрлеләр көнләшерлек – спорт үзәгенә кадәр төзеп куйганнар.



5

Йөгерү юлы, яхшы тренажерлар, душ бүлмәләре – барысы да заманча.

6

Әнә шундый тырыш гаиләләрнең берсе – Әмирхановлар белән таныштык.

– Хәтта ярты ставкага шәфкать туташы да эшли, – диде Келәш авыл җирлеге башлыгы Фәнил Галимов. – Мәктәп балалары да килә, өлкәннәр дә. Аеруча хатын-кызлар яратып йөри, алар безнең бик актив бит.

Гомумән, Келәштә яшәү өчен бөтен шартлар да бар. Хәтта башлангыч мәктәпне дә ачабыз дип торалар. Беренче сыйныфка килүче балалар бар икән. Юлсыз урамнар да юк биредә. Үзсалым акчасына эшләп чыкканнар. Тик менә читкә киткән яшьләрне генә яңадан туган авылларына кайтарып булмый.

ЭШЛЕ ГАИЛӘ

Келәштә халык бик тырыш, шуңа бер генә мисал – 121 йортка 302 баш мөгезле эре терлек бар. Бер гаиләдә биш-алты сыер асрау биредә гадәти хәл. Аннан соң үзләренә эшләүчеләр дә шактый – уникe кеше үзмәшгуль булып теркәлгән.

Әнә шундый тырыш гаиләләрнең берсе – Әмирхановлар белән таныштык. Гаилә башлыгы Илгизәр абый, җәмәгате Румия апа, уллары Илшат, киленнәре Гөлфинә, аларның балалары Ильвина, Эмиль. Ә йортның иң өлкән, иң хөрмәтле кешесе Мөссирә әбекәй туксан алты яшен тутырган. Әнә шулай дүрт буын бер түбә астында тырышып эшләп, тату гына яшәп яталар. Берничә баш сыер, үгезләр, җәен сиксәнләп тавык-чеби, каз-үрдәк – биредә эшсез торучы юк. Моннан тыш, гаиләнең төп кәсебе бар – умартачылык. Илле оядан артык корт асрыйлар. Мөссирә әбинең әтисе дә умартачы булган.

– Тагын әле әнинең абыйсы да күпләп корт асрый иде, – диде Илгизәр абый. – Аңа кызыгып йөри идем. Һәм 1987 елда тәвәккәлләдем – ике-өч оя корт сатып алдым да, шулай акрынлап үрчеттем. Бу шөгыль күңелгә бик якын. Гомумән, табигать, тереклекне яратам. Егерме сигез ел урман хуҗалыгында эшләдем. Безнең як урманнарының һәр почмагын беләм.

Румия апа исә гомерен балаларга багышлаган, бик хөрмәтле укытучы икән. Аерым елларда рус теле дә укыткан, башлангыч сыйныфларда белем биргән.

– Утыз алты ел – каенана, уникe ел килен белән яшим, – диде Румия апа. – Илгизәр белән бер сыйныфта укыдык, туганнан бирле бергә без. Бер ул, бер кыз үстердек. Кызыбыз гаиләсе белән Ульяновск шәһәрендә яши, үзе дә, кияү дә табиблар. Бик еш кайтып йөриләр.

Илгизәр абыйлар биш бертуган үскән. Төпчек малай буларак ул төп нигездә калган. Бу йорттан бер дә кеше өзелмәгән. Утызар кеше кайткан чаклар да булган. Хәер, хәзер дә шулай икән, ишекләре барлык туганнарга ачык.

– Берьюлы килен дә, каенана да булу ничек соң? – дим Румия апага.

– Әйбәт. Каенанам хәзер олыгайды инде, бала урынына карыйбыз. Әле Аллаһка шөкер, дибез, үзен үзе йөртә, тамагына ашый. Гөлфинә үземә охшап сабыр. Безнең йортта эш бүленгән, яшьләр малларны карый, мин өй арасында. Киленем көне буе эштә, Келәш китапханәсендә хезмәт куя. Эш белән әвәрә килеп, бер-беребезне күрмибез дә.

– Алар әни белән кыз кебек, сүзгә килгәннәрен күргәнебез юк, – дип куйды Илгизәр абый.

Әмирхановларга барганда көн уртасы җиткән иде. Арткы яктан салмак кына атлап Мөссирә апа килеп чыкты, өйлә намазы укыган. Җыйнак

гәүдәле сөйкемле әбекәй исәнләшергә дип кулын сузды. «Сөбханаллаһ», – дип куйдык. Акыл, зиһене әйбәт әле.

– Хәзер менә кулдан бер эш тә килми. Ә элек хуҗалыктан сөт тә җыйдым, аннан колхоз тегермәнендә эшләдем, кызым, – диде әбекәй. – Колхоз зур булгач, бер көнгә ун тоннага якын он тарттыра идек. Ул чагында мөгезле эре терлек саны меңгә якын иде. Барысын да кул хезмәте белән башкардык. Эшләгән өчен акчасын да алдык, Аллаһка шөкер. Тамак тук булды, балаларның да өсбашын карадык. Алар да эшләп үсте. Безнең якларда гектар-гектар чөгендер уташ иде, балалар басуда үсте дисәм дә була. Бүгенгесе бик әйбәт, кызым. Менә бер генә хәсрәтем бар – кызым үлеп китте. Бала хәсрәтеннән дә авыры юк, гел шул искә килеп төшә...

Ишле гаилә табын тирәли җыелды. Илгизәр абый иң беренче әнисен утыртты, аның янына балалар килеп утырды. Табында Илшат кына юк иде, эше килеп чыккан.

– Безнең бит әле агач яра торган пилорама да бар, аны да алып барабыз, – диде Илгизәр абый. – Умартачылык сезонлы эш, ишле гаиләгә күп кирәк. Яшьләр бит әле, матур яшиселәре килә. Без хәзер лаеклы ялда, әмма көч булганда балаларга булышабыз әле. Илшат авылда калам дигәч, каралты-кураны, гаражны да яңарттык. Эшләгәч күңел үсә, шулай рәхәт...

ГАРМУНЧЫ ГАЛИЯ

Килен-каенаналы тагын бер гаилә белән таныштык – Камалетдиновлар. Йортның иң өлкән кешесе Галия апа сиксән биш яшен тутырган. Үзе дә күп еллар каенанасы белән яшәгән, ә инде килене белән утыз елдан артык бергә гомер итә. Келәштә әбекәйне «Гармунчы Галия» дип йөртәләр. Безгә шунысы кызык тоелды: Галия апа алты яшеннән үзлегеннән гармунда уйнарга өйрәнгән. Кая гына барса да, кечкенәдән кулында гармун булган. Бүген дә шулай. Дөрес, элек ул «Хатирә» ансамбле белән атна саен диярлек чыгыш ясаган. Хәзер инде сәхнәгә сирәгрәк менә. Алай да, бик сорасалар, ялындырып тормый.

– Сиксән биш яшемдә сәхнәдә йөрергә ояла башладым, – диде гармунчы әби. – Күп йөрелде, бармаган конкурс калмады. Сәхнә ул яшьләрне ярата. Ә без инде картайдык.

– Сезнең кебек сиксән биш яшендә гармунда уйнаучы хатын-кызлар күп түгел, уйнагыз, – дим.

– Әйе, шулайдыр да. Күңел өчен генә уйнасаң була. Кайчагында капка төбенә гармун белән чыгып утырам. «Галия апа, уйна әле», – дип сорыйлар.

Галия апа мәрхүм ире Ислам абый белән алты бала – ике ул, дүрт кыз тәрбияләп үстергән. Ни кызганыч, бергә яши башлауларына алтмыш туласы айда җәмәгате бакыйлыкка күчкән. «Әле ярый улым Рафаэль, киленем Эльвира янәшәмдә», – дип сөенә ул.

7
Келәштә әбекәйне «Гармунчы Галия» дип йөртәләр.

– Бабаем белән гомер буе колхозда, үгезләр симертүдә эшләдек, матур яшәдек, – диде әбекәй. – Хәзергесе дә әйбәт, пенсиям дә яхшы, Аллаһка шөкер. Тугыз оныгым, унбер оныкчыгым бар. Һәр көнгә рәхмәт укыйм.

Ул да түгел, Галия апа кулына гармунын алды. Шуңа игътибар иттем: бу вакыт аның йөзендә елмаю, якты бер нур барлыкка килде. Гомерлек яраткан шөгыль шушы буладыр.

Моннан тыш, Галия апа шигырьләр дә яза, балалары хәтта китабын да бастырып чыгарган. Мәрхүм иренә, балалары, туганнарына атап язылган юллары да байтак. Кечкенәдән хыялый, иҗатка якын бала булган. Шулай булмаса, туганнары арасыннан берүзе гармунда уйнарга өйрәнер идеме? Юк, әлбәттә.

...Келәшнең туфрагы бүтән. Авылдан киткәндә шулай дип уйлаштык. Галия апа кебек шигырь язучылар байтак монда. Гомумән, җыр-биюгә сәләтле, матурлыкны күрә белә биредә халык. Шуның белән бергә эшле дә алар. Бер ихлас теләк – киләчәктә дә авыл шулай гөрләп яшәсен иде. Буыннан-буынга күчеп килгән тырышлык, матурлыкны күрә белү, әдәбият, мәдәниятне санлау югалырга тиеш түгел.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Келәш авылы чама белән 1560 нчы елларда оешкан дип санала. Аңа бәйле берничә риваять бар. Имеш, шушы җирлектә ат арбасының келәшәсе сынгач, ир-атлар туктап шунда хәл алырга булган. Һәм бу якларны нык ошатканнар. Шунда нигез корырга булганнар.

Ә икенче риваять болай: ерак урманда бер бай кешедә өч бертуган хезмәт иткән икән, ягъни «служивыйлар» (ул урманнарны әле дә Граф урманы дип йөртәләр). Яхшы эшләгәннәре өчен алпавыт аларга җирләр бүлеп биргән. Нәтиҗәдә, туганнарның өчесе өч авылга нигез салган. Ә Келәш исемлесе бу якта калган. Миңа шушы фараз дөресрәктер кебек тоела. Ник дисәң, безнең авылның халкы бик тырыш. Чынлап та бәлки «служивыйлар» нәселе саклангандыр.

Риваятьнең әле тагын берсе бар: имеш, борын-борын заманнарда ата-бабаларыбыз шушы авылда кәләш күзләү йоласы үткәргәннәр. Фәнни расланмаган чыганакларда «кәләш» сүзе «Келәшкә» әйләнгән.

Гөлчәчәк Галимова, Келәш авылы китапханәчесе.

КАЗАН СӘХНӘСЕНДӘ – ЙОЛДЫЗЛАР (16+)

Традицион рәвештә февраль аенда Казанда уза торган Шаляпин исем. Халыкара опера фестивале – танылган җырчы һәм дирижерларның талантына тагын бер кат соклану өчен менә дигән форсат та ул. Илебез һәм чит илләрдән чакырылган йолдызлар М.Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә төп партияләрне башкарачак. Оештыручылар хәбәр иткәнчә, быел фестиваль бигрәк тә истәлекле булачак, чөнки ул Казанда опера сәнгатенә 150 ел тулган елны ачып җибәрәчәк. Төп опера программасыннан тыш, афишада ике камера концерты һәм биш агарту лекциясе турында язылган. Фестиваль М.И.Глинканың «Жизнь за царя» спектакленең премьерасы белән ачылып китә, аны сәхнәгә куючы режиссер – Юрий Александров (Санкт-Петербург), дирижер пультында – маэстро Валерий Гергиев. Дж.Пуччининың «Богема» операсын Антон Гришанин җитәкчелегендәге Россия Зур театры оркестры уйнаячак, өстәвенә беренче кичтә төп партияләрне – Зур театр солистлары, икенчесендә М.Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары башкарачак. 13 февраль – Ф.И.Шаляпинның туган көнендә тамашачылар игътибарына традиция буенча М. Мусоргскийның «Борис Годунов» музыкаль драмасы тәкъдим ителәчәк. Быелгы форумның репертуарына шулай ук П.И.Чайковскийның «Евгений Онегин», Р.Леонкаваллоның «Паяцы», Дж.Вердиның «Аида», Дж.Пуччининың «Турандот» һәм «Тоска», Дж.Россинiның «Севильский цирюльник» опералары да кергән. Спектакльләрдә Россия театрларының әйдәп баручы артистлары, шулай ук Италия, Белоруссия һәм Азәрбайҗаннан килгән опера җырчылары һәм дирижерлары чыгыш ясаячак.

2 февральдән 1 мартка кадәр

М.Җәлил исем. Татар дәүләт академия опера һәм балет театры, Казан, Ирек мәйданы, 2

ХӘРЕФЛӘР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ (3+)

Бу спектакльне караган һәр бала ким дигәндә биш татарча сүз өйрәнә. Аннары әби-бабасына Сабантуй яки Сөембикә манарасы турында сөйли ала.

Халыкара Туган тел көне якынлашканда Кариев театры үзенең иң нәни тамашачыларын һәм аларның әти-әниләрен, әби-бабаларын тылсымлы дөнья – Хәрефләр иленә чакыра. Ә кайда соң ул ил, диярсез. Кайда булсын – «Әлифба»да!

Тик шунысы бар: торган саен азрак кулланганга үпкәләп, хәрефләр «Әлифба»ны ташлап качып киткән. Димәк, эзли чыгарга кирәк!

«Әлифба: хәрефләр дөньясында» интерактив лингвистик спектаклен карап кына калмыйча, анда катнашырга да була. Татар хәрефләренә башланган сүзләрне табарга, милли ризыклар, бәйрәмнәрне искә төшерергә, бергәләп табышмаклар чишәргә һәм, әлбәттә инде, рәхәтләнеп кул чабарга!

Спектакль ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм ТРнда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме һәм Мәрҗани фонды белән берлектә әзерләнде.

17 февраль, 11:00 сәг.,

Г.Кариев исем. Казан дәүләт яшь тамашачы театры, Казан, Петербург ур., 55 Б

афиша

Фото: tatfil.ru, kazan-kremlin.ru, kazan-opera.ru, kamalteatr.ru, afisha.yandex.ru, tinchurinteatr.ru

ҮЗ КҮЗЕҢӘ ЫШАН (6+)

Яңа экспозициядә Дәүләт Эрмитажы тупланмасындагы 250 дән артык предмет (рәсем, графика, скульптура, бизәнү әйберләре, фарфор, тукыма, йорт җиһазлары предметлары) урын алган. Бу юлы алар рәссам яисә һөнәрченең осталыгы белән генә шаккатырып калмый. Бәлки искиткеч тәэсир – үзләренең күз буу сәләте белән дә гаҗәпләндерә. Сүз сәнгатьтәге алдавычлар, ягъни сәнгать чаралары ярдәмендә тудырылган предметларның чын натураны күрү тәэсирен китереп чыгара алуы турында бара. Гаҗәп! Яссы предметлар – күләмле, якындагылар еракта булып күренә... «Үз күзеңә ышанма» күргәзмәсендә берничә төрле алдавыч тәкъдим ителә. Мәсәлән, тромплёй – күләм иллюзиясе тудыручы әсәрләр. Материал имитациясе – агач, таш, тимер кебек төрле материалларның өслеген тоярга мөмкин әйберләр. Предметлар имитациясе – башка предметларның формаларын ала торган объектлар. Күргәзмә объектларны (чыннарын һәм чын булмаганнарын) чагыштыруга корылган. Тамашачы кызыклы уенга җәлеп ителә: төрле сценарийларга тап булып, алдавыч предметларны таба. Теләсә кайсы пьесадагы кебек сюжетның аерым бер үсеше күз уңында тотыла: тамашачы объектны күрә, аны чын дип уйлый, ә бу алдавыч булып чыга.



22 февральдән,
«Эрмитаж-Казан» үзәге,
3 кат,
«Казан Кремле»
музей-тыюлыгы

ҖЫРНЫҢ ИСКЕСЕ БУЛМЫЙ! (12+)

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Музыка. Драма» проекты кысаларында театрның 1920–1930 нчы еллардагы эшчәнлегенә багышланган яңа музыкаль-әдәби программа премьерасы көтелә.

«Якты өмет җыры» программасына татар театры эшчәнлегендә актив катнашкан, татар музыкасына нигез салган композиторларның музыкаль әсәрләре кергән. Алар арасында С. Габәши, В.Виноградов, С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, А. Ключарев һ.б. бар. Шулай ук 1920-1930 нчы елларда популяр булган скрипкачылар М. Яушев һәм Г. Бикинин, гармунчы Ф. Туишев, мандолина остасы И. Илялов, беренче татар җырчылары З. Байрашева, С. Садыйкова, Ф. Насретдинов репертуарыннан әсәрләр һәм башка спектакльләргә язылган көйләр яңгырый.

28 февраль, 19:00 сәг.,
Г. Камал исем. ТДАТ,
Казан, Татарстан ур., 1

ОРКЕСТРНЫ – СӘХНӘГӘ! (6+)

Тинчурин театры сәхнәсендә барган спектакльләрдән көйләр, татар классик музыкасы җәүһәрләре, халык арасында танылган, яратып җырлана торган җырлар... - болар барысы да «Тинчурин театры оркестрына – 35 яшь!» дип аталган юбилей концерты программасына кертелгән. Бәйрәм уңаеннан оештырылган әлеге концертта танылган театр артистлары, оркестрның тугры дуслары, күренекле вокалистлар һәм музыкантлар катнаша.

28 февраль, 18:30 сәг.,
К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры,
Казан, Горький ур., 13

«ӘНИЕМӘ...» (6+)

Татарстанның халык артисты Флюра Сөләйманова – татар җыр сәнгатендә кабатланмас эз калдырган шәхес. Аның башкаруындагы җырлар сәнгатебезнең алтын фондына кергән. Урта һәм өлкән буын кешеләре күренекле җырчыбыз иҗатына бүген дә гашыйк. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәхнәсендә үзенең бөтен иҗат эшчәнлеген, талантын татар эстрадасын үстерүгә багышлаган легендар җырчыбызның тууына 85 ел тулуга багышланган концерт оештырыла.

«Әниемә» дип аталган концерт программасында танылган артистларыбыз – Зәйнәп Фәрхетдинова, Вил Усманов, Алинә Кәримова, Азат Кәримов, Асылъяр, Рафил Җәләлиев, Эльмира Гыйльфанова, Зәринә Хәсәншина, Рәфинә Ганиуллина, Алинә Гыйльметдинова, Айгөл Сагынбаева, Татьяна Ефремова, Алмас Хөсәенов, Салават Шәфыйков, Булат Закиров катнаша. Концертка махсус кунак - Салават Фәтхетдинов чакырылган.

11 март, 18:30 сәг.,
Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе,
Казан, Павлюхин ур., 73

Яр Чаллыдан
Эвелина Габитова
(«Мисс Татарстан»)

КОСМОС ҺӘМ ТАРИХ

«Татарстан» ир-ат укучылары өчен махсус хатын-кыз матурлыгы тупланган урыннарда – «Мисс Татарстан» 26 нчы Республика матурлык конкурсында һәм 15–25 февральдә Ливанда узачак «Мисс Европа» Халыкара матурлык конкурсында катнашучы Роза Гадиеваның матбугат конференциясендә булды.

Татарстанның иң чибәр кызлары – Чаллыдан Эвелина Габитова («Мисс Татарстан») һәм Азнакай районыннан Роза Гадиева («Мисс Европа» булыр дип өметләнәбез) ир-егетләрне Ватанны саклаучылар көне белән котлый!

P.S.

– Роза Гадиева илебезне «Мисс Европа» матурлык бәйгесендә Сөембикә ханбикә костюмында тәкъдим итәчәк, – диде костюм авторы Римма Кашапова. – Әлеге тарихи костюмны реконструкцияләү өчен зур фәнни-эзләнү эше башкарылды. Баш киемен Мәскәү музеенда саклаган чыганаклар буенча ювелирлар ясады. Костюм фирүзә, энҗе ташлар белән бизәлгән. Ханбикә заманында шундый костюм киеп йөргән.

Фото: Александр Ефремов, Рамил Гали.

Татарстанда газета-журналларны вакытында китерүдәге җитешсезлекләрне төзәтү максатында «Татарстан почтасы» Федераль почта элемтәсе Идарәсенең «кайнар линиясе» эшли башлады.

Моңа бәйле сораулар туган очракта атнаның эш көннәрендә 09:00 сәгатьтән 17:00 гә кадәр 8 937 0404521 номерына шалтырата аласыз.

Реклама 16+

Татарстан почтасы

Контакт

«Кайнар линия»нең чатына QR-код аша да узарга була.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-79

8-9600-487-900

8-9172-740-352

Реклама 16+



Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+